Безнең МИРАС

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

07
июль 2020

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

Мәхәббәт чокыры

81 бит

75 ел эзләдем

92 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

07
(319)
июль 2020

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АЖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-92)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Григорий Родионов (Гәрәй Рәхим)
Данил Салихов
Индус Таһиров
Ирек Шәрипов
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Ләйлә Лерон
(843) 222-09-83 (17-93)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энже Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Шәйхи Маннур

ТАТАР ГАМЕ

4 Рамил Муллин: «Иң мөһиме – кешенең рухи дөньясы»

ТАРИХИ МИРАС

12 Этрусклар – Рим остазлары. *С.Шәмси*
16 Мамадышым – газиз җирем! *Ф.Мингалиева*
22 Керәшен тамгалары. *Л.Константинова*
28 Мамадыш крестьяннары бунты. *Ю.Карпов*
31 Кече Сон мәдрәсәсе тарихы. *Р.Муллахмәтова*
36 Мамадыш төбәге авыз иҗаты – милләт сагында. *Л.Мөхәммәтҗанова, Г.Дувалова*
41 Кәвәл авылы (Түгәрәк уен көе)
42 Татарларны чукындыру сәясәте Үтәмешне дә читләтеп узмаган. *Н.Исхаков*
50 Халкыбызның рухи юлбашчысы. *Р.Мәрданов, И.Һадиев*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, А.Дубинның «Ике Казан» («Две Казани») дигән альбомыннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан, Мамадыш һәм Мөслим муниципаль районнары архивыннан алынган рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында
басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

56 Ядкярләрдән безгә тарих бага... *А.Борһанов*
60 Мөслимнең «Туган якны өйрәнү музее»
64 Милли көрәш төрләре. *М.Сәхәбетдинов*

ДИНИ МИРАС

66 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

ӘДӘБИ МИРАС

72 «Татар моңнары һаваларга таралсын!» *Х.Миңнегулов*
81 Мәхәббәт чокыры. *К.Кәримов*
84 Уймак-уймак уйлар. *С.Шәйхи*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН...

86 Зөлфәт вафаты. *Л.Лерон*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

90 Истә, һаман да истә!
92 75 ел эзләдем. *А.Гаделша*



81

86

СҮЗ ҺӘМ СУРӘТ

100 Гомерем мизгелләре. *Ә.Зарипов*

СӘНГАТИ МИРАС

106 Борынгы татар милли музыка уен кораллары. *Р.Гыйләҗев*
110 Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында. *З.Гыйльметдинова*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

112 Тел дигән дәрья бар... *Р.Акъегет*

ШАЯН МИРАС

114 Көлке куа килә...

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Июль*

100

Заказ №А-1490. Тираж – 2465 данә. Формат 70x100 1/16
Басарга кул куелды: 26.06.2020. Чыгу көне: 01.07.2020.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән әзерләнде.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: «Сабан туе – халкыбызның борынгы бәйрәме». Фото «Мең чалымлы Казан» («Татарстан» журналы нәшрияты, 2005 ел) исемле китаптан алынды.

Кешеләрне көлү матур итә,
Яшьлек сүнмәс, көлеп яшәсәк!

Шәйхи Маннур

Шәйхи Маннур кызы Миләүшә белән

Шәйхи Маннур

(15.01.1905-10.06.1980)

***

Мәҗлесләрдә бокал чөеп
Туган дуслык – ялган була!
Чын дуслык ул – утта көеп,
Үлем йөргән яуда туа.

***

Югалтышу зары һәм кавышу
Сөенече – тиңсез җыр була.

***

Битарафлык саклый алмый җырлар,
Җырның көче – тынмый яшәүдә.

***

Без болай да артык саран затлар:
Кечерәйтү – безнең йола ул.

***

Яхшы сүз ул һәрчак җанга азык –
Гомер буйлап алга барырга.

***

Язумы бу, язумы бу?
Язганың синең әгәр
Булса бу яздан салкын!
Көчәнсәң дә син никадәр,
Булмаса синдә ялкын!..

***

Мену түгел, төшү читен.

***

Иң бирелеп сөйгән кешеңә дә
Бөтенләй үк бетмә бирелеп.
Серең беткәч, сиңа беркемгә дә
Кызыгың юк кызыгып килерлек.

***

Бу тормышның төрле чагы була, иптәш:
Һичкемең дә әгәр калмаса,
Син кычкырып үзең белән үзең сөйләш,
Ялган тавыш булмас ичмаса...

Текстны журналга ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

Рамил Муллин: *«Иң мөһиме – кешенең рухи дөньясы»*

*(Мөслим муниципаль районы башлыгы **Рамил Хәмзә улы Муллин** белән **«**Безнең мирас**»** журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон** әңгәмәсе)*

– Рамил Хәмзович, табиб һөнәрен сайлагансыз, әмма Сезгә халык өчен башка юнәлештә эшләү миссиясе йөкләнгән – хәзерге көндә Мөслим районы хакимияте башлыгы буларак эшләвегезне дәвам итәсез.

– Мөслим – минем туган җирем. Ык буеның әрәмәсендә уйнап, урманнарында җиләк җыеп, кышларын чаңгыда шуып, табигатьне, җирне якыннан күреп-белеп үсү тормышыма үз йогынтысын ясагандыр. Әнием гомер буе кинотеатрда бухгалтер булып эшләде. Әтием – шофер. Әни күңелебездә матурлык тәрбияләде. Өебез һәрвакыт нурлы, ризыгыбыз тәмле булды. Әти берәр җиргә командировкага китсә, әни бөтен өйне «сүтеп кире җыя» торган кеше иде. Йорт эчендә җиһаз аз булса да, ул һәрвакыт нидер үзгәртә, юк кына чүпрәкне дә матур итеп куя иде. Әтием гел алдынгылар сафында булды, аның белән чиксез горурландык. Газетада фотосы чыкса, шатлана, аны кисеп алып, фотосын альбомга куя идек. Ул безне хезмәткә өйрәтеп үстерде.

Укырга кергәч, актив булганмындыр инде, класс командиры, комсорг итеп куйдылар. Музыка мәктәбендә укыдым. Актив тормыш позициясе миңа кече яшьтән үк салынган булгандыр, күрәсең. Ниндидер гаделсезлек, күңелгә ошамаган әйбер күрсәм, беркайчан да курыкмыйча, турысын әйттем. Комсомол бетәр алдыннан узган конференциядә: «Комсомол ул безгә шуны, тегене бирә, аннан да яхшы нәрсә юк, ул безнең якты киләчәк!» – дип чыгалар да ялкынланып сөйлиләр. Ә чынбарлыкта яшьләр комсомолга керергә бик атлыгып тормады, взнос җыю авырлашты. Мин: «Безнең икенче җыелыш булмаска мөмкин! Монда үз-үзебезне мактап утырабыз, комсомолдан берни дә калмады!» – дип чыгыш ясадым. Бу вакытта әнием Мәскәүдән 60 сумга пуловер алып биргән иде. Ә ул чакта аның үз хезмәт хакы – 60 сум! Борчылып сөйли-сөйли, шул пуловерга авторучка белән сызып бетергәнмен. Шулай итеп, комсомолдан киттем.

Табиб буласым килде. Әнием гомере буе бронхиаль астма белән чирләде. Аның төннәр буе сырхаулаганын күреп, бик борчыла идем. Табиб булып, әнине дәвалыйсым килде. Хирург булырга омтылдым, санфактан лечфакка күчәргә уйлаган идем, әмма рөхсәт итмәделәр, хыялым барып чыкмады. Сәламәтлек саклау эшен оештыру буенча махсус түгәрәкләргә йөреп, шушы юнәлештә эшләргә уйладым. Укуны бетергәч, миңа Мөслимдәге санэпидстанцияне җитәкләргә тәкъдим иттеләр.

«Иманлы кешеләрнең нәселен дәвам итү күңелемә бик ятышлы»

– Без үскәндә Мөслим һәм Актаныш районнарында динне әлләни тыю булмады. Хәзер район, дәүләт җитәкчеләре дә дингә тартыла. Сезне ислам динен кайтаруга зур өлеш керткән шәхес буларак беләбез. Моңа нәрсә этәргеч бирде?

– Дингә кайту киртәле юл булды. Беренчедән, мин һәрвакыт үз алдыма: «Ни өчен яшим? Яшәүнең мәгънәсе нәрсәдә? Нинди бурычларым бар?» – дигән сораулар куя идем. Галәм, табигать өстен канун буенча хәрәкәтләнә. Дөрес, без дарвинизм белән тәрбияләндек, әмма аның асылына тирәнрәк төшенсәк, бик күп каршылыклар барлыгын күрәбез.

Икенчедән, Аллаһыга шөкер, әбиләрем динле иде. Әти ягыннан әбием һәрвакыт намазда булды. Аның әйткән серле сүзләрен кабатларга, истә калдырырга тырыша идем. Ул намазын безгә кунакка килгәндә дә калдырмады. Әби намазга басса, өйдә тынлык урнаша: сөйләшергә, тавыш чыгарырга ярамый. Кечкенәдән аның намаз укыганын карап торырга яраттым, бу сихри күренеш күңелемә бик хуш килә иде. Репрессиягә дучар булган бабаемның да намазын калдырмаганын беләм, әмма әбием бу турыда бик ачылып сөйләргә яратмый иде. Иманлы кешеләрнең нәселен дәвам итү күңелемә бик ятышлы. Боларның барысының да миңа тәэсире булгандыр.

1990 нчы елларда мәчетләр салынды, нур иңде. 30 яшь тулгандарак, эзләнә башладым. Йосыф, Рамил һәм Госман хәзрәтләргә рәхмәтлемен. Рәшидә абыстай Исхакыйның бездә кунакта булуын яхшы хәтерлим. Аның намазның мөһимлеге турында сөйләгәне әле дә истә. Сеңлемнең туен хәмерсез, хәләл итеп уздыру да минем өчен зур ачыш булды.

Тормышта рухи яктан бер почмакка барып терәлгәч, Аллаһының рәхмәте белән, җомга көнне уразага кердем һәм беренче намазымны укыдым. Әниемә шылтыратып: «Беренче намазымны укыдым», – дидем. Ул да намазда, уразада булуын әйтте. Шулай итеп, күңелләребез тулып, елашып,

бер-беребезне котладык. Хәзерге көндә, Аллаһыга шөкер, балаларым һәм тормыш иптәшем дә намазда, туганнарым да дингә тартылып килә.

Дин – кешелекнең, тормышның нигезе. Татар халкы дингә килми, ә дингә кайта. Чөнки милләтебезнең үткәне иманлы, әби-бабаларыбыздан калган бай дини мирасыбыз бар! Чыннан да, дингә кайткач, тормышта бик күп үзгәрешләр булды. Хәзерге көнге тормышка караш икенче. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, күп нәрсәгә Коръән тәгълиматы аша карыйм, гыйлем алуны дәвам итәм. Дөрес, барысы да җиңел генә бара дип булмый. Аллаһы Тәгалә сынауларын биреп тора, һәр заманның үз борчу-мәшәкате, шатлыгы бар.

«Кеше хакы, җәмгыять, милләт хакы дигән төшенчәләр бар!»

– Тормыш кискен үзгәрде. Без үскәндә аэропортлар булса да, юлсызлык үзәккә үтте. Пучы белән Олы Имән арасыннан бара алмыйча азаплана идек. Ул заманнарда күңелләр чиста, идеология бар иде. Хәзер икенче чор башланды: кешеләр бер-берсеннән, хәтта туганнар да бер-берсеннән читләшә башлады. Күзәтү һәм тормыш тәҗрибәгездән чыгып, бу мәсьәләләргә фикерегез ничек?

– Һәр чорның уңай һәм тискәре яклары бар. Ни өчен безгә бүген тарих кирәк? Кешенең тормыш рәвеше үзгәрсә дә, аның эчке дөньясы шул ук. Кайсы гына гасыр әдәбиятын укысак та, мәңгелек төшенчәләр белән очрашабыз: мәхәббәт, нәфрәт, куаныч, югалту, сугыш... Бу табигый дә, кешенең эчке дөньясы үзгәрми, тышкы тирәлеге генә үзгәрә. Хәзерге татар дөньясын 20 нче йөз башындагы милли тормыш белән чагыштырырга яраталар. Татар милли киеме дип Тукайлар заманындагы киемне атыйлар. Әмма

аңа кадәр киемнәр башкача булган, Тукайлар яңача – җәдитчә, европача киенеп йөргәннәр бит! Аннан элеккеге фотосурәтләрне карасак, киенү рәвешләре бөтенләй башкача икәнен күрәсең. Киемнәр үзгәрсә дә, кешенең эчке дөньясы, ихтыяҗлары кала... Байлар затлы киенгән, иганәчелек хәрәкәтен оештырып җибәргән, мәчет-мәдрәсәләр, хастаханәләрне үз акчаларына салган һәм тоткан, рухи, мәдәни дөньяны баеткан. Әмма гади халыкның 1960 нчы елларга кадәрге тормышына карыйбыз икән, аның бар яшәве ризык һәм кием табу өчен җан асраудан гыйбарәт булуына төшенәсең...

Мөслим төрле вакытларны кичерде. 1970 нче еллар гөрләп торган төзелешләр чоры, бу елларда балалар күп туа иде. Мөслим районында елына бер меңгә якын бала туган. Бүген елына 150-160 бала туса, куанабыз. Элек бер мәктәпне генә 70 бала тәмамласа, хәзер район буенча аларның саны 70кә чак тула. Элек шуларның 80 проценты авылда калса, хәзер калучылары бармак белән генә санарлык. Районда иң кадерлесе – кеше. Аның биредә – кендек каны тамган туган җирендә калуы киләчәгебез өчен бик мөһим.

Колхозларның гөрләп торган вакыты... Бу заманнар әтиләр буынына бик якын. Ул аларның яшьлеге, матур хатирәләре... Юл булмаса да, интегеп, җәяү йөреп укысалар да, бу бик күңелле чак булган, чөнки кеше

күп, күмәклек бар, идеология көчле. Әлеге тәрбия кешенең канына бик нык сеңгән. Идеологик үсеш аларга эшләргә дә мөмкинлек биргән. Мин, 90-100 яшьлек әби-бабайларны туган көннәре белән котларга баргач, элеккеге тормышны сорашырга яратам. Алар ачлык-ялангачлык, юлсызлык шартларында сәнәк, көрәкләр белән, чабата яки кәлүшләр киеп, искиткеч зур хезмәт куйган. Шушы халыкны күтәрергә, күңелләрендә өмет уятырга нинди рухият, идеологик көч кирәк булган бит! Бу аларны җиңүләргә ирешергә, зур шәһәрләр төзергә, мул уңыш алырга илһамландырган. Идеологиянең массаларга йогынтысы бүгенге заман күзлегеннән тикшерелмәгән зур мирас әле ул! Моны өйрәнеп, хәзерге тормышта да кулланышка кертәсе иде. Халыкның, дәүләтчелекнең идеологик кыйбласы булмаса, ул таралып бетә. Тел, гореф-гадәт кенә аңа нигез була алмый.

Дөрес, совет чорының аяныч яклары да бик күп! 1930 нчы еллардагы күмәкләштерү сәясәтен генә карагыз. Күпме кеше сөргенгә озатылган! Алар авылның иң тырыш, үзенең ихатасын зур хезмәт куеп күтәргән кешеләре бит югыйсә! Бүгенге фермерлар бит инде алар! Кешене куркыту, бушка эшләтү, репрессияләр, азатлыкны, дин иреген, хөр фикерләүне тыю, таякка эшләтү, рәнҗетү һәм янаулар булган... Аллаһы Тәгалә күпме хезмәт куйган колхозларны ни сәбәпле юкка чыгарды соң? Болар барысы да – рәнҗетелгәннәрнең күз яше, каргышы нәтиҗәсе. Кеше хакына керү, килешүләрне үтәмәү дә булгандыр... Кеше хакы, җәмгыять, милләт хакы дигән төшенчәләр бар! Алар – кагылгысыз! Без, үткәннәрнең тискәре якларын онытмыйча, яхшыларыннан үрнәк алырга тиеш. Ә яхшы яклары күп иде...

Әнием коймак пешерсә, бер таба – өйгә, бер таба урамга, дусларга иде. Икенчебез өчпочмак алып чыга. Аз иде, әмма уртак булды, чөнки күңел киң иде. «Якты йөзең, такта чәең булса, шул җитә!» – диләр иде әниләр. Өстәлләр мул түгел, әмма кешеләр бер-берсен кунакка чакыра. Болар барысы да туганлык, дуслык җебен, күмәклекне ныгытуга хезмәт итте, халыкны берләштерде. Дөрес, хәзерге өстәлләр бермә-бер мулрак, әмма ихласлык кимеде, чын күңелдән җыелып күрешүләр сирәгәйде. Табыннар мул, йортлар әйбәт, ләкин кешеләрдән зар-интизарны күбрәк ишетәбез. Ни өчен зарлана? Чөнки шөкер итми! Шөкер итми икән, аның күңеле тыныч булмый. Күңеле тыныч түгел икән, җаны да тыныч түгел. Җаны тыныч булмагач – ул бәхетсез! Мал бар, әмма тынычлык юк. Кеше һәрвакыт нәрсәдер эзли, аңа һаман нидер җитми... Мин авыллардагы әби-бабайлар янында еш булам. Алар бүгенге мул тормышка шөкер кылалар. Аллаһы Тәгалә: ***«Шөкер кылыгыз, мин өстәрмен»,*** – ди. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисен искә төшерик: ***«Иртән торгач тәнең сау, күңелең тыныч, көнлек ризыгың булса, бөтен дөнья синең аяк астыңда».*** Хәзерге нигъмәтләргә шөкер итәбез икән, әлхәмдүлилләһ, күп эшләр башкарырга мөмкинлек бар. Безгә, үзебезне табып, уйланырга һәм гыйбрәт алырга кирәк.

«Без матур җирдә бәхетле яшәргә тиеш!»

– Җитәкче буларак, авылларны да, район үзәген дә яхшыртасыгыз килә. Элек Мөслим урамнары башкача иде: кирәкмәгән корылмалар, тәртипсезлек... Җиде ел элек бирегә җитәкче булып килеп төшу белән, Сез ни турында уйландыгыз?

– «ВАМИН» таралган вакыт. «Мөслим» агрофирмасы да таралды. Җирнең – 60, малның 70 проценты алар кулында иде. Аларның банкротлыкка чыгуы район таралуга тиң булды. Җидешәр ел сөрелмәгән басулар бар иде, юл җимерек, инфраструктура кайгыртылмаган. Иң аянычы – гөрләп торган фермалар юкка чыкты.

Заманында Мөслим халкы тормышын мал карап алып барды. Ике меңгә якын мөгезле эре терлек кенә бар иде биредә. Терлек асрамый башлагач, абзар һәм сарайлар каралмый башлады, анда тирес, чүп җыелды. Ул чорда яшьләрнең берсе дә Мөслимдә калырга теләмәде. Эш юк. Җир 400 мең тора. Югыйсә, Россиядә җирдән күп нәрсә юк, нигә буш җирне шул бәягә сатып алырга?!

Эшне нидән башларга? Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич берничә район җитәкчесен Сингапурга җибәрде. Шунысы гаҗәпләндерде: хәзерге Сингапур – илле ел эчендә юклыктан гөлбакча ясаган дәүләт. Илнең бернинди табигый байлыгы, хәтта эчәр суы да юк! Ли Куан Ю, җитәкче булып килгәннән соң, себерке күтәреп, Сингапурны җыештыра башлый, агач утырта. Америкадагы депрессия елларында да юллар төзиләр, урамнарны җыештыралар. Санитар табиб буларак, мине Мөслимнең һәм авылларның тышкы кыяфәте бик борчыды. 70 авылга 350 зур чүплек бар иде. Туган авылым бер урамлы Каенсазда гына да ике чүплек! Мөслимнең ишегалларыннан 3500 КамАЗ чүп чыгардык. Халыкның иске сарайларны сүттерәсе килми. Иң әүвәл бер ишегалдын җыештырып күрсәттек. Хәзерге көндә күпкатлы йортларның ишегалдында бер генә сарай да калмады. Аларның урынын матур ишегаллары, балалар мәйданчыклары алды.

Авыл эчләрендә үзара салым акчасына 160 км юл салынды. Су проекты гамәлгә ашырылды. Мөслимгә, авылларга чишмә суы китердек. 7-8 мең кеше яши торган Мөслимнең зиратын чистартырга ике меңнән артык кеше чыкты. Әле кайчан гына аларның эчендә керерлек түгел иде. Мөслимдә бер тротуар да юк иде, хәзер алар эшләнде, яңалары салынып килә. Яктырткычларның саны ун мәртәбә артты. Балалар бакчалары, мәктәпләр, хастаханә төзекләндерелде, клубларга тотындык. Парк һәм скверлар булдырылды, агачлар утыртылды, су чистарту корылмасы төзелде. Мөслим матурлык үзәгенә әйләнде. Иске коймаларны сүтеп аттык, кабельләрне җир астына төшердек, урам бәдрәфләре урынына яңа, заманча туалетлар эшләнде. Мине кайчакта, тәнкыйтьләп: «Нигә матурлыкка ул кадәр игътибар итәргә кирәк инде?!» – диләр. Беренчедән, Аллаһ – Җәмил, бу сүз күркәм дигән мәгънәне аңлата. Без матур җирдә бәхетле яшәргә тиеш.

Икенчедән, яңа эшләнгән балалар мәйданчыгында бер төркем бала уйнап йөри. Алар инде элекке пычраклыкны белмәячәкләр, матурлыкны күреп үсәчәкләр. Ә матурлыкны күреп үскән бала киләчәктә дә гүзәллеккә омтылачак. Аларга дөрес нәсыйхәт тә бирелсә, безнең киләчәгебез өметле.

Өченчедән, матурлык инвестицияләр җәлеп итте. «Август» агрокомпаниясе җитәкчеләре килгәч, мин аларга Мөслимне, төзекләндерелгән объектларны күрсәттем. Алар үз ке-

«Без матур җирдә бәхетле яшәргә тиеш!»

Рамил Муллин

Бүгенге Мөслим күренешләре

Мөслимлеләр кагыйдәләре

1. Туган ягыңның тарихын бел, халкына хезмәт ит!
2. Якташларың белән горурлан, район даның үстер!
3. Һәрчак белемгә омтыл, заманнан артта калма!
4. Гореф-гадәтләрне сакла, өлкәннәрне хөрмәт ит!
5. Эчке дөньяңны үстер, рухыңны бает!
6. Мәрхәмәтле бул, игелек кыл!
7. Мохтаҗларга ярдәм ит, хәйриячелеккә үз өлешеңне керт!
8. Һәр гамәлең ихлас күңелдән булсын!
9. Җиденче буынга кадәр нәсел шәҗәрәңне бел!
10. Әти-әниеңне хөрмәт ит!
11. Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!
12. Ныклы гаилә төзе, балаларыңа туган телне өйрәт!
13. Яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бир, яхшы үрнәк бул!
14. Сәламәтлегеңне сакла, сәламәт яшәү рәвеше алып бар!
15. Табигатьне ярат, чисталыкны сакла!

шеләренә: «Мөслимлеләр үзәкне ничек төзегән, безнең максат биредә менә шундый матур авыл хуҗалыгы булдыру», – диде. Бу егетләрнең Россиянең башка район үзәкләрендә мондый матурлыкны күргәне булмаган! Шулай итеп, Мөслим халкының тырыш, булдыклы, эшчән икәнен белделәр. Техникага гына да 2 млрд сум инвестиция керде. Хәзерге көндә Уразмәттә ике млрд ярымлык роботлаштырылган ферма төзиләр. Бу матурлыкка керткән көчебезнең инвестициясе түгелмени?! «Намус», «Туган як» агрофирмасы да инвестицияләр кертте. Аларда Мөслимдә эшләргә була дигән ышаныч һәм максат барлыкка килде.

Илгиз Исламов җитәкчелегендәге «Агромастер» заводы тракторлар җитештерә башлады. Бүген Россиядә мондый өч кенә завод бар. Шуларның берсе – Мөслимдә. Алар 250ләп агрегат җитештерә, чәчкечләрен Россиянең төрле төбәкләреннән һәм хәтта чит илләрдән дә сатып алалар. Бу – зур горурлык. Россиядә грипка каршы вакцина ясый торган бер генә завод бар. Шуларга чималның яртысы Беларусьта җитештерелсә, яртысы Дамир Шәңгәрәев җитәклəгән заводта – тавык эмбрионыннан Мөслимдә ясала. Элекке фермаларда кошчылык үсеш алды. Бу эшләр үзебезнең егетләр – мөслимлеләр кулында.

Дөрес, җиребезнең күп өлешен читләр эшкәртә дип бераз борчылабыз. ИншәАллаһ, шулардан үрнәк алып, үзебезнекеләр дә үсәрләр. Шөкер, яхшы гына эшләүче крестьян-фермер хуҗалыклары бар. Игенчелек академиясе оештырып җибәрдек. Балалар күреп үссеннәр: бүгенге авыл хуҗалыгы инде – «ДТ» тракторы түгел, ә заманча, комфортлы авыл хуҗалыгы машиналары, югары технология. Хәзер кеше интектерергә кирәкми, максатыбыз – аз көч кулланып, мул табыш алу.

Аллаһыга шөкер, җиребез, табигатебез, тәҗрибәле өлкәннәребез, яшьләребез һәм бай тарихыбыз бар. Безгә боларның барысын бергә туплап, дөрес сәясәт алып барасы гына кала. Моның өчен мин Президентыбызга, министрларга, эшкуарларга һәм дусларыма, хезмәттәшләремә бик рәхмәтле. Күп эшләр уртак хезмәтнең, күмәк тырышлыкның матур нәтиҗәсе. Әмма иң мөһиме – кешенең рухи дөньясы!

«Музей – зур тәрбия, мәгариф учагы!»

– Мөслимдә әдәбиятка, җырга һәм, гомумән, сәнгатькә игътибар артты. Язучылар очрашуларга бик теләп кайталар...

– Археолог Альберт Борһанов җитәкчелегендә казу эшләрен оештырдык. Балаларның күңелендә: «Мөслим җирендә борынгы заманнан ук кешеләр яшәгән икән, нигә бүген монда калмаска, ә читкә китәргә кирәк», – дигән уй тусын иде. Тарих, тел, әдәбият, мәдәният, мәгариф, дин бергә кушылса гына көчле. Ә аларның барысын да шушы җир – Мөслим туфрагы берләштерергә тиеш. Олпат әдипләребезнең, шәхесләребезнең сүзен, акылын балаларның аңында калдырырга кирәк.

Мин эшли башлаганда районда ике генә бию түгәрәге бар иде, бүген аларның саны егермедән артык. Һәр мәктәптә театр түгәрәкләре эшли. Тормыш – театр ул. Әгәр дә син бу тормышта үз ролеңне тапмасаң, һәрвакыт пәрдә артында булачаксың. Ә безгә һәрчак сәхнәдә, алдынгылар сафында булырга кирәк!

Мәктәпләрнең үз музее бар. Музей иске комган җыю гына түгел! Ул – зур тәрбия чарасы, мәгариф учагы! Лицей музеена барасыз икән, Мөслимнән чыккан галимнәр белән таныша аласыз. Тукай мәктәбендә – мәгърифәт, гимназиядә – хезмәттә уңышка ирешкән шәхесләр музее. «Әдәбият һәм сәнгать музее» мәдәният йортында заманча итеп эшләнде. Тиздән өр-яңа музей – «Батырлар йорты»н ачабыз.

«Райондагы балалар татарча сөйләшсен, иманлы булсыннар иде!»

– Бөтенроссия авыл Сабан туе да быел беренче мәртәбә Татарстанда – Мөслимдә узачак...

– Сабан туе искиткеч матур урында – Ык елгасы үзәнлегендәге әрәмәдә үтәчәк. Әрәмә – тормышыма бәйле мөһим урын. Мин бик авыр туганмын. Әниемнең тулгагы бик озак барган. Мин туганнан соң, әтием, әрәмәгә барып, чәчәкләр җыеп кайткан. Вакытлар узу белән, әрәмәгә маллар керде, аннан әрсез америка чаганы басты, шомырт та калмады, чүплек тә шунда иде, юынтык сулар да бирегә агып төште. Хәзер бу урын яңадан табигатьнең гүзәл почмагына әйләнде: ял зоналары, амфитеатр, ипподром, бассейн, ясалма күлләр булдырылды. Әрәмәне халыкка элекке хәлендә кайтару күптәнге хыялым иде. Әйткәнемчә, бу урын – әтиемнең әниемә хөрмәте, ихтирамы һәм мәхәббәтенең символы.

Райондашларым үз җирен яратып, мәдәниятен, тарихын, гореф-гадәтләрен белеп тәрбияләнсә, әлбәттә, киләчәгебез өметле булачак! Ни өчен Сабан туеның прологында 400гә якын баланы катнаштырабыз? Чөнки үз баласы катнашкан Сабан туе, беренчедән, бала өчен кадерле, икенчедән, әти-әнисе мәйданга: «Минем улым-кызым катнаша бит!» – дип килә. Аның өчен бәйрәм аеруча кадерле булачак, чөнки ул – аның мирасы, аның традициясе һәм аның киләчәге!

Рус телен ихтирам итәм, әмма иң зур теләгем – үз балаларым һәм райондагы балалар татарча сөйләшсен, иманлы булсыннар иде! ■

Безнең мирас №7 июль 2020

Этрусклар – Рим остазлары

Солтан Шәмси



Этрускларның хәрби корабы, б.э.к. IV гасыр

Туран. Төркиләр кузаллавынча, бу алла ир затыннан булырга тиеш иде кебек, чөнки төркиләрне дулкынландыручы Туран атамасы аларның иң борынгы тарихын искә төшерә. Әмма галимнәр, этрускларның Туран алиһәсе мәхәббәт һәм табигатьнең уңыш бирүче көчләрен гәүдәләндерүче зат саналган, дип язалар. Грекларда ул Афродита исемен алган, шулай ук мәхәббәт һәм матурлык алиһәсе саналган, имеш. Чыгышы белән Кече Азия төбәгенә карый икән.

Тик без Туран алиһәне грекларның Афродитасына бәйле рәвештә барлыкка килгән дигән фикердә тормыйбыз. Күп халыклар мифологиясендә мәхәббәт, матурлык, табигатьнең тудыручы көчләрен гәүдәләндерүче аллалар бар. Туран – бик борынгы исем. Эзотерика белән тирәнтен шөгыльләнүчеләргә Атлантида халыклары арасында прототураннар *(баба тураннар)* дип аталган кавемнең яшәве билгеле. Атлантида һәлакәте вакытында аларның бер өлеше исән калган булса кирәк. Җир йөзендә диңгез империясе Атлантиданың колонияләре күп булган, бәлки, баба тураннар шул колонияләрнең берсен тәшкил иткәндер. Юкка

Ахыры. Башы журналның 7 нче (2019) санында.

гына, күп заманнар үткәч, Үзәк Азия киңлекләрендә Туран дәүләте барлыкка килмәгәндер. Туран кавеме төркиләрнең борынгы бабалары санала. Шул сәбәпле, телләрендә төрки сүзләр катламы булган этрускларның бер алиһәсе Туран исемен йөртүе бик табигый күренеш.

Туранның этрусклар мифологиясендә бөек урын алып торуын Этрурия территориясендә табылган борынгы бронза көзгенең арткы ягына ясалган сурәт бик ачык күрсәтә. Анда бер төркем алиһәләр сурәтләнгән. Иң өстә (күктә) дүрт ат җигелгән арбада баручы Туран ясалган, аның башында зиннәтле таҗ, муенында шундый ук зиннәтле муенса. Туранны рәссам башка алиһәләрдән киң тасма белән аерып куйган, тасмага этруск хәрефләре белән «Туран» дип язылган. Астарак (җирдә) биш хатын-кыз сурәтләнгән. Уртада итәге тубыгына хәтле төшкән затлы күлмәкле, башына асылташлар белән бизәлгән диадема кигән, кулына көзге тоткан, иңенә затлы сөңге салган Алтайа атлы алиһә матур урындыкта утыра. Аның каршындагы Уни Алтайаның диадемасын төзәтебрәк кую өчен кулын сузган. Уни артында башына затлы шлем кигән Менрва басып тора, кызганычка, хәрефләре ачык булмау сәбәпле, Менрва артындагы алиһәнең исемен укып булмады. Алиһәләрнең игътибары Алтайага юнәлгән. Көзгедә Алтайаны ниндидер җаваплы церемониягә әзерләү күренеше сурәтләнгән булса кирәк. Аның артында кулына ниндидер изге агач ботагы тоткан хатын-кыз баскан. Өстән, биек күктән, шушы алиһәләргә дүрт ат җигелгән арбага баскан Туран карап тора. Дөрес, арба үзе сурәтләнмәгән, тик Туранның ике ягында күренеп торган икешәр ат башы аның арбада басып торуын күзалларга ярдәм итә. Көзгедәге бу сурәттә безнең игътибарны үзәктә утырган Алтайаның исеме җәлеп итә. Димәк, төркиләр өчен изге саналган Алтай атамасы бик борынгы заманнарда этрусклар өчен дә ят исем булмаган. Этрусклардагы Алтайа алиһә исеменең күп заманнар узганнан соң Алтай атамасын йөрткән таулар рәвешендә тарихта калкып чыгуы очраклы факт түгелдер.

Әмма бер сорау җавапсыз кала. Ни өчен этрусклардагы Туран, башка төркиләрдәге кебек, ир затыннан булмыйча, хатын-кыз алиһәгә әйләнгән? Минемчә, моның сәбәбе Туранның Атлантида заманнарында ук билгеле алиһә булуына бәйле. Эш шунда ки, атлантлар Анага табынганнар. «Матриархат – это атлантическое течение. И если 5-я раса *(безгә билгеле дөнья эзотерикада БИШЕНЧЕ РАСА дип атала. –* ***С.Ш.)*** поклонялась Сыну, 4-я раса *(ягъни Атлантида. –* ***С.Ш.)*** поклонялась Матери... и вершиной поклонения было материнство». *(Кут Хуми, Виталий Сердюк. Учение Синтеза. Кн.1, ч.2. М., 2007. – С.4.).* Менә ни өчен ерак заманнарда Туран хатын-кыз сыйфатында булган. БИШЕНЧЕ РАСАДА кешелек дөньясы матриархаттан патриархат дәверенә аяк баскач,



Алиһәләр:
өстә – Туран, аста – Алтайа, Уни, Менрва
һәм исеме укылмаган алиһә

Нептун сурәтләнгән «Диңгез» мозаикасы, Антакьяның археология музееннан.

алиһәне табигый рәвештә ир заты дип кабул итү гадәткә кергән булса кирәк. Төрки халыклар дәүләте дә Туран исемен алган. Күрәсең, шул дәвердә этрусклардагы **ТАНРны** гадәти төрки телдә сөйләшүчеләр **ТӘҢРЕ** дип атый башлаганнардыр.

Туран, Уни кебек, Этрурия шәһәр-дәүләтләрендә патша хакимиятен саклаучы алиһә саналган.

«Туран-алиһәгә Италиягә этрускларга кадәр килеп урнашкан тугандаш халык пеласклар да хөрмәт күрсәткәннәр, корбаннар китергәннәр» икән (Нем., 28).

Нетун – этрусклар мифологиясендә су алласы, аеруча диңгез стихиясе алласы. Грекларда ул – Посейдон, римлыларда Нептун исемен йөрткән. Римга бик якын торган Тибр елгасының икенче ягында урнашкан Вея шәһәренең патшалар династиясенә нигез салучы һәм шулай ук этрускларның Ветулония шәһәренең яклаучысы исәпләнгән. Аңа корбанга шәраб һәм су китергәннәр. Этрускларның сакаллы Нетуны да, римлыларның Нептуны да кулына өч җәпле сәнәк тоткан килеш сурәтләнгән. Римлылар әүвәл диңгезчеләр булмаган, шуңа күрә, Нетунны оста диңгезчеләр булган этрусклардан алып, аны Нептун дип атый башлаганнар.

Нетун-Нептунга корбан бирү «Салация» дип аталган йолага бәйле булган. А.И.Немировский фикеренчә, «Нетун-Нептун аллаларның барлыкка килүе пеласк-этруск халыкларына кайтып кала. Римлылар Салация сүзенең мәгънәсен аңлый алмаганнар. Эш шунда ки, алар Салацияне берәр кеше исеме дип кабул иткәннәр. Римлылар латин теле ярдәмендә сүзнең мәгънәсенә төшенергә тырышканнар. Ә ул пеласк-этруск сүзе «сол» белән ясалган йола атамасы икән. Нетун-Нептунга корбан бирү «сал» дип аталган, ягъни аллага багышлап «корбан китерү» *(ягъни салу. –* ***С.Ш.****)* булып чыга. Шуннан «Салация йоласы» барлыкка килгән. Башка аллаларга корбан биргәндә дә, «сал» сүзе кулланылган» (Нем., 199). Бу сүз татарның корбан «чал-чалу»ына бик якын тора түгелме соң?

Этрусклар, оста диңгезчеләр буларак, римлыларны кораблар төзергә һәм диңгездә йөрергә өйрәткәннәр. Алар тар палубалы сугыш һәм киң палубалы сәүдә кораблары төзегәннәр. Бер үк вакытта пиратлык белән шөгыльләнүдән дә баш тартмаганнар. Юкка гына Этрурия ярларына дулкыннарын каккан диңгез

Тиррен диңгезе дип аталмагандыр. Иберия (Борынгы Испания) ярларына якын урнашкан Балеар утраулары да ул заманда Тиррен утраулары дип аталган. Димәк, этрускларның элекке тиррен атамасы Урта диңгезнең көнбатышында шактый дәһшәтле яңгыраган. «Иберияләге металлургия үзәге Тартесс шәһәренә тирреннар нигез салган» икән (Нем., 32). Иберияда, төрки иберләрдән башка, төрки кабиләләрдән турдетаннар, турдуллар, контестаннар, илергетлар һәм башкалар да яшәгән.

Галимнәр фикеренчә, ибер теле белән этруск теле бер-берсеннән күпмедер аерылган телләр булган. Бу шулай булырга тиеш тә. Этруск теле шактый үзенчәлекле, әмма гадәти төрки телдән тайпылган тел булса да, анда төрки сүзләр катламы сакланып калган.

Күреп торабыз, Нетун-Нептун аллаларның килеп чыгышы безне әллә кайларга алып кереп китте. Оста диңгезчеләр саналган этрускларның ничек инде үз диңгез алласы Нетун булмасын ди?!. Аларның мифологиясе өчен бу бик табигый күренеш ләбаса!

Нортия (Нурфия) – этрусклар мифологиясендә бу алиһә адәм балаларының язмышын кайгыртучы буларак билгеле. Вольсиния шәһәрендә аңа багышланган гыйбадәтханә дә булган. Анда һәр елның азагында диварга кадак кагу йоласы үткәрелгән. Бу йола язмыштан узмыш юк дигәнне аңлаткан, ягъни үз язмышыңа риза булып яшәргә өндәгән. Этрускларның бронза көзгеләренең арткы ягында бер кулына – кадак, икенче кулына чүкеч тоткан шәрә яшь хатын рәвешендә Нортия алиһә сурәтләнгән. Бу йолада башка алиһәләр дә катнашкан. Ел азагында диварга кадак кагу бер үк вакытта узган елның төгәлләнүен, күктә яңа елның йолдызы кабынуын да аңлаткан. Этрускларда иң зур вакыт арасы гасыр саналган, тик гасыр хәзерге замандагыча төп-төгәл йөз елны тәшкил итмәгән, ә кеше гомере озынлыгы белән үлчәнгән. Шулай ук һәр кешенең үз «гасыры» булган, кешеләрнең «гасыры» бер-берсенә туры килмәгән. Гомумән, этрускларда вакытны үлчәү мәсьәләсендә төрле карашлар яшәгән. Грек тарихчысы һәм философы Плутарх *(б.э.ның 50-120 нче еллар тирәсендә яши)* фикеренчә, этрускларның тарихы б.э.к. 968 елдан башланган. Бәлки, тирреннар *(этрусклар)* Италиягә Кече Азиядән шушы елда күчеп килгәннәрдер? Бу мәсьәләдә дә ачыклык юк.

Кеше язмышын кайгыртучы Нортия алиһәнең гыйбадәтханә диварына вакыт кадагын кагучы булуы символик мәгънәгә ия.

Автордан

Бер ел дәвамында басылып килгән бу хезмәт укучыларда зур кызыксыну уятты. Язучы-каләмдәшләрем дә төркиләргә бәйле этрусклар тарихына битараф калмадылар, күрешкәндә, бу тема турында сүз кузгатып, фикерләрен әйткәләп, кызыксынуларын белдереп тордылар. «Безнең мирас» редакциясе шушы көнгә хәтле тарих фәнендә ачылып җитмәгән серле бер тема булып килгән этрусклар цивилизациясенең төркиләр белән бәйләнешен тирәнтен аңлап эш итте, шул сәбәпле, хезмәтнең шактый өлеше журнал битләрендә урын алды. Моның өчен журнал җитәкчелегенә зур рәхмәтемне белдерәм! Бу хезмәт киләчәктә, бәлки, китап булып та басылып чыгар. Ул чакта укучылар аның икенче яртысы белән дә таныша алырлар. ■

Безнең мирас №7 июль 2020

МАМАДЫШ РАЙОНЫ ОЕШУГА – 90 ЕЛ!

Мамадышым – газиз җирем!

Фирая Мингалиева

*Мамадыш ягы – Татарстандагы борынгы тарихи төбәкләрнең берсе. Журналистлар, язучылар мәшһүр рус язучысы **Лев Николаевич Толстойның: «Сез ышанмассыз, Неапольдә, Римда, Венециядә яшәгәнче, мин Мамадышта яшәр идем»**, – дигән сүзләрен мисалга китерәләр һәм бу якның гүзәл табигате, данлы тарихы турында язалар. Минемчә, ул безнең төбәкнең матур табигатен генә түгел, аның тырыш һәм эшчән кешеләрен дә күз уңында тоткандыр. Мамадыш урынындагы авыл 1391 елга карый. Шәһәр дәрәҗәсен Мамадышка 1781 елда Екатерина патшабикә бирә. Гербындагы яшел тирәлеккә урнаштырылган алтын көлтә, ике көмеш урак аның борынгыдан ук мул тормышлы, бай төбәк булуы турында сөйли.*

Районыбыз республиканың төньяк өлешенә урнашкан, ул Киров өлкәсе һәм Удмуртия белән чиктәш. Район 2,6 мең квадрат километр мәйдан били һәм республикада иң зур районнардан санала. Аның төньяк һәм көнчыгыш чикләрен Нократ һәм Чулман елгалары юа. Шулай булгач, бездә табигый болыннар, күлләр ифрат та күп. Елгалар белән бергә, алар халыкның яшәешенә булышалар. Балык тоту һәм үрчетү, җәмәгать һәм шәхси хуҗалыклар өчен печән әзерләү, күңелле һәм файдалы ял итү өчен, бездә мөмкинлекләр чиксез.

Төбәгебез гүзәллеге, географик яктан уңай урнашуы белән аерылып тора. Риваятьләргә караганда, бирегә ял итәргә ханбикә Сөембикә һәм Сафа Гәрәй килә торган булган. Кайчандыр Гәрәй хан утары булган авыл хәзер Грахань дип атала. Урта Кирмән авылы янында меңьеллык тарихлы Ханнар зираты бүгенге көндә дә саклана.

Төбәкнең язмышы тарихи шәхесләргә нык бәйләнгән. 1774-1775 еллардагы крестьян сугышы вакытында шәһәребез аша Емельян Пугачев үзе узган. Революционерка Вера Фигнер Келәүш урманчылыгында үзенең яшьлек елларын уздырган. Безнең егетләр данлыклы «Варяг», «Стерегущий», «Аврора» крейсерларында хезмәт иткән. «Мултан эше» буенча биредә язучы һәм публицист В.Г.Короленко булган, бөек Салтыков-Щедрин үз әсәрләренең прототипларын Мамадышта тапкан. Бездә Советлар Союзы маршалы Василий Чуйков, Надежда Крупская һәм Лев Троцкий эзләрен дә табарга мөмкин.

Билгеле, район тарихы, аның халкы узган данлы юл, исемнәре илебезгә таралган галимнәр һәм хәрбиләр, язучылар һәм шагыйрьләр, композиторлар, артистлар турында күп һәм озак сөйләргә мөмкин. Районыбыз журналистлары, газета редакторы, язучы Рафаил Газизов җитәкчелегендә, «Мамадышым – язмышым». Мамадыш – судьба моя» дигән зур күләмле китап чыгарды. Анда данлыклы кешеләребез турында бәйнә-бәйнә сөйләнелә.

Мондагы һәйкәлләрдә сугышта шәһит киткәннәрнең, Советлар Союзы Геройлары Гафият Нигъмәтуллин, Михаил Просвирнин, Иван Максимов, Михаил Москвин, Дан орденнарының тулы кавалеры Миннәхмәт Әүхәдиев, сугышта 8 улын югалткан Фатыйха Әхмәдиева, язучы Шәйхи Маннур, композитор Фәрит Яруллиннарның рухы яши.

Язучы һәм шагыйрьләребез Шәйхи Маннур, Зиннур Мансуров, Рәис Даутов, Шаһинур Мостафин, Әхмәт Гадел, Ринат Мөхәммәдиев, Әлфәт Закирҗанов, Мансур Сафин, Марат Закир, Вәрис Гали, Локман Закир, Рәсимә Галиева, Сәяф Шәйхи, Владимир Калашников, Юлия Аполонова, Гөлнур Васыйлова, Амур Фәлах, Мәнүсә Шәйдуллина, Рафаил Газизов, Нурзия Мирхазова, Фәрит Имамов, Равил Мостафин бар. Галимнәр – Камил Вәлиев, Раиф Васыйлов, Василий Кибяков, язучы Мәхмүт Бөдәйли, композиторлар Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар, Россиянең композиторлар берлеге рәисе Вячеслав Казенин, артистлар – Хәлил Мәхмүтов, Шәмси Закир, җырчылар – Мәрьям Рахманкулова, Миңгол Галиев, Георгий Ибушев, Вячеслав Добрынин, рәссам Нәҗип Нәккаш, бар әсәрләрен Мамадышка багышлаган рәссам Фоат Гарифуллин иҗатлары туган җиребезне дөньяга танытты. Бүгенге яшь буын аларның эшен дәвам итә.

Бөтен мамадышлылар һәм кунаклар яратып төшә торган Нократ яр буендагы беренче пристань, елга буйлап пароходлар һәм баржалар йөри башлагач, унтугызынчы гасыр башында оештырыла. Узган гасырның җитмешенче еллар ахырына Мәскәү-Уфа трассасы салынып, Нократ аша күпер файдалануга тапшырылганчы, кешеләр аргы якка баржалар белән чыгарыла иде.

Нократ яр буен үзгәртеп кору моннан ундүрт ел элек башланып китте. Ике яруслы итеп ял мәйданчыгы күтәрелде. Хәзерге көндә анда тимердән коелган фигуралы рәшәткәләр, беседкалар, балалар өчен күңел ачу урыннары, төсле музыкалы фонтан, төрле әкият геройларының сыннары урнаштырылды.

Совет урамындагы 11/6 нчы йорт Мамадышның иң өлкән биналарыннан берсе иде. Реконструкция башланганчы, аның ишек өстендә «Саламандра» җәмгыяте тарафыннан 1849 елда иминиятләштерелгән» дигән калай эленеп торды. Ул мещанин Кушпелев тарафыннан төзелгән. Беренче каты – кирпечтән, икенчесе агачтан иде. Октябрь инкыйлабына кадәр анда сыра трактиры һәм кунакханә була. 1925 елда ремонт үткәреп, беренче каты – типографиягә, икенчесе «Пролетариат тавышы», «Киңәшче» кантон газеталары редакцияләренә бирелә. Беренче янкормалар аңа егерменче гасырның алтмышынчы, хәзерге радио һәм телевидение ягы туксанынчы еллар ахырында җиткерелде. 2003 елда бина тулысынча реконструкцияләнде. Агач өлеше сүтеп алынып, бетон блоклардан күтәрелде. Хәзер бинаның икенче катында «ТАТМЕДИА» АҖнең Мамадыш-информ филиалы эшли.

«Реконструкция башланганчы, ишек өстендә «Саламандра» җәмгыяте тарафыннан 1849 елда иминиятләштерелгән» дигән калай эленеп торды. Беренче каты – кирпечтән, икенчесе агачтан иде. Октябрь инкыйлабына кадәр анда сыра трактиры һәм кунакханә була.

Шәйхи Маннур исемендәге «Агымсу» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе Вәрис Галинең эш бүлмәсендә урнашкан. Биредәге кадерле документларда, фоторәсемнәрдә, экспонатларда газетаның беренче мөхәррире – легендар Мәхмүт Бәдәйлидән алып Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Ш.Маннур премиясе лауреаты Зиннур Хәсәновка кадәр булган чор шактый тулы яктыртылган. Замандында шушы газета редакциясендә практика үткән, хезмәт юлларын башлаган шәхесләрдән – күренекле язучы-публицист Айдар Хәлим (Чаллы каласы), балалар өчен мавыктыргыч әсәрләр иҗат итүче әдибә Сәмига Сәүбанова (Казан), танылган журналистлардан – Роза Рәхмәтуллина («Ватаным Татарстан» газетасы), Сөембикә Кашапова («Мәдәни җомга»), Чәчкә Хөснетдинова («КамАЗ»ның «Нур» газетасы) һ.б. турында да сөйләүче кызыклы сәхифәләр бар монда...

Ратуша бинасы, Мамадышка шәһәр статусы бирелгәч, 1785 елда төзелә. 1918 елга кадәр анда Шәһәр Думасы да эшли. Беренче катка сәүдә рәтләре урнашкан була. Каршында базар гөрли, ярминкәләр оештырыла. Аларда сәүдә итәргә Алабугадан, Чистайдан, Казаннан, Рыбинскидан, Түбән Новгородтан да килеп йөргәннәр. Мамадыш районы оештырылган еллардан алып анда янгын часте эшли. Биредә Пионерлар йорты эшләде, бер бүлмәсе «Туган якны өйрәнү музее»на бирелде.

Беренче катында фатирлар да булды, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсе цехлары да урнашкан иде. Тарихи йөзен кайтарып, хәзер анда яңадан сәүдә рәтләре эшли башлады. Шәһәр көнендә каршысында бөек рус язучысы Лев Толстойга һәйкәл ачылды *(фото 20 нче биттә)*.

1963 елда Мамадышта музыка мәктәбе ачыла. Аңа кичке мәктәп бинасының беренче катыннан берничә бүлмә бирәләр. Укучылар һәм сыйныфлар саны артканнан соң, ике катлы агач бина тулысынча мәктәп карамагына күчә. Туксанынчы еллар башында мәктәпкә, яңа бина җиткерү өчен, каршыдагы элекке икенче мәктәпнең тулай торагы урыны бирелде. Аны сүтеп, җирен тигезләүгә, эш тукталды һәм төзелеш 1997 елда гына башланып китте.

Фундаментын күтәреп куюга, эш тагын тукталды һәм ул 2003 елда гына яңадан җанланды. Бүген бишкатлы бинаның беренче катында – район китапханәсе һәм үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, иң өскесендә сәнгать мәктәбенең концертлар залы урнашкан. Мәктәптә Яруллиннар (мәшһүр композиторлар) музее да эшли. Ул хәзер Мамадышның иң матур биналарыннан берсе.

«Бүген бишкатлы бинаның беренче катында – район китапханәсе һәм үзәкләштерелгән китапханәләр системасы, иң өскесендә сәнгать мәктәбенең концертлар залы урнашкан.

Халкыбыз белән таулар да күчерергә мөмкин. Районташларыбыз үз алларына куелган барлык бурычларны үтәргә сәләтле.

Монда район башлыгы Анатолий Петрович Иванов турында аерым әйтеп үтәсем килә. Күпчелек яңалыкны ул тәкъдим итә, башка проектларны да күтәреп ала һәм һәр җирдә эшне башлап, оештырып җибәрүче дә ул. ■

Фирдәвес Зариф

Мамадыш

(Җыр)

Татарымның газиз төбәге син,
Әрәмәле елга, тау ягы.
Туганайлар кунакка йөрешкән
Бәйрәмнәрнең тәүге учагы.

Кушымта:
Мамадышым, диеп, очып кайтам,
Саг(ы)нуымнан куеп канатлар.
Бер күрүдә сиңа гашыйк булып,
Исемеңне меңнәр кабатлар.

Гүзәл табигатьле Мамадышта
Күпме егет үз(е)нә яр тапты.
Кабатланмас мәгърур Нократыңны,
Уңган кызларыңны яратты.
Кушымта.

Гасырларны кичкән тарихың бар,
Күркәм гореф-гадәт, йолалар.
Кендек каны тамган җиргә бер(е)геп,
Яшьләр синдә нигез коралар.

Кушымта:
Мамадышым, диеп, очып кайтам,
Саг(ы)нуымнан куеп канатлар.
Бер күрүдә сиңа гашыйк булып,
Исемеңне меңнәр кабатлар.

Керәшен тамгалары

(Мамадыш районының Владимир авылы мисалында)

Лидия Константинова*

Владимир чиркәве

Керәшеннәрдә әлеге вакытка кадәр игътибардан читтә кала биргән, әмма кыйммәтен һич тә югалтмаган уникаль мирас бар. Ул – нәсел тамгалары. Андый тамгаларны элек «җир тамгасы» дип тә йөрткәннәр.

Нәрсә соң ул «тамга»? «Тамга» ул – нәсел, этник төркем билгесе дигәнне аңлата. Керәшеннәрнең тамгалары Идел буе һәм Үзәк Азиядә булган борынгы рун билгеләренә якын дип саный Г.Макаров. Тарихчы **Ф.Ислаев**: *«Төркиләрнең иң борынгы ыру-кабилә тамгалары VII-VIII гасырларга караган Кытай елъязмаларында теркәлеп калган һәм сакланган. Заманында кытайлылар төньякта яшәүче төрки кабиләләр белән сәүдә эше алып барганнар, алардан хуҗалыкта файдалану, Тан армиясе өчен атлар сатып алганнар. Атның базар бәясе шактый югары исәпләнгән. Сатып алынган атларга тамгалар да сугылган. Кытайлылар төрки кабиләләрдән сатып алынган тамгалы атларны чын мәгънәсендә затлылык, сыйфатлылык билгесе итеп кабул иткәннәр»*, – дип яза.

Башкорт галимнәре төзегән белешмә сүзлектә, илебез территориясендә яшәүче адыгей, абхаз, карачай, балкар, башкорт, казакъ, кыргыз, осетин, нугай, мари халыкларында тамга аеруча киң таралган, дип язылган. Алар төрки халыклардагы «дамга» сүзе монгол телендәге «тамга» сүзеннән килеп чыккан дип саныйлар, аның

* **Константинова Лидия Семеновна** – Мамадыш районы Үсәли урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы.

берничә мәгънәсе булган дип күрсәтәләр. «Келәймә», «печать», «тугра» – шундыйлардан. Алтын Урда чорында «тамга» хан мөһере сугылган документ, акчалата салым мәгънәсенә ия булган. Галимнәр «таможня» сүзенең килеп чыгышын да «тамга» сүзе белән бәйлиләр. Башкортлар үзләре ясаган, җитештергән әйберләргә генә түгел, хәтта мал-туарга да тамга сукканнар.

«Керәшен сүзе» газетасының 1998 елгы 31 август санында **Геннадий Макаров**ның «Нәсел тамгаларыбызны онытмыйк» дигән мәкаләсе басылып чыккан иде. Автор, газета укучыларга мөрәҗәгать итеп, мондый юллар яза: *«Берәү генә яисә берничә кеше генә тамгалар турында мондый җентекле эшне эшләп чыга алмый. Әлегә кадәр алар зиратларда бар, әбик тырышып эзләнсәң, сорашсаң, тамгаларны белүче авыл картларын да табып була әле. Мондый эш мәктәпләрдәге тарих дәресләре өчен бигрәк тә кирәкле һәм саваплы булыр иде. Алдагы көндә исә барлык керәшен авылларының да ыру-нәсел һәм тамга карталарын төзергә мөмкинлек туар дигән өмет бар».*

Мин дә, Үсәли урта мәктәбенең тарих укытучысы буларак, укучыларымны җәлеп итеп, эзләнү эшенә керештем. Владимир авылы тамгалары беркем тарафыннан да барланмаган булып чыкты. Галим Г.Макаров та: «Миңа, кызганычка каршы, Владимир зиратында булырга туры килмәде», – диде.

Башта берничә өлкән кешедән: «Нәсел тамгагызны беләсезме?» – дип сорадык. Кызганыч, уңай җавап ишетмәдек. Үзем әти ягыннан да, әни ягыннан да нәсел тамгаларымны барлаган идем инде. Владимир һәм Албай авылларыннан килеп укучы керәшен балаларына бу сорауны биргәч, алар аптырап калды, ишеткәннәре дә булмаган икән. Шуннан эш башланды инде… Балалар белән Владимир авылы зиратына юл тоттык. Кабергә куелган элекке хачлардан тамгаларны табып, аларны фотога төшердек, кайсы нәселгә нисбәтле булуын ачыкладык, тасвирламаларын өйрәндек.

Владимир авылы зиратында сакланган тамгалар

Тамгалар	Фамилия	Кушамат	Тасвирлама
	Яковлев	Нарпа	Ромб нигезендә ясалган тамга
	Алексеев		Өчпочмак. Төрки халыкларда бу тамганың бөти (талисман) дигән аңлатмасы бар икән
	Кучтраев	Кучтрай	Өчпочмакның уң почмагыннан сызык үтә
	Юзиев		Өчпочмак һәм түбәсендә сызык, ләкин алар тоташмаган
	Юзеев	Йөзи	Түбәсеннән сызылган өчпочмак
	Сапуриннар	Сапура	Өчпочмак тамгасының аскы өлеше ясалмаган, өстендә – сызык
	Саркиевлар	Сәркиләр	Ауган «Г» хәрефен хәтерләтә, кисәү агачы тамгасы
	Кирушин	Кируш темәйләре	Ятып торган «К» хәрефен хәтерләтә яки «түбә» белән тоташкан туры сызык
	Кирушиннар тамгасы булырга мөмкин	Кируш темәйләр, Сукырлар	Ауган «П»ны хәтерләтә, өстендә – сызык
	Романовлар	Романнар	Крест тамгасы өстеннән тагын бер сызык менгән

Тамгалар	Фамилия	Кушамат	Тасвирлама
	Чернов-лар	Чурный-лар	«Ч» һәм «Л». Болар аерым да очрады. Ике як нәселнең тамгалары булуы мөмкин дип нәтиҗә ясадык
	Бачковлар	Наналар, Микушлар, Кәләпүш-ләр	Кач (крест) тамгасы
	Биктяшев-лар	Биктәшләр	Параллель дүрт сызык. Тарак тамгасы дияр өчен аркылы сызыгы юк
	Киевлар	Киев	Ауган «Л». Бу фамилиядәге кешеләр Влади-мирда инде юк

Зираттагы шактый гына тамгаларның инде кайсы нәселгә караганлыгы билгеле түгел. Агач материал черү сәбәпле, кач/хачларда язылган фамилияләрне уку шактый кыен, ә кайберләрендә ул бөтенләй язылмаган.

	«Е» хәрефен хәтерләтә, тарак тамгасы булырга да мөмкин
	Үзебезчә «Z» дип атадык
	«Л» хәрефе, өстендә – сызык
	Өч җәпле сәнәк тамгасы

Тамгалар	Фамилия	Кушамат	Тасвирлама
	Пасыев-лар, Костин-нар, Маловлар, Муке-евлар, Петровлар	Улый, Ибекә, Мулла, Унтый, Мукей, Темәпи (Барысы да Пасы-евлардан чыккан)	Киләп агачы
	Пасыев-ларның Улыйлар нәселен-дәге хачтагы тамга		Киләп агачы, өстә – кач тамгасы

Зөлфәт

Нәсел тамгасы

Ерак бабайлардан килгән тамга,
Безнең тамга – нәсел тамгабыз...
Әткәемә килеп ирешкән ул...
Нәсел тере! Исән калганбыз!

Ул тамганы әткәй өй салганда
Балта белән чапты нигезгә.
– Хәтерләп кал, улым, бу тамганы
һәм яман сүз аңа тигезмә!

Бу тамгада – адәм, фикер, очыш...
Шулар һич тә туктап калмасын!
Тапшыра күр берүк оныкларга –
Бу тамганы сулар агызмасын,
Бу тамганы утлар алмасын!

Сукбай каны түгел – тамырыңда
Борынгыдан килгән кан яна!
Синең өчен нәсел кызармасын,
Син дан өстә шушы тамгага!

	Ике җәпле сәнәк тамгасы, ятып тора торган варианты да очрады
	Әйләнгән «Л» яки «галочка» тамгасы
	Кирушиннар тамгасы булуы да ихтимал
	Каз аягы тамгасы

	Кач тамгасының башка варианты булырга мөмкин
	Трапеция
	«Ш» хәрефен хәтерләтә

Хачларда нәсел тамгасы үрнәкләре



Авылда үз тамгаларын белгән 2-3 кеше табылды. Әмма аларның нәсел тамгалары зираттагы хачларда юк яки алар сакланмаган.

Тамгалар	Фамилия	Кушамат	Тасвирлама
	Васильевлар	Татыйлар	Тарак тамгасына охшаш, тик өскә менеп киткән таяклары бар
	Ивановлар	Элеккеге кушаматлары Гөргөрибанныкылар (Григорий һәм Иван), хәзер Әсүкләр дип йөриләр	Ике җәпле сәнәк
	Юзеев	Йөзи	Өчпочмак һәм аска таба сызык – «чыршы» сурәте дип уйларга мөмкин

Нәсел тамгаларын өйрәнүче егетләр: Виталий Кирушин (сулда), Альберт Юзеев

Укучыларым зираттагы һәр агач кач/хачны диярлек тикшереп чыкты. Виталий Кирушин белән Альберт Юзеев исемле укучыларым үзләренең нәсел тамгаларын тапты. Дөрес, Альбертның әбисе Авдотья (Аудый), Юзеевларның (Йөзиләр) нәсел тамгасын алдан ук белеп, рәсемен ясап җибәргән иде. Моның дөрес икәнен хачлар да раслады. Шулай ук Пасыевлар нәселе дә (язма авторыныкы) кызыклы. Алар арасында үзләренең нәсел агачын булдыру өстендә эшләүчеләр бар. Владимир авылындагы Петров, Малов, Костин, Мукеев фамилияләренең Пасыевлардан чыкканлыгын раслаучы дәлилләр дә табылды. Пасыев фамилиясен йөртүчеләрнең кушаматлары да төрле – Улыйлар, Муллалар, Темәпиләр, Ибекәләр, Питрушлар. Аларның күбесе туганнар икәнлеген белми булып чыкты. Туганлык мәсьәләсенә бәйле сорауларга җавапны кабер хачлары да раслады – тамгалар бер! Димәк, бер нәсел, бер ыру кешеләре.



Хачларда нәсел тамгасы үрнәкләре

***

Күрүебезчә, керәшеннәрдә ыру тамгасы зиратларда хәзерге вакытта да саклана. Ә бу тамгалар белән элек урман, печәнлек, көтүлек һәм басу чикләрен дә билгеләгәннәр. Аларны, гадәттә, чик буендагы имән баганага чокып ясый торган булганнар. Тамгалар төрле документларда, гаризаларда, ярлыкларда да күрсәтелгән. Бу очракта ул имза ролен үтәгән. Пәке, пычак белән уелган нәсел тамгаларының махсус атамалары бар. Әйтик, «бөгәлҗә», «бożра», «тарак», «киләп агачы», «казаяк», «ике-өч җәпле сәнәк», «капка» һ.б.

Кызганыч, тамгаларны туплау эшендә шактый соңга калганбыз икән. Тамгалары булган хач/качлар, агачтан ясалган булу сәбәпле, череп, әкрен генә юкка чыккан. Әмма без Владимир зиратындагы 30лап тамганы барларга өлгердек, шулай итеп, галим Геннадий Макаров мөрәҗәгатенә бер тамчы булса да өлешебезне кертә алдык дип уйлыйбыз.

Шуны да искәртим: алда исемнәрен искә алган укучыларым – Виталий Кирушин белән Альберт Юзеев, шушы тема буенча чыгыш ясап, Татарстан һәм Бөтенроссия укучылар конференцияләреннән җиңү белән кайттылар. Ходай насыйп итсә, алдагы елларда Мамадыш районындагы барлык керәшен тамгаларын да системалы өйрәнергә һәм алар белән «Безнең мирас» журналы укучыларын таныштырырга уйлыйбыз.



1970 нче елларга кадәр зиратларда нәсел тамгасын хачның (кач) аскы өлешенә уеп куя торган булганнар



Чумылдырылырга (чукындырылырга) өлгермәгән сабыйларның каберендә түбәле һәм түбәсез тамгалы казык (багана)

Кулланылган әдәбият:

1. Фәйзелхак И. Атка сугылган тамгалар. – Безнең мирас. – 2016. – №5.

2. Культура народов Башкортостана. Словарь-справочник. Тамга [Электронный ресурс] // Посреди России: информационно-аналитическое издание: [сайт]. [2012]. URL: https://posredi.ru/knb_t_tamga.html

3. Макаров.Г. Нәсел тамгаларыбызны онытмыйк. – Керәшен сүзе. – 1998. – 31 август, 27 ноябрь. ■

Владимир авылы күренеше

Мамадыш крестьяннары бунты

Юрий Карпов*

ВКП(б) ҮК 1929 елның ноябрь пленумындагы резолюциясендә: «Колхозлар хәрәкәте аерым өлкәләргә тоташ коллективизация бурычы куя», – дип белдерә. Әмма ике ай да үтәргә өлгерми, 1930 елның 5 гыйнварында имзаланган «Колхоз төзелешенә дәүләт ярдәме күрсәтү темплары турында»гы карарда авыл хуҗалыгын ил күләмендә тоташ күмәкләштерү таләбе куела. Түбән һәм Урта Идел, Төньяк Кавказ кебек бөртекле культуралар игү өчен иң кулай булган төбәкләрдә күмәкләштерүне 1931 елның язында тәмамларга уйлыйлар. Башка районнарда исә бу эш 1931 яки 1932 елның көзендә төгәлләнергә тиеш була.

ТАССР беренчел районнар исемлегенә кертелми. Шулай итеп республикабыз өчен иң соңгы срок – 1932 елның ахыры билгеләнә. Әмма Татарстан арттан сөйрәлергә күнекмәгән: районнарда күмәк хуҗалыклар төзү процессы котырынган темплар белән үсеш ала. 1929 елның сентябрендә үк Татарстанда күмәкләштерү айлыгы уздырыла. Ә инде октябрьдән декабрьгә кадәр колхозлар саны тугыз мәртәбә арттырыла. Ә 1930 елның мартына ТАССРдагы крестьян хуҗалыкларының 83 проценттан артыгы колхозларга кергән санала.

Күмәкләштерү ярышы Мамадыш кантонын да читләтеп узмый. 100 процент коллективизация артыннан куып, волость комитетларының кайбер вәкилләре турыдантуры: «Колхозга кермәгән кешене атып үтерергә!» – дип, ялкынлы чыгышлар ясый. Телдән сөйләнә торган янаулар бик тиз арада гамәлгә дә күчә. Репрессияләр, күмәк хуҗалыкка кермәгәннәргә салымнарны арттыру, бай күршеләрнең милкен тартып алу кебек эшләр башлана. Болар барысы да мәҗбүриләү, шәхеснең рухын сындыру юлы

* **Юрий Карпов** – төбәкне өйрәнүче. Мамадыш авылының Әҗмәк авылында яши. Авторның узган елгы июль санында Әҗмәк авылы тарихы турындагы мәкаләсе басылып чыккач, укучыларда зур кызыксыну уяткан иде.

белән башкарыла. 1930 елның 2 февралендә ОГПУ рәисе урынбасары Г.Ягоданың «Кулакларны класс буларак юк итү турында»гы боерыгы да чыга.

Большевиклар партиясе, аерым крестьян хуҗалыкларына һөҗүм белән бергә, чиркәүләргә, мәчетләргә һәм руханиларга каршы да көрәш башлый. Бу процесс 1929 елның 8 апрелендә ҮК Президиумы карары дөнья күргәннән соң көчәя.

Әлбәттә, әлеге сәясәт крестьяннар тарафыннан төрле каршылыкларга очрый. Алар тоташ күмәкләштерүгә, чиркәүләрне һәм мәчетләрне ябуга, чаңнарны төшерүгә һәм мәчет манараларын кисүгә кискен ризасызлык белдерә. Бу уңайдан 1929-1930 елларда Мамадыш кантонының Үсәли волостендагы Албай авылы *(Урта Әрнәш дип тә әйтәләр. –* ***Ред.****)* «хатын-кызлары» бунты игътибарга лаек.

1929 елның 1 декабрендә поп Петров, авыл советы карары һәм ярлылар җыелышы нигезендә чиркәүне ябу һәм анда мәктәп ачуга каршылык белдерү максатыннан, үз янына тирә-як авылларның хатын-кызларын чакырып, җыелыш үткәрә. Нәтиҗәдә, 4 авылдан килгән хатын-кызлар авыл советыннан чиркәүне япмауны таләп итә. Әлеге төркем белән сайлау хокукыннан мәхрүм ителгән, ягъни репрессияләнгән батрак Кузьминнның кызы җитәкчелек итә. Волость башкарма комитеты авыл советының чиркәүне ябу турындагы карарын раслаганнан соң, 1930 елның 7 гыйнварында укытучы Комиссаров рәислегендәге комиссия гыйбадәтханәне рәсми рәвештә ябарга килеп җитә. Шулвакыт ике хатын: «Чиркәүне талыйлар! Чиркәүне саттылар!» – дип, шашынып кычкыра башлый. Тиз арада 200 кешелек төркем җыелып, комиссиядән чиркәүгә эленгән кызыл байракны төшертә, ачкычларны тартып ала һәм хатын-кызлардан кизү торучы төркем оештыра. Байракны төшергәндә барлык кешеләр дә тантаналы төстә: «Ура!» – дип кычкыра.

Кызганыч, большевиклар чиркәүне барыбер ябуга ирешә. Аның бинасында озак еллар буе мәктәп һәм клуб эшли. Гыйбадәтханә 1990 елда гына җирле православие җәмәгатьчелегенә кайтарыла.

Совет тарих фәнендә большевиклар режимына каршы төрле чыгышлар, бай крестьяннар, ягъни кулак фетнәләре буларак, гел тискәре яктан гына бәяләнде. Әмма архив документлары моның киресен сөйли. Совет власте үткәргән сәясәткә ул елларда халыкның ярлы-батрак катламы да оешкан төстә каршылык белдергән икән!

Мамадыш кантоны крестьяннары күмәкләштерүгә, мәчет-чиркәүләрне ябуга гына түгел, ә тулаем совет хакимиятенә каршы да чыгышлар ясый. 1930 елның язында Мамадышта, «Долой Советскую власть и коммунистов!» лозунгы астында, кулга алынган крестьяннарны азат итү таләбе белән берничә каршылык хәрәкәте була.

Совет хакимиятенә башка төрле формада да ризасызлык белдерелә. Алар СССР ОГПУы хисапларында «Оештырылган милли контрреволюция» буларак күрсәтелгән. Шул еллардагы документтан өземтә китерик: *«Милли контрреволюция үсешенең төп моментларына түбәндәгеләрне кертергә кирәк: мулла-ишан элементлары шактый активлашкан шартларда кулакларның контрреволюцион эшчәнлеге үсү; кулак-мулла антисовет элементларының күмәкләштерү һәм чәчү эшләренә көчле каршылыгы; баш күтәрүчеләр арту; аларның җирле халыкны массакүләм чыгышларга котыртуы һәм җитәкчелек итүе. Мамадыш кантонында февраль (1930) аенда 23 кулак-антисовет группировкасы бетерелде. Алар үткәрелә торган чараларга каршы тору һәм аларны өзү, авыл активын террорлаштыру, массаларның дини фанатизмын кузгату (дингә һөҗүм турында провокацион имеш-мимешләр тарату) һәм массакүләм коралланган чыгышларга әзерләнү максатын куйганнар иде. Группировкалар легаль булмаган киңәшмәләр оештырды, күрше авыллар, волостьлар һәм хәтта шәһәрләрдәге группировкалар белән элемтә урнаштырды. Бу төркемнәр эшчәнлегенә руханилар актив катнашты...»*

Мамадышта кулак-антисовет төркемнәре булу һәм аларның эшчәнлегендә руханиларның актив катнашуы бу каршылыкларның шактый оешкан төстә барганлыгы турында сөйли. Тулаем алганда, хәл шулкадәр җитди төсмер ала ки, хакимият хәрби көч кулланырга мәҗбүр була.

Илдә социаль киеренкелек көчәйгәч, сәяси вазгыятьне үз кулына ала белгән Сталин авылга һөҗүмне вакытында туктатырга кирәклеген аңлаган булса кирәк. «Правда» газетасының 1930 елгы 2 март санында аның «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләсе һәм 14 мартта ҮКның «Колхоз хәрәкәтендә партия линиясен бозулар белән көрәш турында»гы карары басылып чыга. Бөтен тәртипсезлек, ихтыяри-мәҗбүри күмәкләштерү, җирне, терлекләрне һәм кош-кортларны тартып алу, сугышчан атеизм һәм башка күренешләр җирле җитәкчеләр намусына кайтарып калдырыла. Бу гамәлләр, өлкә комитеты секретареннан башлап волость һәм авыл советлары эшчеләренә кадәрге җитәкчеләрнең «башбаштаклыгы» һәм «уңышлардан башлары әйләнеп китүе»нә бәйләп аңлатыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, крестьяннар, колхозга язылуның ирекле булуына ышанып, күмәк хуҗалыклардан бер-бер артлы кача башлыйлар. 1930 елның 1 октябренә күмәк хуҗалыкларның өлеше ун проценттан да кимрәккә кала.

Сталин мәкаләсе һәм ҮК карарыннан соң, крестьяннарның каршылыгы көчәя генә. Әйтик, 1930 елның 15 мартында Урманчы авылында яшәүче хатын-кызлар кулаклаштыруны туктатуны һәм колхозны таратуны таләп итәләр. Районның күп кенә авылларындагы совет биналарына һәм колхоз хәрәкәте активистларының йортларына ут төртәләр, аларга һөҗүм итәләр, ә кайбер урыннарда эш үтерүгә кадәр барып җитә. 1931 елның язында Малмыжка авылындагы колхоз рәисен, үтереп, күпер астына ташлыйлар. 1932 елның 9 июнь төнендә Уразбахты авыл советы рәисе һәм аның ике улы суела.

Мамадышта авыл халкының каршылык хәрәкәте шактый озак дәвам итә. 1933 елның башында гына хакимиятнең репрессив чаралары һәм хәрбиләрнең «тырышлыгы» нәтиҗәсендә, хәл тотрыклылана. Тышкы яктан күмәкләштерүне танып, көчләүгә буйсынган крестьяннар совет хакимиятенең аграр үзгәртеп кору сәясәтенә эчке яктан, күңел-калебләре белән озак еллар каршы булып калалар, «беркемнеке дә булмаган» җирдә ихтыяри-мәҗбүри генә эшлиләр, усалланалар. Ә иң куркынычы – ярымач халык массалары пәйда була.

Әлбәттә, Мамадыш кантонында узган әлеге процесслар тарихи чыганаклар нигезендә җентекләп өйрәнүне таләп итә. Бу эшне алга таба да дәвам итәргә һәм аның белән «Безнең мирас» укучыларын таныштырырга уйлыйбыз. ■



Албай авылы чиркәвенең күренеше

Тарихи мәгълүмат:

Албай чиркәве 1873 елда Изге Гурий туганлыгы әгъзалары һәм сәүдәгәр И.С.Кривоносов акчасына төзелә. Ул 1874 елның 3 гыйнварында изгеләштерелә. Совет чорында аның бинасында мәктәп һәм клуб эшли. 1998 елда әлеге бина яңадан гыйбадәтханә функциясен башкара башлый.

2013 елның 29 ноябренә каршы төндә чиркәү террорчылар тарафыннан яндырыла. Аның урынына, ТР Президенты Р.Н.Миңнеханов, дәүләт бюджеты һәм иганәчеләрнең ярдәме белән (9 млн сум), өр-яңа чиркәү салына. Гыйбадәтханә 2014 елның 10 июнендә тантаналы төстә ачыла.

безнең мирас №7 июль 2020

Кече Сон мәдрәсәсе тарихы

Рәйсә Муллахмәтова*

Мамадыш районындагы Кече Сон авылы 122 еллык тарихы булган таш мәдрәсә бинасы, күренекле шәхесләре – галим, язучы, табиб Таҗетдин Ялчыгол, өч композитор – Заһидулла, Фәрит һәм Мирсәет Яруллиннар белән дә дан тота.

Мөдәррисләребез

Татар галиме Ризаэддин Фәхреддин үзенең «Асар» дигән хезмәтендә Кече Сон мәдрәсәсенең мөдәррисләрен санап китә. Фәхреддин бине Мөхәммәтсадыйк бине Габдерәфикъ әс-Сони 1803 елда туа. Аксакалларның әйтүенә караганда, Фәхреддин хәзрәт тумышы белән Саба төбәгеннән, Саурыш тирәсендәге авылларның берсеннән була. Ул, Кече Сонда имамлык һәм мөдәррислек итеп, 1868 елда 65 яшендә вафат була. Фәхреддин урынына имам һәм мөдәррис булып улы Юныс кала. Ул 1900 елның 25 маенда 58 яшендә дөньядан китә. Юныстан соң аның улы Госаметдин

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

Настоящее свидѣтельство, съ приложенiемъ надлежащей печати Екатеринбургскаго 3-хъ класснаго II-го городского училища, выдано крестьянину Казанской губернiи Мамадышскаго уѣзда Нижне-Сунской волости деревни Малыхъ Суны Гусамутдину Мухамедъ-Юнусову въ удостовѣренiе того, что онъ успѣшно выдержалъ испытанiе въ знанiи русскаго языка, установленное для кандидатовъ на должность сельскаго муллы. Сентября 29 дн. 1898 года. Гор. Екатеринбургъ.

Подписали: Предсѣдатель Коммиссiи Инспекторъ Надворный Совѣтникъ

Преподаватель Надворный Совѣтникъ С. Виноградовъ

Преподаватель

Казан губернасының Кече Сон авылы крестьяны Госаметдин Мөхәммәдюнысовның Екатеринбургтагы 3 классслы 2 нче шәһәр училищесында рус теленнән имтихан бирүе турындагы таныклык. 1898 ел

СВИДѢТЕЛЬСТВО.

По указу Его Императорскаго Величества, въ присутствiи Оренбургскаго Магометанскаго Духовнаго Собранiя, вслѣдствiе просьбы крестьянина Казанской губернiи Мамадышскаго уѣзда, деревни Малаго-Суна Гусамутдина Мухаметъюнусова согласно 1424 ст. XI тома 1 части (изд. 1896 года) было ему, Мухаметъюнусову учинено испытанiе въ знанiи правилъ магометанской религiи, по которому оказался быть способнымъ: имамъ-хатыпомъ и мударрисомъ. Въ удостовѣренiе чего и выдается ему, Мухаметъюнусову, это свидѣтельство, съ тѣмъ, что оно, показывая о его познанiяхъ, не предоставляетъ ему право исправлять духовныя требы впредь до утвержденiя его въ духовномъ званiи губернскимъ начальствомъ въ приходъ, въ который будетъ выбранъ. Городъ Уфа, Августа „19" дня 1900 года. Гербовымъ сборомъ оплачено.

За Предсѣдателя Оренбургскiй Муфтiй. (Хаджи) Членъ

Члены Ахуны:

У сего печать: И. д. Секретаря

Столоначальникъ

№ 5187

Кече Сон крестьяны Госаметдин Мөхәммәдюнысовка имам-хатыйб һәм мөдәррислек итү хокукы бирә торган таныклык. Документны мөфти Ризаэддин Фәхреддин һәм башка ахуннар имзалаган. 1900 ел, 19 август

* **Рәйсә Абдулла кызы Муллахмәтова** – мәгариф ветераны, туган як тарихын өйрәнүче.
Мәкаләне язганда ТР Милли архивы, авыл халкы сөйләвеннән язып алынган истәлекләр һәм Үсәли авылы тарихчысы М.Фазылов язмалары кулланылды.

Авыл зиратында Ялчыгол бине Мәмәтколга (1721-1786) истәлек ташы кую. Ялчыголның нәсел дәвамчысы Гамир ага Таҗетдинов сөйли.

имам һәм мөдәррис итеп тәгаенләнә. Ул 1870 елның 20 гыйнварында туа һәм 1920 елда бакый дөньяга күчә. Госаметдин хәзрәтнең Мәүләхән һәм Габдерахман исемле уллары кала. Мәдрәсәнең соңгы мөдәррисе Мәүләхән 1984 елда Алма-Ата шәһәрендә вафат була. Икенче улы Габдерахманга исә әтисе үлгәндә нибары бер яшь була. Ул берникадәр вакыт Мамадышта белем ала, укытучы хезмәтен башкара. Аның, 1980 елда Ташкенттан кайтып, әтисенең язма мирасы белән кызыксынуы, авыл картларыннан китаплар алып китүе мәгълүм.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң, Госаметдин хәзрәтнең гаиләсен гомер иткән йортыннан куып чыгаралар. Мәдрәсә белән янәшә урнашкан мәһабәт йортта колхоз идарәсе, авыл советы һәм почта урнаша. Әлеге йорт соңгы елларда гына сүтелә.

Ялчыголлар – Кече Сонның горурлыгы!

Татар укымышлысы, әдип, хәтта медицинага багышланган хезмәтләр дә иҗат иткән Таҗетдин Ялчыгол 1785 еллар тирәсендә Кече Сон мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә. Күп язмаларда Таҗетдиннең әтисе Ялчыгол хәзрәтнең Кече Сон авылында вафат булуы турында әйтелә. Ул – тугыз мәртәбә хаҗда булган күренекле рухани. Хаҗга соңгы баруында үзе белән улы Таҗетдинне дә ала һәм аны Төркиянең Диярбәкер шәһәрендә гыйлем алырга калдыра. Хаҗ кылгач, улын алып, туган якларына кайтырга ниятли. Әмма юлда Ялчыгол хәзрәтнең сәламәтлеге какшый һәм 1785 елның 24 маенда 65 яшендә Кече Сон авылында вафат була, шунда җирләнә. Кече Сон мәдрәсәле авыл булганлыктан, аның зиратында зыялы кешеләрне билгеле урынга дәфен кыла торган булганнар. Ялчыголның нәсел дәвамчылары Гамир ага Таҗетдинов белән Линар Шаһиев, бу урынны өлкәннәр белән ачыклап, киртә белән әйләндереп алдырдылар һәм истәлек билгесе куйдылар.

Хәзрәтнең 22 яшьлек улы Таҗетдин, әтисе васыяте буенча, Кече Сон авылында яшәп, аның каберен өч ел буе зиярәт кылган һәм мәдрәсәдә укыткан, иҗат иткән.

«Уку – энә белән кое казу!»

Агач мәдрәсә яна һәм 1898 елда аның урынына Тәберде Чаллысы авылыннан Шәйдулла оста таштан яңа бина төзи. Мәдрәсәнең иңе – ун, буе егерме метрдан артып китә, дүрт бүлмәсе була. Башмак, кәвеш сала торган бүлмә әчелек дип

аталган. Ике зур бүлмә дәресханә өчен хезмәт иткән. Урам ягындагы бүлмәдә – «Данмулла хәзрәт» *(укымышлы, зыялы мулланы аңлаткан «дамелла» сүзе гади халык телендә «данмулла»га әйләнеп киткән. – **Ред.**)*, эчкесендә хәлфәләр шәкертләргә дәрес биргән. Шул ук эчке зур бүлмәдә шәкертләр өчен кечкенә генә ике бүлмә дә булган. Уртадагы дүртенче бүлмәдә шәкертләр дәрескә әзерләнгәннәр, шунда ук ятып йоклаганнар да. Мендәр, юрган кебек әйберләр стенадагы шүрлеккә куелган. Азык-төлек һәм кием-салымнарны саклау өчен, һәр шәкертнең Кече Сонда аерым йорты булган. Мәдрәсә белән янәшәдәге агач бина шәкертләргә ризык әзерләү, ашау-эчү өчен хезмәт иткән. Биредә Кече Сонның Фәсхетдин карт (аны «Пасый» дип атаганнар) шәкертләргә чәй кайнатып, ашарга пешереп торган, мәдрәсәнең мичләренә яккан. Шәкертләр «Буралы кое»га юынырга йөргәннәр. Агач башмакларны Кече Сонның Рәхимҗан атлы кешесе ясаган.

Мәдрәсә бинасы менә шундый хәлдә иде.

Мәдрәсәдә белем бирү традицион, «кадими» методикага нигезләнеп алып барылган. Программага кертелгән дәресләрнең һәммәсе дә диярлек дини була, дөньяви фәннәр аз укытыла. Әмма Кече Сон мәдрәсәсе заманында иң абруйлы уку йортларыннан исәпләнә. 1898-1908 еллар арасында мәдрәсә шәкертләренең саны 42дән 110га кадәр арта. Укучылар саны күбәюенең сәбәбе – уку-укытуның югары дәрәҗәдә булуы һәм яңа, иркен бина төзелү дип уйларга кирәк. Мәдрәсәдә Мамадыш төбәгеннән, Лаеш, Чистай һәм Спас өязләреннән килеп укыганнар. Азатлык даулап, 1905 елгы шәкертләр хәрәкәтендә катнашкан ике Казан шәкертенең дә, полициядән качып, Кече Сон мәдрәсәсендә белем алганлыгы билгеле. Мәдрәсәне тәмамлаган 300дән артык шәкерт, указ алып, Казан губернасындагы төрле авылларда мулла һәм мәзин вазыйфасын башкарган. Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мәстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» әсәрендә Кече Сон мәдрәсәсендә Фәхреддин хәзрәттән дәресләр алган укымышлы Чистай мулласы Хәсән хәзрәт турында язып үтә.

Мәдрәсәдә укулар сентябрьдә башланган. Апрель ае азагында, мәдрәсә каршындагы «Чүчи» тавы кардан ачыла башлагач, шәкертләр авылларына ялга китә торган булганнар.

Скрипкачы Кәләй карт – табын күрке!

Кече Сон мәдрәсәсе шәкертләре гел уку белән генә мәшгуль булган дип әйтеп булмый. Әлбәттә, алар шаярганнар да, уен-көлкесе дә булган. Хәзрәттән качып, кыска гына күренешле тамашалар оештырып, күңел ачып та алганнар. Гадәттә, тамашада кыз белән егетнең хат алышуы тасвирланган. Кайчакта кечкенә генә чәй мәҗлесе дә әзерләнгән. Табынга сатучы Сабиттан алган 1 тиенлек күмәч, 2 тиенлек хәлвә куелган, Бүре Һади һәм Һидият кибетеннән дә ризыклар алганнар. Әлбәттә, мондый мәҗлесләргә һәрвакыт атаклы музыкант Заһидулла Яруллинның туганы, скрипкачы Кәләй картны чакырганнар. Кәләй бабайның скрипка моңнары

мәҗлесне тагын да ямьләндереп җибәргән. Хәлфәләр арасында да төрлеләре булган. Кайберләре һәр ишеткән сүзне «Данмулла хәзрәт»кә җиткереп торган.

Данмулла хәзрәт Кече Сон зиратында җирләнгән. Истәлекләргә караганда, ул бик укымышлы, яхшы күңелле кеше булган. Аны җирләргә төрле төбәкләрдән кешеләр (мөгаен, элекке шәкертләредер) килгән. Озатырга баручыларның бер очы зиратка җитсә, икенче очы авыл башында калган…

«Мәдрәсәләрдә китап киштәсе»

Ә менә Чистай ягындагы Каргалыдан килгән Әбелкарәм хәлфә алдынгы фикерле, яңалыкка омтылучан кеше булган, дип сөйлиләр. Ул уку-укыту системасындагы искелекне тәнкыйтьләгән, мәдрәсәдә күбрәк дөньяви фәннәрне укыту уе белән янып йөргән икән.

Кече Сон мәдрәсәсендә борынгы кульязма мирас тупланган гыйльми китапханә дә эшләгән. Кызганыч, бу байлык исән-имин сакланып калмаган, утызынчы елларда юкка чыккан. Госаметдин хәзрәт йортының чормасы әле сугыш елларында да кульязма китаплар белән шыплап тулган була. Аларга кагылып кына кара, сине, милләтче, халык дошманы, дип, төнлә килеп алып та киткәннәр. Шулай да кайбер йортларда кульязма мирас хәзерге көнгә чаклы сакланып калган. Үзбәк халкының бөек шагыйре Галишер Нәваинең шәкертләр күчереп язган кайбер әсәрләре моннан берничә ел элек Кече Сонда табылды һәм Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының «Мирасханә»сенә саклауга алынды.

Партия эшлеклесе, совет укытучысы – кичәге шәкерт

Кече Сон мәдрәсәсендә укыган бик күпләр 1917 елгы борылыштан соң дәүләт, партия органнарында эшләделәр, күмәк хуҗалыклар оештырдылар, колхоз рәисләре булдылар. Алар арасында үзләренең тормыш юлын мәгариф белән бәйләүчеләр аеруча күп иде. Мәсәлән, Чистай районының Адәмсу авылыннан килгән, үзенең белеме, зирәклеге белән аерылып торган Гаяз шәкерт, ике институт тәмамлап, укытучы булып эшли, Бөек Ватан сугышында һәлак була. Шул ук районның Колмакчы авылыннан килгән бертуган Камил һәм Мирзасалихлар да совет мәктәбе директорлары булып хезмәт итәләр. Уразбахты авылыннан Зиннәт хәлфә мәдрәсәдә шәкертләргә дәрес бирә. Ул соңыннан Үсәлидә мәктәп директоры булып эшли, читтән торып Казан дәүләт университетының география факультетын тәмамлый. Мәгариф өлкәсендә озак еллар буе фидакарь хезмәт куйган Зиннәт Абдуллин, Татарстанда беренчеләрдән булып, Ленин ордены белән бүләкләнә. Түбән Арбаштан Сәхи Гасыймовның тормышы Югары Кыерлы авылы белән бәйләнгән. Ул биредә балалар укыта, мәктәп директоры булып эшли. Габделхәй Салихов (Тәберде Чаллысы), Сәяф Сафин (Югары Сон), Зәки һәм Хәким Гайнановлар (Чыршы Арты), Карәм Афзалов (Урта Сон), Зиннур Абдуллин (Норма) һәм башка бик күпләр үзләренең тормышларын яшь буынга белем һәм тәрбия бирүгә багышлыйлар.

Мәдрәсәдән – музейга

Халыкка мәгърифәт нуры тараткан данлыклы Кече Сон мәдрәсәсе яшәешенә Совет хакимияте балта чаба. 1917 елның 15 сентябрендә аның биналары совет мәктәбенә бирелә. Шулай итеп, биредә 1970 елга кадәр башлангыч сыйныф укучылары белем ала.

Моннан 122 ел элек агач бина урынына таштан салынган мәдрәсә бинасының озак еллар ташландык хәлдә булуы күпләрне борчый иде. Аның

Мәдрәсә бинасында композитор Фәрит Яруллинга багышланган музей ачу тантанасы. 2016 ел, 12 июль

түшәме, сайгагы юк, тәрәзәләрдән җил өрә, стеналарда ярыклар… Бу бинаны саклап калырга иде, дип өзгәләнгән кешеләр дә булды. Ниһаять, авылда әлеге эшне башкарып чыгардай шәхес табылды. Сон җирле үзидарәсе җитәкчесе – иманлы, батыр йөрәкле Мансур Фәрвәзетдин улы Сәлахов әлеге эшне башлап җибәрде һәм ахыргача башкарып та чыкты. *«Моннан ун еллар элек, җимерек булу сәбәпле, Кече Сон мәдрәсәсе бинасын тарихи һәйкәлләр исемлегеннән сызарга да теләгәннәр иде. Бу хакта ул вакыттагы районыбыз башлыгы* ***Рөстәм Кәлимуллин****га җиткердем. Ул килеп карады, озак кына уйланып торды һәм: «Торсын әле», – диде. Аңа ремонт үткәрү мәсьәләсе белән йөри башладык. Районыбызның яңа башлыгы Анатолий Петрович Иванов теләгебезне хуплады. Мәдәният министрлыгына документлар әзерләп тапшырып, бер миллион сум грант оттык һәм эш башланып китте. Бу бинаны яңартуга бик күп кешеләр үз өлешләрен керттеләр. Мамадыштан килеп, стенаның ишелә башлаган урынын сүтеп, яңадан өйделәр. Урта Кирмән авылы осталары агач эшләрен башкардылар. Үзебезнең авылдашларыбыз стеналарны штукатурладылар һәм коймасын тотуда ярдәм күрсәттеләр. Бик күпләр акчалата да ярдәм кулы суздылар. Аларның барысы да музейның «Мактау китабы»на кертелгән»*, – дип сөйләде ул безгә. Шулай итеп, элеккеге мәдрәсә бинасында 2016 елның 12 июленнән композитор Фәрит Яруллин музее эшләп китте.

Мәдрәсә-музейны ачканда Мамадыш район хакимияте башлыгы **Анатолий Иванов**: *«Бу бина Мансур Сәлаховның үҗәтлеге, тырышлыгы нәтиҗәсендә торгызылды. Илдә кризис дип тормады, төн йокламыйча чапты ул. Яруллиннар безнең төбәгебезне зурлаган кешеләр. Бина алга таба да халыкка хезмәт итсен. Авылыгыз ямьле, халкы тәртипле»*, – диде.

Музеебыз Фәрит Яруллин исемен йөртсә дә, анда мәшһүр композиторлар Заһидулла һәм Мирсәет Яруллиннарга, танылган мәгърифәтче Таҗетдин Ялчыголга, авыл, колхоз һәм мәктәп тарихына, кул эшләренә дә урын бирелгән. ■

Мамадыш төбәге авыз иҗаты – милләт сагында

Челтәрле дә бизәкле. Мамадыш районының Ылыя авылындагы йортларның тәрәзә йөзлекләре

Халык авыз иҗатының иксез-чиксез хәзинәсен танып белми торып, шушы халыкның үзен, аның телен, холык-фигылен өйрәнү мөмкин түгел. Кешелек элек-электән өлкәннәрнең акыллы сүзләрен, төпле фикерләрен истә тотып яшәгән. Буыннан-буынга күчеп яши торган әлеге кыйммәтләр хәзерге көндә дә зур әһәмияткә ия. Мифлар, мәкаль-әйтем, табышмаклар, мәзәк-акиятләр, риваять, дастан, бәет һәм мөнәҗәтләр, йола җырлары, гореф-гадәтләр, милли бәйрәмнәр һ.б., шөкер, халыкта әле дә бар.

Мамадыш – мөселман һәм керәшен татарлары яши торган төбәк. 2013 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре Мамадыш районында комплекслы фәнни экспедициядә булып кайтты. «Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән» дигән сериядә гаять бай эчтәлекле, затлы эшләнешле «Милли-мәдәни мирасыбыз. Мамадыш» (2017) дип аталган китапта биредә яшәүче милләттәшләребезнең гореф-гадәтләре, авыз иҗаты, тел үзенчәлекләре чагылыш тапты.

*Шунысы мөһим: Мамадыш районында җирле халык үзе дә рухи мираска битараф түгел. Мәсәлән, Мамадыш төбәгендә туып, шунда гомер иткән, мәктәптә татар теле укыткан **Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова** бүгенге көндә Мамадыш районы татар фольклорына, хәзерге заман татар дөньясына хас гореф-гадәтләр, традицияләр, тарих, авыз иҗаты белән әдәбият арасындагы күпгасырлык бәйләнешләрне да колачлаган, шушы төбәктә таралыш алган фольклор ядкярләрен бергә туплап тәкъдим итә торган саллы җыентыкны басмага әзерләп йөри. Биредә тынгысыз җанлы Гөлфинур Зәйнулла кызы әзерләгән әлеге җыентыктан аның үзе тарафыннан халыктан тупланган кайбер материалларны укучылар игътибарына тәкъдим итәбез.*

Лилия Мөхәммәтҗанова, *филология фәннәре докторы,*
Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел,
әдәбият һәм сәнгать институты баш фәнни хезмәткәре

Су анасы

(мифологик хикәят)

Балачакта су буенда бәбкә саклап утырабыз. Берзаман Тәскирә апаны Су анасы алган дип кычкырыша башладылар. Без дә йөгереп киттек тегермән бөясенә. Бөя искиткеч зур, киң һәм тирән. Юк инде Тәскирә апа. Менә шушы басмада кер чайкаганда эләктереп алган инде Су анасы. Кычкырып та карыйлар: «Тәскирә, Тәскирә», – дип. Берзаман бу тавышка ирләр дә җыела башлады. Тиз генә чумып, эзләргә иде дә исәпләре, хатыннары чыр-чу килә, имеш, сине дә алыр Су анасы… Шулай да, тәвәккәлләделәр, озак кына эзләделәр, әмма Тәскирә апа табылмады. Өлкәнрәкләр: «Су анасының су астында өе бик тирән икән, шунда алып киткәндер инде», – диештеләр.

Сөйләүче: Фатыйхова Гайшә Галимҗан кызы (1932 елгы). Иске Комазан авылы.

Бичура

(мифологик хикәят)

Бичура хатын затыннан була. Буе – аршин ярым, иңе – аршин. Башына өрпәк салып йөри, бәрәңге базларында, идән асларында, ташландык мунчаларда яши. Бичура бар кешенең дә өенә ияләшми, сайлап кына ияләшә. Бичура ияләшкән өйләрдә аңа үзенә аерым бүлмә калдыра торган булганнар.

Бичураны безнекеләр Чаксы авылыннан алып килгәннәр дип сөйлиләр ие борынгылар. Чаксыда матур гына яшәп ятканда, чукындырылудан качып, күчеп китәргә мәҗбүр булганнар бабаларыбыз. Су эчә торган коега поп, тәре ташлап, бу су инде чукындырылды, эчсәгез, сез дә чукынган буласыз, дип, татарларны китәргә мәҗбүр иткән. Шуннан соң хәзерге Акман авылына нигез салганнар бабаларыбыз. Йорт-кураларын да куптарып алып килгәннәр. Аит исемле ерак бабам күчергән келәт бүген дә исән әле. Черт тә итмәгән. Аларга ияреп бичура да күчкән. Башта Мотыйгулла абзыйларда диләр ие бичураны. Ашарына тәмлерәк ризыклар калдырсаң, иртә беләнгә әллә никадәр эшләрен эшләп куя икән, дип сөйлиләр ие. Аннан соң күршеләре Шакирҗан абзыйга күчкән, дип сөйли башладылар. Аларда озак тормаган, күрәсең, йорт хуҗаларын ошатып җиткермәгәндер. Тамагына ашатмадылар микән? Алар үзләре дә ярлырак торганнар, тавык бәрәңгесенә генә риза түгел икән бичура, дип сөйләделәр. Соңга таба, Гыйниятулла абзыйга күчкән икән бичура, ди башладылар. Кыш вакыты. Бакча артыннан кергән, кар өстендә аяк эзләре калган, имеш. Озак яшәгән аларда бичура. Карчыгы Хупҗамалтәй, эшләрен тизрәк эшләсен дип, коймаклар пешереп куя икән мич башына. Теге иртә торуларына печәнне дә өеп куя, утынны да ярып куя, ди. Болар тагын моны коймак белән сыйлыйлар икән. Коймак пешерергә оннары да булган аларның. Чөнки Гыйниятулла абзыйның бабаларыннан калган ярма ясый торган таш яргычы бар ие. Бөтен авыл шуңа ярма ярдырырга килер ие. Ярып биргән өчен хуҗага да калдырып китәләр ие әҗерен. Ачлык күрмәделәр. Бичура да рәхәтләнеп яткан инде.

Сөйләүче: Насретдинова Мәрфуга Юныс кызы (1909 елгы). Акман авылы.

Кирмән җирендәге Елантау

(риваять)

Казан шәһәре өчен сайлап алынган җир еланнар белән тулы була. Аларны юк итүне бер сихерче үз өстенә ала. Кыш көне еланнар яткан урынга күп итеп салам өя дә, яз җиткәч, ут төртә. Тик өч башлы Зилант бик еракка очып китә. Кирмәнлеләр аның Алтын базы урнашкан тау эченә кереп китүен күреп калалар, имеш…

Сөйләүче: Спиридонова Алсу Сәяф кызы. Урта Кирмән авылы.

Сөрән каены турында риваять

Дүсмәт тау башында бер ялгыз каен бар безнең. Өлкәннәрнең әйтүе буенча, гасырдан артык инде аңа. Усал җилләргә, салкын кышларга бирешмичә яши ул һаман. Исеме дә бар аның: «Сөрән каены» дип атала. Нәнәм сөйли торган иде, карлар эреп, әзрәк җир ачылуга, яшьләр шул каен янына җыела торган булганнар элек. Учак ягып, төнлә шунда уен сыман очрашу булган, таң атканчы, керәшен җырларын җырлап утырганнар.

Сөйләүче: Григорьев Владимир Иванович (1947 елгы). Дүсмәт авылы.

Сөннәтче әби

(сөйләк)

Зәйтүнә исемле ие ул. Чыгышы белән Ямаш авылыннан. Ире Самат исемле булгач, Самат Зәйтүне дип йөртәләр ие. Шул Зәйтүнәттәй сөннәткә утырта ые малайларны. Үткен пәкесе бар ые. Үгез бозауларны да, тәкәләрне дә печә ие. Ул вакытта авыл зур, кеше күп. Балалар да ишле, мал-туар да ишле ие хуҗалыкта. Ник бер «читкә тайпылган хәл» булсын. Куллары шәфкатьле ие Зәйтүнәттәйнең, урыны оҗмахта булсын.

Сөйләүче: Юнысов Сабит Салих улы (1930 елгы). Акман авылы.

Сабит Салих улы Юнысов (1930 елгы)

Түгәрәк «Ясин»

(сөйләк)

Безнең Нәфыйк бабай нәселендә саклана торган бу «Ясин» төрле авырулардан савыктыра, ягъни, мунча кереп чистарынып чыккач, бисмилланы әйтеп, баштанаяк җиде кат гәүдәңне әйләндерсәң, шифасы, һичшиксез, тия иде. Әнием яшьтән бик гыйлемле, дини иде. Гарәп хәрефләре белән Коръән укый иде. Түгәрәк «Ясин»ны да ул ясады.

Сөйләүче: Нәфыйк бабайның оныгы Хәлимә апа (1937 елгы). Акман авылы.

Юраулар

Юраулар өчен бик күптөрле билге-галәмәтләр нигез булып тора. Язын аҗаган күргән кешене гомере буена ачы язмыш, зур афәтләр, көтелмәгән газап-михнәтләр, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан бәла-казалы, зар-интизарлы булыр, диләр. Өй янына каен агачы утыртырга ярамый, кайгыдан башың чыкмый. Миләш агачы күз тиюдән саклый. Артыш агачы булган йортка җеннәр, шайтаннар керә алмаган. Тәнендә миңе күп кеше бәхетле була, диләр. Миңнәре үзе күрә алмый торган җирендә, әйтик, аркасында булса, андый кеше бигрәк тә бәхетле, имеш.

Борын очы кычытса – мәет. Козгын карылдаса – мәет. Ашагач, өстәл өстен кәгазь белән сөртсәң – талаш. Күп еласаң – мәеткә яки хәсрәткә. Гөлләр корый башласа – йортта тынычлык, тигезлек бетә. Үрмәкүч оясын кич белән кузгатмыйлар – бәрәкәт бетә. Кояш баегач, өй җыештырсаң, кер юсаң – йорттан бәрәкәт китә, игелек күрмәссең. Баз капкачы өстендә йокларга ярамый – чирлисең. Күп талашу, кычкырышу – бәхетсезлеккә, йортта игелек бетә. Ике кеше берьюлы сөлгегә кул сөртсә – талашып китәрләр.

Сөйләүче: Искәндәрова Нәҗия Нәкыйп кызы. Мамадыш шәһәре.

Ырымнар

Мөселманнар өчен эш башларга чәршәмбене иң әйбәт көн диләр ие. Киселгән чәч, тырнакларыңны теләсә кая ташламаска, бисмилланы әйтеп, мичкә атарга кирәк, диләр ие. Ашаганда аягыңны селкеп, шайтан чакырып утырмаска, өстәлдәге ризыкны каплап куярга, киемне кигән килеш текмәскә, гомерне кыскарта, диләр ие. Буш бишекне тирбәтсәң, бала чирле була, 40 көн тулмыйча баланы ялгыз калдырмаска, чөнки җен алмаштырырга мөмкин, мендәре астына пычак салырга кирәк, диләр ие. Балага күз тимәсен дип, артыш агачыннан бөтиләр тагып куялар ые. Песи ишеккә карап битен юса йә самавыр катырак чыжласа, кунак киләчәк дип юрыйлар ые.

Сөйләүче: Усманова Сәрбиҗамал (1933 елгы). Акман авылы.

Төш юрау

Төшеңдә суны аркылы йөзеп чыксаң, йә булмаса, тауга менсәң, сөенечкә дип юрыйлар ые. Төшеңдә еласаң да – шатлыкка. Гармун тавышы ишетсәң, хәбәр буласына. Төшеңдә ак кием дә шатлыкка, ә инде менә кара кием – кайгыга, диләр ие. Чи ит күрсәң – авыруга.

Күп инде ул төш юраулар. Төшне бит аны кешегә сөйләргә дә кушмыйлар. Кешегә сөйләгәнче, чыгып җилгә сөйлә, диләр. Һәркем үзенчә юрый бит. Начар төшләр кермәсен, дисәң, йокларга ятканда «Бисмикә, Аллаһүммә, әмүүтү үә әхьйәә» (Синең исемең белән Аллаһым мин үләм һәм терелә̆м) дигән доганы укырга кирәк. Аллаһны алга куеп яшәсәк, начар төшләр кермәс.

Сөйләүче: Хәбибрахманова Нурсама (1931 елгы). Мамадыш.

Нурсама Хәбибрахманова (1931 елгы) ире Садыйк абый белән

Баскан авылы тарихы

(риваять)

Казан ханлыгы дәверенә карый торган авыл. Әүвәл авылның исеме Акчура була. Бу авыл ике бабадан башланган: Сәли һәм Имәнкол. Акчура авылын, урманнан чыгып, юлбасарлар баскан. Шуннан аның исеме «Баскан» булып китә. Ләкин Акчура авылы (Баскан) иске урында калмый, яңа урынга күчә. Ул урын Бүрсет-Сукачы авылы булса кирәк.

Олылар сөйләгәннәрдән язып алынды. Баскан авылы.

Албай авылының нигезләнүе турында риваять

Безнең монда Кистәнче җылгасы, Түлмәт дигән чишмә бар. Албай дигән кеше килеп утырган да шул чишмә янына җорт җиткергән. Ибан Грозный багытында качкан татарлар килеп утырган. Аннары керәшеннәр килгәч, татарлар качып киткәннәр. Җәрмәкәй морзалар (Ермаковлар), Җәмилләр (Емельяновлар) чукынганнар. Безнең тамыр Янсуар җанында Талкыш авылы бармы, менә шуннан күчеп килгәннәр. Урыслар Комораудан килгәннәр. Кистәнче җылгасы җанында таш кирбечләр чыга. Анда авыл булган, аларның пуҗымнары да билгеле.

Сөйләүче: Макаров Григорий Иванович. Албай авылы.

Абзар иясе үчләнә

Дүсмәт авылына килеп утырган бабайлар башта мөселман динендә булганнар. Мулла абзыйның безнең элеккеге иске пуҗымда яшәгәнлеге билгеле. Петр I заманында авыл чукындырыла. «Поплар, казак отрядлары белән килеп, халыкны мәҗбүриләп язгы салкын сулы инешкә кертеп, кулларына тәре тоттырып чумдырганнар»,– дип сөйли торганнар ые. Мулла абзый чукындырылгач, аның пуҗымында минем ерак бабамнар яши башлаганнар. Әмма бу пуҗымда тынычлык булмаган, бабамнарның маллары бер дә үрчемәгән. «Мөселманлыктан керәшен диненә күчүебез ошамагандыр инде абзар иясенә, шуңа үчләнә»,– дип зарланышкан бабайлар. Ни әйтсәң дә, мулла нигезендә дуңгыз тоту да хәрам бит.

Сөйләүче: Васильев Николай Арсентьевич (1950 елгы). Дүсмәт авылы

Ташлыяр авылы җырулары

Ак та пәкеләрне мин сапладым,
Мәчет манарасын сырларга.
12дә җыруымның берсен куйдым,
Сез туганнарга дип җырларга.
Иртәләрдән торып ипи бастым,
Арыш онынннан түгел, бодайдан.
Сезнең исәнлекләрне без сорыйбыз,
Иртән иртүк торып Ходайдан.
Урман авызлары, әй, тар авыз,
Юкә чәчәккәе балавыз.
Сагынганнар саен күрешергә,
Җырагырак безнең арабыз.
Урман буйларында, ай, имәннек,
Имәннек буйлары, әй, игеннек.
Игеннәрне бергә, ай, игеек,
Гомерләргә бергә җөреек.
Бәйрәмнәрдә без җөреек,
Ике кулыбызга гөл учлап.
Сез дуслар белән бер күрешкәч,
Калыр инде күңел тынычлап.
Килсен ие болыт, яусын яңгыр,
Яусын ые болын буенда.
Сезнең белән безнең йөрешүләр
Барсын ые гомер буена.
Кара урманнарның, әй, артында
Карчыгалар канат кагынган.
Очкылыклар тотса, тот исеңдә,
Без булырбыз сезне сагынган.

«Җырак бабам Егоров Арсентий (1903 елгы) җыры», – дип җырлап күрсәтүче – Степанова Анфиса Ивановна. Ташлыяр авылы.

«Һәр халыкның, һәр төбәкнең үз йөзе, үз төсе, милли холкы булган кебек, безнең төбәкнең дә үзенә генә хас кабатланмас атамалары, гореф-гадәтләре, йолалары, җыр-такмаклары, уеннары бар. Борынгы тарихыбызны, данлы үткәнебезне чагылдыра торган атамалар, мәсәлән, Ханнар зираты, Елан, Манасыр, Аккош таулары, Алтын базлары; Үти, Буденный, Поп чишмәләре кебек серле, тылсымлы атамалар бездә генәдер. Им-томнар темасын гына алыйк. Сөннәтче бабайлар турында күп ишеткән бар, ә менә Сөннәтче әбиләр бездә генә булгандыр, мөгаен. Шулай ук төбәгебездә генә түгел, Татарстан, хәтта Россия күләмендә дә изге дәвалаучылар булып танылган Миңнеямал, Дөрия, Гамбәрия әбиләр дә бездә генә булгандыр... Өй почмакларын каерып керергә, яшь балаларны алмаштырып куярга сәләтле җеннәр, шар булып тәгәри торган убырлар, өрәкләр, алты башлы аждаһалар, шуларны суырып ала торган ак болытлар, әле бүген дә изге чишмәләрне саклый торган зәһәр еланнар да бездә генәдер...»

Гөлфинур Дувалова

*Мамадыш районы авылларындагы фольклор үрнәкләрен информантлардан **Гөлфинур Зәйнулла кызы Дувалова** язып алды. Мамадыш шәһәре.* ■

Кәвәл авылы

(Түгәрәк уен көе)

Куктәй кулмәгемне кулгә салдым,
Кугәрмәс ук…
Кугәрмәс ук борын, ал, җаный.
Минем гыйшыкларым сиңа төштей,
Саргаймас ук…
Саргаймас ук борын, ал, җаный.

ҖЫРЛАШЫПТЫЙ, ҖЫРЛАП БЕЗ КАРЫЕК

Җырлашыптый, җырлап без карыек,
Килешерләр…
Килешерләр микән көебез?
Килешерләр булса ла, ай, көебез,
Җалан шулай…
Җалан шулай бергә җөрербез.

Пәке лә, ди, пычак мин җасаттым,
Мәчит манар…
Мәчит манарасын сырнаргай.
Сезнең өчен әле мин ыризай
Асыл ла җыр…
Асыл ла җырларын җырларгай.

Алмай агач белән балан агач
Җәй уртасый…
Җәй уртасый чәчәк атмыйдыр.
Уйныек, кызлар, без көләек,
Узган гүмер…
Узган гүмер кире кайтмыйдыр.



Татарларны чукындыру сәясәте Үтәмешне дә читләтеп узмаган

Нияз Исхаков

Сембер губернасының картасы (фрагмент). 1857 ел. (РГИА. Ф.515, оп.71, д.2529, л.1)

Үтәмеш Татарстанның Тәтеш муниципаль районына керә. Өч авыл – Олы Тархан, Кече Тархан һәм Үтәмеш урнашкан җирләр, хәзерге вакытта да шушы авыллар файдалана торган кыр-басуларны да кертеп, Зөя өязенең Яңа Уразлино авылында оештырылган хәрби йөзлектә хезмәт итүче староста Уразла Енеевкә һәм аның хезмәттәшләренә Мәскәү патшасы Алексей Михайлович Указы буенча 1646 елда бирелгән була. Аларга читтән күченеп килүчеләрне кабул итү мөмкинлеге дә бирелә. Безгә билгеле булган чыганакларда әлеге документ оригинал хәлдә табылмады. Указда Уразла Енеевнең тарханлык алуы күрсәтелгән дип уйларга мөмкин, чөнки оеша башлаган авыл Тархан дип атала. Соңрак ул Олы Тарханга әверелә, ә Тархан елгасының югары һәм түбән өлешләрендә урнашкан авыллар Тарханбаш һәм Кече Тархан була. Моңа кадәр халык төпләнеп яшәмәгән җирләрне үзләштерү әлеге гамәлнең төп максаты булып тора.

Үтәмешкә, чал тарихлы күрше авыллар Олы Тархан, Кече Тархан, Тарханбаш, Бидәңге (Татар Бидәңгесе), Бакырчы (авыл икенче исем белән дә аталган – Иркеево) кебек үк бер чорда – XVII гасырның уртасында яки аның икенче яртысы башлануга нигез салынган дип фикер йөртәбез. Моның ике юл белән тормышка ашырылган булуы мөмкин: беренчесе – Зөя өязенең хәзерге Чуашстан Республикасына кергән җирләрдә яшәүче йомышлы һәм ясаклы татарларның, Олы Тарханга нигез салучыларга кушылып, яңа җирләрне үзләштерүгә рөхсәт алуы һәм хәзерге Үтәмеш урынында нигезләнүе; икенчесе – аерым гаиләләрнең, үз кырларына якынрак булу теләге белән, инде нигез салынган һәм яшәп килә торган авыллардан, беренче чиратта, Олы Тарханнан күченеп утыруы.

Билгеле булганча, Казан ханлыгы яулап алынганнан соң, патша хөкүмәте тарафыннан татарларны мәҗбүриләп чукындыру башлана. Шушы сәясәт христиан дин әһелләренең актив катнашында алып барыла. Ул гасырлар буе дәвам итә.

20 нче йөзгә кадәрге вакыт аралыгы халкыбыз тарихында чын мәгънәсендә дәһшәтле, караңгы еллар, ифрат авыр чорлар була. Патша хөкүмәте татар халкының динен, реаль тарихын алыштыруны максат итеп куя. 1740 елда моның өчен махсус «Чукындыру эшләре буенча контора» оештырыла. Мөселманнарга каршы репрессияләр кулланыла. Христиан динен кабул итүчеләргә берничә елга салым түләмәү мөмкинлеге бирелә. Христианлыкка күчәргә теләмәүчеләргә, киресенчә, икътисади басым ясала, аларны хәтта чукынганнар өчен салым түләргә дә мәҗбүр итәләр.

Мәгълүм булганча, татар авылларында чукынганнарны һәм чиркәү тарафыннан чукындырылган дип саналганнарны керәшеннәр дип атаганнар.

Нияз Фәтхелислам улы Исхаков – отставкадагы полковник, техник фәннәр кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр. 1935 елның 15 августында Үтәмеш авылында игенче гаиләсендә туган. 1953 елда Олы Тархан татар урта мәктәбен тәмамлап, 1953-1956 елларда Даугавпилс шәһәрендә өчьеллык Хәрби авиация-радиотехника училищесында укый. 1956-1960 елларда Прибалтика хәрби округы авиация полкында (Латвия, Тукумс шәһәре) МиГ-17пфг истребительләрен радиотехника хезмәте белән тәэмин итүче техник-лейтенант була. 1960 елда, радиотехника буенча белемен үстерергә теләп, Ленинградта урнашкан А.Ф.Можайский исемендәге хәрби авиация инженерлары академиясенә укырга керә. 1965 елда академияне алтын медальгә тәмамлап, 1970 елга кадәр Капустин Яр ракеталар сынау полигонында инженер-сынаучы хезмәтендә була. 1970-1973 елларда А.Ф.Можайский исемендәге академиянең адъюнктурасында укып, кандидатлык диссертациясен яклый һәм техник фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала. Шуннан соң Санкт-Петербургта урнашкан фәнни-тикшеренү институтында өлкән фәнни хезмәткәр булып эшли һәм фәнни төркем җитәкчесе вазыйфасын башкара. Татар тарихы, бигрәк тә туган авылы Үтәмешнең үткәне, бу төбәктән чыккан һәм анда яшәгән мәшһүр шәхесләр белән кызыксына.

Империя хөкүмәте һәм православие руханилары алып барган сәясәт – Русия составында рус булмаган халыкларны көчләп чукындыру һәм шулай итеп христиан диненә күчерү татарлар өчен аяныч хәл – фаҗига була. Әлбәттә, берничә йөз ел буена сузылган бу сәясәт Үтәмеш халкын да үз агымына тартып кертергә тырыша, үтәмешлеләрнең дә бер өлеше шул сынау аркылы узарга мәҗбүр була.

> «Татарларны чукындыру сәясәтенә кагылышлы мәгълүматлар вакытлы матбугатта күренгәләп тора. Әмма аларның билгеле бер өлеше бөтен татар халкына бәйле булган хәлләрне гомуми яссылыкта яктырта. Безнең мәкаләдә бу тема конкрет шәхес – үтәмешле Әхмәтсадыйкка бәйле рәвештә бәян ителә.

Татарларны чукындыру сәясәтенә кагылышлы мәгълүматлар вакытлы матбугатта күренгәләп тора. Әмма аларның билгеле бер өлеше бөтен татар халкына бәйле булган хәлләрне гомуми яссылыкта яктырта. Безнең мәкаләдә бу тема конкрет шәхес – үтәмешле Әхмәтсадыйкка бәйле рәвештә бәян ителә. Әхмәтсадыйк XIX гасырның икенче яртысында Сембер һәм Буа өязләрендә яшәгән һәм чукынганнар дип саналган татарларның мөселманлыкка кайту өчен көрәшен башлап җибәрүче, әйдәп баручы һәм бу көрәштә төп рольләрне башкаручыларның берсе була. Әхмәтсадыйк бу эшләре өчен Себергә – Туруханкраена сөрелә. Мәкаләдә китерелгән мәгълүматлар рәсми кәгазьләргә нигезләнеп дәлилләнә.

1834 елда Үтәмештә узган VIII җанисәп (ревизия) нәтиҗәләрен өйрәнеп, авылда яшәгән алтмыш тугыз гаиләнең бишесе чукынганнар исемлегенә кертелгән булуы ачыкланды. Аларда халыкның гомуми саны 29 кеше (балаларны да кертеп) – 11 ир-ат һәм 18 хатын-кыз. Барысы да рус исемнәре белән теркәлгән. Шунысын да искәртеп китү урынлы: чукынган крестьяннарның булуы Үтәмешкә генә хас күренеш түгел. Мәсәлән, шул ук 1834 елгы җан исәбен алу вакытында Бакырчыда да шундый биш гаилә теркәлгән. Олы Тарханда, Бидәңгедә, Кече Тарханда һәм башка татар авылларында да андыйлар булган. Үтәмештә *«чукынмаган казна крестьяннары»* төркеменә 487 кеше – 243 ир-ат һәм 244 хатын-кыз кергән. Шушы ук вакытта, ягъни 1834 елда Үтәмеш җәмигъ мәчетле авыл була. Мәчеттә *«имам җәмигъ вә мөхтәсыйб Минуш Мостай улы»* хезмәт итә. Бу турыда Үтәмеш мәчетендә 1834 елда төзелгән метрика кенәгәсенә язылган.

Үтәмештә яшәүче керәшеннәр турында ревизия язмаларында теркәлгән мәгълүмат белән танышкач, табигый рәвештә сораулар туа: алар нинди шартларда керәшеннәргә әйләнгән һәм моңа мөнәсәбәтләре нинди булган, православие дини йолаларын үтәгәннәрме һәм чиркәү руханилары белән аралашканнармы, хәлиткеч күпчелекне тәшкил иткән авылдашлары – мөселманнар арасында алар ничек яши алган? Бу сораулар һәрберебезне кызыксындыра, тик менә ревизия язмаларында аларга җавап таба алмыйбыз. Ревизия язмалары башка максатларда – хөкүмәткә салым түләргә тиеш булганнарны барлау, исәпкә алу өчен төзелгән.

Халык хәтере мәңгелек ул, бигрәк тә аянычлы хәлләрне онытмый. Буыннан-буынга күчеп килгән хәтер теләсә нинди шартларда да яши. Аның әһәмияте югары бәяләнә, чөнки ул теге яки бу вакыйгага карата халыкның күпчелек өлешендә сакланган һәм буыннан-буынга тапшырыла торган карашларны чагылдыра. Бу уңайдан XX гасырның 40-50 нче елларына кадәр олы яшьтәге үтәмешлеләр тара-

фыннан гына әйтелеп калмыйча, балалар арасында да киң таралган һәм тискәре карашны аңлата торган чукындыру сүзенең киң кулланылган булуын әйтеп узу урынлыдыр. Мәсәлән, берәрсенә карата ачулы карашны белдерү өчен: *«... кит моннан, чукынган!»* – дип әйтәләр иде. Бу күренеш кинәт кенә һәм сәбәпсез барлыкка килмәгән бит. Ләкин чукынганнарның кайчан да булса авылда яшәгән булуы без, балаларга, билгеле түгел иде. Гомумән, ул елларда бу темага сөйләшү булмады.

Керәшеннәрнең дә хәле катлаулы булган. Чиркәү руханилары аларны даими күзәтеп торган. Шул ук вакытта керәшен булып саналучылар абсолют күпчелекне тәшкил иткән авылдашлары – мөселманнар белән күршеләр булып яшәгән, аралашкан һәм үзләренең кабул итә алмаслык кыен хәлдә калуларын аңлаган. Чукынганнарга авылдагы мөселманнар белән аралашып яшәве авыр булган. Нәтиҗәдә, аларның бер ишләре мөселманлыкка кире кайту, ә икенчеләре, ягъни чиркәү тарафыннан чукындырылганнар дип саналучылар үзләренең мөселман булуларын раслау өчен көрәшкәннәр.

Бу мәсьәләне ныклап өйрәнгәнче үк, бер дә шикләнмичә, шуны әйтә алабыз: Үтәмештә, зур булмаган авыл шартларында яшәүчеләр, авылдашларның барысы өчен дә бер үк төрдәге һәм уртак булган хезмәт – кыр эшләре һәм терлекчелек белән шөгыльләнүчеләр, тормыш шартлары таләп иткәнчә, бер-берсе белән тыгыз мөнәсәбәттә булырга тиеш кешеләр, татар халкының аерылгысыз өлешен тәшкил итүчеләрнең бер төркеме үзләре теләп христиан диненә күчә алмаслар иде. Бу мөмкин булмаслык хәл. 1834 елгы ревизия язмаларыннан һәм Үтәмеш мәчетләренең метрика кенәгәләреннән күренгәнчә, хәтта Сабит Рәфыйк улы да, 20-25 ел солдат хезмәтендә булып та, мөселманлыгын саклап кала алган. Шулай да, Үтәмештә керәшеннәрнең булуы – бәхәссез факт. Шуны истә тотып, үзебезне кызыксындырган сорауларга җавап табарга омтылыш ясадык.

Бер танышым болай дип әйткән иде: *«Чиркәүнең яхшы ягы бар – ул берәүне дә көчләп христиан диненә тартмый»*. Шундый дәлилләнмәгән рәвештә әйтелгән сүзләргә нигезләнгән очракта ялгыш юлдан китүебез дә мөмкин. Шуңа күрә, мөмкин булган кадәр, рәсми чыганакларга таянып эш итәргә булдык.

> **«Чиркәүнең яхшы ягы бар – ул берәүне дә көчләп христиан диненә тартмый».**

Ревизия язмаларында өченче сан белән теркәлгән гаиләгә игътибар итик. Ревизия язмасында аның турында, гаилә башлыгы Михаил Васильев 1827 елда 44 яшендә үлгән, ә аның улы – *«Михаила Васильева сын Николай, новорожденный, 13 лет»*, дип язылган. Ревизия 1834 елда уздырылган. Шулай булгач, *«Михаила Васильева сын Николай»*ның 1821 елда туган икәнлеге ачыклана. Гаиләдә, Николайдан башка, аның әнисе һәм өч кыз туганы булган. Николай Михайлов чынбарлыкта Әхмәтсадыйк Танеев икән. Бу хакта Сембер губернаторының 1866 елның 23 гыйнварында һәм 29 маенда Русия эчке эшләр министрына җибәргән донесениеләрендә әйтелгән. 29 майда төзелгән донесениедән бер өзек: *«... крестьянин деревни Утямышевой Николай Михайлов (а по-татарски Ахмет Садык Танеев) ...»*. Донесениедә күрсәтелгән *«Ахмет Садык»*ны *«Әхмәтсадыйк»* дип уку дөреслеккә туры килә, чөнки бу – ике тармаклы татар исеме. Шушы урында чираттагы сорау туа: нинди гамәлләре белән һәм нинди сәбәпләр аркасында гади бер авыл крестьяны губернаторның игътибарын җәлеп итә алган һәм аны хөкүмәт министрына мөрәҗәгать итүгә этәргән?

Җавапны шул ук донесениеләрдә табабыз. Донесениеләрнең Әхмәтсадыйкка кагылган өлешләрен оригинал хәлдә, ягъни русча язылган килеш, орфографик һәм стилистик үзенчәлекләрен саклап урнаштырабыз.

«Господину министру внутренних дел

23 января 1866 г.

...Некоторые из старокрещеных татар Буинского уезда, заявляя в волостных правлениях о поданном ими на высочайшее имя прошении относительно присоединения к могаметанству, просили, чтобы священники не ходили к ним с требами до получения на это прошение разрешения. Прошение это отправлено из Казани крестьянином деревни Утямышевой по имени Садыком... В деревне Тарханах Буинского уезда крещеные татара тоже не допустили священников окрестить детей их до разрешения на поданное ими прошение, отправленное от них крестьянином деревни Утямышевой Ахмет Садык Танеевым...».

29 май донесениесеннән өзекләр:

«...татара (донесениедә шулай язылган) деревни Елшанки говорят, что их подстрекает крестьянин деревни Утямышевой Николай Михайлов (по-татарски Ахмет Садык Танеев)... крестьяне деревень Больших Тархан, Сюндюковой, Утямышевой и Новоиркеевой... исполнять обряды православной веры отказались, говоря, что «лучше пойдут в Сибирь» ... Крестьяне при расспросах их о подстрекателях говорят большею частию о крестьянине деревни Утямышевой Николае Михайлове, который ездил и по другим деревням и, как поверенный от них, был в городе Казани для написания всеподданнейшего прошения, каковое, по показанию Михайлова, писал ему там какой-то коллежский регистратор Алексей Осипов Любимов... По Буинскому уезду содержание предписания было объявлено крещеным татарам, проживающим в г. Буинске, крестьянам сел: Пимурзина и Трех Болтаева (иначе Болтай Уразлеевой), деревень: Буинки, Сиушевой, Бюрган, Черепановой, Чикильдыма, Старых Тинчалей, Сорока Сайдак, Новой Задоровки, Дувановой, Старой Чекурской, Большой Аксы, Ишмурзино Суринской, Полевых Бикшик, Лащей... По выслушании объявленного татары объяснили, что они крещены никогда не были и поэтому христианами считаться не могут, оставить же магометанство, снова присоединиться к православию никогда не согласятся и допускать священников к совершению крещения, погребения и других треб не будут; даже чуваши деревни Чипкас Ильметевой утверждали, что они не чуваши, а татары.

...При расспросах исправника, кто хоронит их умерших и дает имена новокрещеным, они отвечали, что этим занимаются те из них, которые знают грамоту, но указать, кто именно, почти все отказались, кроме крестьян деревни Старых Тинчалей, которые назвали своего одножителя Латыф Азеева...

«

Донесениеләрнең Әхмәтсадыйкка кагылган өлешләрен оригинал хәлдә, ягъни русча язылган килеш, орфографик һәм стилистик үзенчәлекләрен саклап урнаштырабыз.

...Немедленно следует удалить из жительства всех лиц, на которые указываются как на подстрекателей, именно крестьян Симбирского уезда деревень Утямышевой Николая Михайлова (Ахмет Садык Танеева), Больших Тархан Алексея и Федора Сергеевых и отставного унтер-офицера Петра Сергеева ...».

Донесениенең бу өзегендә анык итеп әйтелгән: губернатор фикеренчә, Әхмәтсадыйк кебекләрне яшәү урынна-


№ 4404
154
2
20 нояб. 1874 г.
М. В. Д.
СИМБИРСКАГО ГУБЕРНАТОРА.
ПО КАНЦЕЛЯРІИ.
столъ 1
12 Ноября 1874 года.
№ 593.

Въ Департаментъ Духовныхъ Дѣлъ Иностранныхъ Исповѣданій.

Вслѣдствіе отношенія отъ 30 минувшаго Сентября за № 8059-мъ имѣю честь увѣдомить Департаментъ Духовныхъ Дѣлъ, что ходатайства крещеныхъ татаръ различныхъ деревень Симбирскаго и Буинскаго уѣздовъ о дозволеніи имъ исполнять обряды магометанской религіи возникли еще въ началѣ 1866 года. Всѣ такія просьбы присланы были изъ Министерства Внутреннихъ Дѣлъ бывшему Симбирскому Губернатору при предписаніяхъ отъ 6 и 14 Января 1866 года за №№ 25 и 68-мъ.

Вслѣдствіе этихъ предписаній


крещеныхъ татаръ, по мнѣнію его, слѣдовало немедленно выслать изъ предѣловъ здѣшней губерніи. Въ числѣ указанныхъ Губернаторомъ лицъ были, между прочимъ, и крестьяне селеній: Большихъ Тархановъ, Шаймурзиной, трехъ Бигитаевъ, Старыхъ Тинчалей, Чакадыма и Утямышева, упомянутыхъ въ поданныхъ 31 Августа сего года на Высочайшее имя прошеніяхъ.

Трое изъ указанныхъ Губернаторомъ лицъ: Буинскій купецъ Агдинъ, крестьяне дер. Утямышевой Михайловъ и Абдульменевъ, по распоряженію Господина Министра Внутреннихъ Дѣлъ (предписаніе 19 Іюня 1866 года № 68) высланы были въ то же время въ Туруханскій край.

Донося въ представленіи отъ 14 Августа 1866 года за № 341-мъ о результатахъ этой мѣры, бывшій Губернаторъ присовокупилъ,

Әхмәтсадыйкның Турухан краена сөрелүен раслаган документ архивта саклана (РГИА. Ф.821, оп.8, д.780)

рыннан көч куллану юлы белән куган очракта гына аларның башкаларга тәэсир итүеннән котылып булачак.

Икенче документта керәшеннәрнең үз ирегe өчен көрәшүләренә бәйле вакыйгаларга өстәмә ачыклык кертелгән. Биредә шул турыдагы мәгълүматны да урнаштырабыз, чөнки ул керәшеннәрнең максатларына ирешү юлында нык торуларын күрсәтә:

«...в 1866 г. между «отпавшими» крещеными татарами, отказавшимися крестить новорожденных детей, и православными священниками, прибывшими для увещания в д. Большие Тарханы, произошел серьезный конфликт. На увещание татары явились в тюбетейках, и священник потребовал их снять. Но татары отказались исполнить требование. Тогда по просьбе священника дьякон попытался снять тюбетейку с Алексея Сергеева, а тот ударил дьякона в висок и прогрозил то же самое над священником».

Министр 1866 елның 24 һәм 29 апрель көннәрендә губернаторга хәбәр иткән: *«...ходатайства их о дозволении возвратиться в магометанство не могут быть уважены ... ».*

1868 елның 23 декабрендә Боерган (24 кеше кул куйган), Чурапан (6), Иске Тинчәле (3), Биморза (15) һәм Чагылдым (12) керәшеннәре үзләре кул куйган үтенеч язуын Русиянең эчке эшләр министрына җибәрәләр. Үтенеч язуында министрга ошбу хәбәрне җиткерәләр: Борындыкта яңа чиркәү төзү һәм чиркәүдә каравыл торучыларга түләү өчен, өстәмә салымнан баш тартулары сәбәпле, Боерган авылы керәшеннәренең мөлкәтләрен алып китәләр: Ибәт Мәҗитовның самавырын

(10 сумга бәяләп) һәм мамык мендәрен (10 сум), Халит Мәүлетовның атын (30 сум) һәм мамык мендәрен (10 сум), Әхмәт Йосыповның атын (40 сум), Нигъмәтулла Йосыповның сыерын (20 сум). Моны, чиркәү руханилары күрсәтмәсе нигезендә, көч кулланып, хакимият вәкилләре башкарган.

Крестьяннар ни өчен турыдан-туры императорга мөрәҗәгать иткәннәр соң? Бу шуның белән аңлатыла: аларга Олы Тархан һәм Сөендек вулысларының җирләре патша указлары нигезендә бирелгән. Биредә яшәүче халыклар патша (соңрак – император) сараена буйсынган, хөкүмәт крестьяннары булып саналган, сарай файдасына салым түләгән һәм күптөрле дәүләт йөкләмәләрен башкарган. Мондый статустагы крестьяннар Иделнең Тау ягындагы авылларында байтак булган. Үтәмеш һәм башка авылларның керәшеннәре, үзләренең император крестьяннары икәнлеген белеп һәм аңлап, турыдан-туры аңа мөрәҗәгать иткәннәр һәм аның яклавына өмет баглаганнар. Әмма хатлары Эчке эшләр министрлыгыннан ары китмәгән. Хәер, алар император өстәленә барып җиткән очракта да, нәтиҗәсе шул ук булачак иде.

Сембер губернаторы министрга 1866 елның 19 октябрендә җибәргән хатында, Сембер һәм Буа өязләренең һәр авылында диярлек керәшеннәр элеккечә чиркәү йолаларын үтәмиләр, мөселманлыкта кала бирәләр, дип яза һәм аларны башка төбәкләргә күчерү кирәклеген тәкъдим итә.

Бу мәкаләдә күпсанлы документларның бары тик берничәсеннән генә өзекләр китерү белән чикләнәбез. Ләкин болары да нигезле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Керәшеннәр ике исем белән йөрергә мәҗбүр булганнар. Чиркәү руханилары аларны метрикаларга рус исемнәре белән теркәгән, ә ата-аналары балаларына татар исемнәре куштырган. Рус исеме христиан динендә булуны аңлатырга тиеш булса да, керәшеннәр үзләрен татар исемнәре белән генә танытырга тырышкан. 1866 елның февралендәге сорау алу вакытында Олы Тархан крестьяны үзе турында: *«Русча мине Леонтий Иванов дип атыйлар, ә минем исемем – Габдрахман Габдрахимов»*, – дип әйткән. Аның кебек үк, башкалар да (14 кеше) үзләрен татар исемнәре белән танытканнар: *«Данила Акимов түгел, Җомагол Бикҗанов», «Николай Акимов түгел, Зәбир Бикҗанов», «Егор Иванов түгел, Биктимер Бикиев»* һ.б.

Алдарак күрсәтелгән һәм башка бик күп документларны өйрәнү мондый нәтиҗәләргә китерә:

Сембер һәм Буа өязләрендә яшәүче татарларның керәшен булып саналу тарихы шушы без анализлаган документлар язылудан 200-250 еллар элек башланган. Аларның тарихи яктан еракта калган бабалары чиркәү метрикаларында христианлыкны кабул итте дип теркәлгән. Ләкин алар христиан йолаларын үтәмәгән, мөселман булып калган, балаларына да мөселманча тәрбия биргән.

Чиркәү руханилары да православие йолаларын үтәүне даими һәм эзлекле рәвештә таләп итмәгән. Бары тик балалар туу факты, аларга урыс исемнәре бирү белән чикләнеп, метрика кенәгәләрендә теркәп барганнар. Шулай итеп, аларның керәшен булулары, бары тик формаль рәвештә, күз буяу өчен генә, чиркәү метрикаларында саклаган. Әмма бу хәл Русия императорының 1835 елның 25 гыйнварында чыккан Указы аркасында бик кискенләшә. Бер үк вакытта Үтәмеш һәм аның якын-тирәсендәге авылларда яшәүче керәшеннәр белән идарә итү махсус оештырылган Кайсарово вулысына тапшырыла. Патша хөкүмәте Сембер һәм Буа өязләрендә яшәүче татарларның мөселманлыкка кайту өчен көрәшләрен хөкүмәткә каршы пропаганда дип атап, мөселманлыкка кайткан керәшен татарларына каршы күптөрле җәзалар куллана башлый.

Керәшеннәрне мөселман татарлар зиратына күмү тыела. Хөкүмәт органнары тарафыннан татар авылларында керәшеннәр өчен аерым зират булдыру таләп ителә һәм бу эш оештырыла да. Үтәмештә керәшеннәр зираты 1830-1840 елларда барлыкка килгән дип уйлыйбыз һәм ул XIX гасырның азагына кадәр файдаланудa булган. Әлеге зират хәзер инде юкка чыккан Тархан юлыннан авылга керүгә уң якта урнашкан була. XX гасырның кырыгынчы елларында да биредә кабер калкулыклары күренә иде. Үтәмешлеләр бу урынны керәшеннәр зираты дип атап йөртте. Каберлектә нинди дә булса тамга-билгеләр булмау сәбәпле, кемнәр күмелгәнлеген ачыклау мөмкин түгел иде. Анда агачлар һәм куаклар да үсми иде.

«Хөкүмәтнең Эчке эшләр министры, күпләп сөрелүчеләр булган очракта, халыкның көчле каршылык күрсәтү ихтималы булуын аңлап, өч кешене, шул исәптән Үтәмештән Әхмәтсадыйкны Себергә – Турухан краена җибәрергә әмер бирә.

Әхмәтсадыйк һәм аның көрәштәшләренең эшчәнлеге билгеле күләмдә уңай нәтиҗәләргә китергән. Сембер губернасында 1866-1868 елларда барган әлеге көрәштә барлык керәшеннәрнең 86,2 проценты катнашкан. 19 нчы йөзнең ахырына губернада керәшен дип саналган татарлар юк дәрәҗәсендә аз калган. Хөкүмәт татарларны мәҗбүри һәм көч куллану юлы белән чукындыру сәясәтен үзгәртергә мәҗбүр була. XIX гасырның азагында-XX гасырның башында татарларны көчләп чукындыру сәясәте күпмедер дәрәҗәдә йомшара, моны Үтәмеш мисалында да раслап була. Тик бу хәл әле хөкүмәтнең һәм чиркәүнең рус булмаган халыкларны, шул исәптән татарларны христиан диненә күчерү максатыннан ваз кичүен аңлатмый. Алар бары тик аңа ирешү ысулларын гына үзгәртәләр. Хөкүмәт керәшеннәрне христиан динендә калдыру һәм мөселман татарларны да шуңа тарту өчен башка юллар кирәклеген аңлый. Шуларның берсе – татарлар өчен рус мәктәпләре ачу һәм андый мәктәпләргә йөрүне мәҗбүри итү кирәк дигән тәкъдим кертү.

Хөкүмәтнең Эчке эшләр министры, күпләп сөрелүчеләр булган очракта, халыкның көчле каршылык күрсәтү ихтималы булуын аңлап, өч кешене, шул исәптән Үтәмештән Әхмәтсадыйкны Себергә – Турухан краена җибәрергә әмер бирә. Бу турыда 1866 елның 19 июлендә язылган һәм 68 саны белән теркәлгән предписаниедә әйтелгән. Сембер губернаторы 1866 елның 14 августында (341 санлы представление) министр әмеренең үтәлүен хәбәр итә. Димәк, Әхмәтсадыйк 1866 елның июль-август айларында Себергә сөрелгән. Бу турыдагы мәгълүматны без Русия эчке эшләр министрының 1874 елның 12 ноябрендә язылган хатыннан алдык. Әхмәтсадыйкның сөргендәге язмышы әлегә ачыкланмаган. Күпләргә билгеле булганча, Турухан краена, кулларына корал тотып, хөкүмәткә, дәүләткә каршы көрәшүче революционер-большевикларны сөргәннәр. Әхмәтсадыйк та алар дәрәҗәсендәге куркыныч җинаятьче булып саналган. Әмма Әхмәтсадыйк һәм аның кебекләр башлаган һәм алып барган көрәш билгеле бер дәрәҗәдә уңай нәтиҗәләргә дә китергән. Губернатор әлеге представлениесендә: *«...әмма бу хәл православие диненнән чигенгән татар һәм чуашларга күтелгән тәэсирне булдырмады»*, – дип өсти. ■

ТАТАР КИТАБЫ

Халкыбызның рухи юлбашчысы

Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. XVIII гасыр күчермәсе

Төрки-татарлар безнең эрага кадәрге чордан алып хәзерге көнгә кадәр рун язуы, уйгыр, гарәп, латин алфавитларын һәм кириллицаны кулланганнар. Язулы булу – мәгълүматлылык дигән сүз, ә мәгълүмат зур мәдәни көчкә ия. Китап күп гасырлар дәвамында төп һәм бердәнбер мәгълүмат чарасы булган. Татар мәдәнияте тарихында да ул мәртәбәле урын алып тора.

Халкыбызның борынгыдан ук китаплы халык булуы ислам дине белән бәйле. Ислам динендә «Китап» атамасы изге Коръән китабы дигәнне белдергән. Мөселманнар буларак, татарлар да, Китап дигәндә, иң беренче нәүбәттә, Коръәнне күздә тотканнар. Коръән сүзе, ягъни китап сүзе халкыбыз өчен иң газиз һәм мәртәбәле дәлил буларак кабул ителгән. Гыйлемгә, укуга, китапка сак мөнәсәбәт һәм тирән хөрмәт ислам диненең нигезенә үк салынган. Пәйгамбәребезнең (с.г.в.) күп хәдисләрендә гыйлем олыланган.

Тарихтан күренгәнчә, «Белем алу һәр мөселман кешесенә фарыз» дигән хәдискә татарлар аеруча тугрылыклы булырга омтылганнар. Татарлар арасында белем алуга, укуга карата гасырлар буе шундый мөнәсәбәт яшәп килгән. Нәтиҗәдә, татар халкының милли хасиятләре, ислам тәгълиматы белән аерылгысыз бербөтен рәвештә тыгыз бәйләнеп, халкыбызны иманлы һәм динле, мәгълүматлы һәм мәгърифәтле иткән.

Кайда гына яшәсәләр дә, татарлар мәчет төзергә, мәктәп-мәдрәсә ачарга, матбугат һәм китапчылык эшен гамәлгә куярга тырышканнар. Татар халкының аң-белемгә, китапка багышланган мәкаль һәм әйтемнәре, төрле дәвер әдипләренең шигырьләре һәм тирән мәгънәле канатлы сүзләре Китапны изгеләштергән.

Китапның төп асылын халыкның язуга ия булуы тәэмин итә. Идел-Урал буйларында яшәгән борынгы бабаларыбыз, ислам дине белән бергә, гарәп язуын да кабул итеп, халкыбыз бу язуны мең елдан артык кулланган. Гарәп язулы китаплар татарларның җанына ук изгелек күзәнәкләре кебек үрелгән.

Китапчылык үсеш алсын өчен тагын бер мөһим шарт – халыкта язма һәм басма сүзгә ихтыяҗ булу, аң-белемгә омтылышның югары дәрәҗәгә җитешүе, белем-уку йортларының үсеш алуы.

Кулъязма китап

Төрки-татар телендәге беренче дәвер борынгы китаплар гарәп хәрефләре белән язылган, ягъни кулдан күчерелгән китаплар кулланылышка кергән.

Татар кулъязма китабының мең елдан артык тарихы бар дип, хаклы рәвештә әйтә алабыз. Чөнки Идел-Урал буйларына гарәп язуы үтеп кергәч тә, Коръән һәм башка дини китапларны күчереп язу, шул рәвешчә тарату, мәктәпләр өчен дәреслек-кулланмалар булдыру тормышка ашырыла башлаган. Гарәп язуы һәм гарәп теле мөселман төрки-татарларның рухи тормышында озак дәверләр мәртәбәле урын биләп килгән.

Коръән. XVIII гасыр күчермәсе

Татар кульязма китабы тарихын тирәнтен өйрәнгән галим, академик, тарих фәннәре докторы Миркасыйм Госманов билгеләвенчә, татар кульязма китабы үсешенең иң югары ноктасы мәшһүр татар дәүләтләренең яшәү дәверенә – XIV-XVI гасырларга туры килгән. Әмма Казан ханлыгы һәм аннан соң башка татар ханлыклары яулап алынгач, татарларның рухи һәм дини, гомумән, төрле яклап кысрыкланулары нәтиҗәсендә, милли китапның яшәү һәм үсү мөмкинлекләре бик тарайган. Нәтиҗәдә, татар кульязма китабының эшләнеш сыйфаты түбәнәйгән. Тик мәсьәләнең икенче ягы куәтләнгән: ата-баба динен һәм туган телне саклау юнәлешендә татар китабы төп таяныч-терәккә, көчле идеологик һәм иҗтимагый факторга әверелгән. М.Госманов билгеләвенчә, татар басма китабы китапчылык өлкәсендә бай тәҗрибә тупланган җирлектә туган. Татар кульязма китабының сыйфатлары басма китапларга да күчкән.

Татар дәүләтләре бәйсез гомер кичергән дәверләрдә кульязма китап күчерү эше белән махсус белгечләр, нәфис язу осталары – хаттатлар, мулла-хафизлар шөгыльләнгән. Ә ханлыклар яулап алынганнан соң, бу эшне тулаем диярлек татар шәкертләре башкарган. Шул ук вакытта аерым хаттат-каллиграфлар, муллалар һәм укымышлы затлар да китаплар күчереп язган.

XVI гасырда китап күчергән затлардан исемнәре мәгълүм ике кешене атарга мөмкин. Шуларның берсе – **Адниш хафиз ибне Мөхәммәдаднаш хафиз**. Ул, Мәскәүгә илче итеп җибәрелгәч, тоткынлыкка эләгә һәм аның шул хәлендә 1554 елның җөмадиел-ахир (май) ае уртасында язып тәгәлләгән җыйнак кына җыентыгы билгеле. Ул хәзергәчә Мәскәүдә Россия дәүләт борынгы актлар архивында саклана. Әлеге җыентыкта «Сиражел-колуб» һәм «Шәраигыль-әхкям» исемнәрендәге ике чәчмә әсәр, шулай ук Әхмәд Ясәви һәм Сөләйман Бакыргани шигырь-хикмәтләре теркәлгән. «Сиражел-колуб» әсәренең асылы гарәп телендә булып, Адниш хафиз аны татар теленә фарсыча вариантыннан ирекле тәрҗемә иткән. Ул Казан ханлыгы чорының әдәби ядкяре булып исәпләнә.

1581 елда **Хаҗи Бәйрәм бине Хаҗи Булат** тарафыннан язылган гарәпчә-татарча сүзлек – XVI гасырга нисбәтле кыйммәтле кульязма ядкярләрнең икенчесе. Ул хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университетының Фәнни китапханәсендә саклана.

Китап күчерү белән XVII-XIX гасырларда шөгыльләнгән шактый хаттатлар билгеле. Мәсәлән, китап күчергән затлардан Иванай Урсай улы, Юныс Иванай улы, Габдрахман Туймөхәммәт улы, Илми Үтәмеш улы, Сәйфелмөлек Зәйнетдин улы, Габдерәшит Мортаза улы, Җәгъфәр Ягъкуб улы, Сөбхан Габделкәрим улы, Ибраһим Ядкяр улы, Минуш Мостай улы, Сәгъдетдин Габделҗәлил улы, Мозаффар Габделгаффар улы, Габдерәхим Утыз Имәни, Габделхәмит Динмөхәммәт улы, Гобәйдулла Кәлимулла улы, Газизҗан Мөхәммәтҗан улы, Хәйрулла Габделхәбир улы, Гайсә Туктаргали улы, Рәхмәтулла Әмирхани, Шиһабетдин Мәрҗани һәм тагын күп исемнәрне атарга була. Аларның күбесе гомерләре

Сиражел-колуб. 1554 елгы күчермә



Өмми Камал шигырьләре. XIX гасыр башы күчермәсе

буе китап күчерү шөгыленнән аерылмаган. Татар тарихында 20 яшеннән башлап 95 яше тулганчы барлыгы 223 китап күчереп язган Габденнасыйр Сабит улы, берничә йөз данә Коръән китабы күчергән Хөсәен Әлмөхәммәт улы, 70 яше тулганнан соң да китаплар күчергән Таҗетдин Хәсән улы, 90 яшенә хәтле бу эш белән шөгыльләнгән Сәйфулла Йөртекәй улы кебек фидакяр шәхесләрнең исемнәре билгеле. Шунысын искәртергә кирәк: китап күчерү белем, тырышлык, сабырлык белән бергә, бик күп вакыт та таләп иткән. Мәсәлән, Коръәнне һәм бүтән калын китапларны күчереп язу өчен 2-3 ай өзлексез тырыш хезмәт таләп ителгән.

Күркәм язулы һәм яхшылап төпләнгән кульязма китаплар шактый кыйммәт бәягә сатылган. Мәсәлән, тарихчылар Бөгелмә өязе Әлкәй авылында күчереп язылган Коръән тәфсиренең бер томы 1841 елда 200 сумга сатылу факты һәм ул чорда бер ат бәясе 20 сум торганлыгы турында язып калдырган.

Каурый яки камыш каләм белән кулдан язылган һәм күчерелеп тиражланган кульязма китаплар традициясе XIX гасырның икенче яртысына кадәр дәвам иткән.

Тарихи дәверләрдәге төрле фаҗигаләр, янгыннар, шулай ук гасырлар дәвамында татар халкын милли һәм дини изү сәясәте аркасында йөз меңләгән язма китапларның аз өлеше генә безнең көннәргә хәтле килеп ирешкән.

Татар кульязма китапларының шактый өлеше 1920-1930 елларда Совет илендә барган идеологик һәм сыйнфый көрәш дәверендә юкка чыгарылган. Кульязма китапларның дистә меңнәрчә нөсхәдә сакланып калуы бу мирасның элек гаҗәеп зур күләмдә булганлыгын дәлилли. Хәзергәчә килеп ирешкән кульязма татар китаплары эчтәлек ягыннан күптөрле тармакларга: дини әсәрләргә, матур әдәбиятка, халык авыз иҗатына, тарих, фәлсәфә, әдәп-әхлак, медицина, математика, география һ.б. күп фәннәргә карый.

Кульязма китаплар эшләнеш ягыннан мөселман дөньясының китапчылык традицияләрен дәвам иткән.

Мәшһүр шагыйрь Кол Гали XIII гасыр башында иҗат иткән «Кыйссаи Йосыф» әсәре хаклы һәм лаеклы рәвештә милли әдәбиятыбызның чишмә башы дип санала. Идел-Урал буйларында яшәгән татарлар, дини сюжетка нигезләнгән «Кыйссаи Йосыф»ны күп гасырлар өзлексез укып, әсәр геройлары белән бергә кайгырганнар һәм куанганнар, юаныч һәм гыйбрәт-сабак алганнар. Бөек әсәрнең сихри һәм шигъри куәте үзеннән соңгы татар һәм, гомумән, төрки телләрдәге тугандаш халыклар әдәбиятлары үсешенә гаҗәеп зур йогынты ясаган.

Хәзерге көндә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының фәнни оешмаларда, китапханәләрдә һәм музейларда саклана торган кульязма күчермәләре якынча 300 берәмлек тәшкил итә.

Татар язма истәлекләренең XVIII гасырдан элеккерәк чорларда иҗат ителгәннәре иҗтимагый, тарихи һәм табигый сәбәпләр (сугышлар, көчләп чукындыру, тузу-таушалу, янып юкка чыгу, дингә каршы көрәш, башка төрле бәла-казалар) аркасында аз сакланып калган. XVI-XVII гасырларда иҗат ителгән әсәрләр урын алган кульязмалар аеруча сирәк очрый. Әүвәлрәк язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының да

йөзләгән күчермәләре арасында XVII гасырга караганнары санаулы гына, барысы да диярлек XVIII һәм XIX гасырлардагы кулъязмаларда саклангаң. Болар белән бергә, кәгазьнең табигый саклану вакыты чикләнгән булуны да исәпкә алырга кирәк. Агач чималыннан эшләнгән кәгазьнең «гомере», яхшы шартларда саклаганда, 100 ел тирәсе булса, мамыктан ясалган кәгазьнең яше 400-500 елга җитәргә мөмкин. Шунлыктан борынгырак чорлардагы язма истәлекләрнең безнең көннәргә санаулы гына берәмлекләре килеп ирешкән.

Татар кулъязма китаплары белән фәнни кызыксыну XIX гасырның беренче дистә елларында башланган. Казан университетының татар теле укытучысы Ибраһим Хәлфин татар тарихи кулъязма чыганагының текстын өйрәнеп, аны «Әхвали Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» исеме астында 1822 елда Казан университеты матбагасында бастырып чыгарган. Татар шагыйре Габдерәхим Утыз Имәни гасырлар буе кулъязмалар хәлендә күпләп таралган һәм укылган борынгы әдәбиятыбыз җәүһәре «Кыйссаи Йосыф» әсәренең төрле күчермәләре нигезендә тәнкыйди текстын әзерләгән, аның беренче басмасы 1839 елда нәшер ителгән. Төрки-татар әдәби ядкярләреннән «Кисекбаш», «Ахырзаман», «Бәдәвам», «Мәликә китабы» кебек мәшһүр әсәрләр татар наширләре тарафыннан 1840-1850 елларда бастырылган һәм шул вакыттан башлап 60-70 ел эчендә аларның дистәләгән басмалары дөнья күргән. Халык арасында кулъязмалардан укып йөртелгән бүтән иске кыйссалар һәм дастаннар, шигъри әсәрләр дә шулай ук XIX гасырда бастырып чыгарылган. Шул рәвешчә алар бөтенләй онытылу һәм югалудан саклап калынган!

Хисаметдин Мөслими. Тәварихы Болгария. 1836 елгы күчермә

Татар кулъязма истәлекләрен өйрәнгән археографларның беренчесе буларак Ибраһим Хәлфин исәпләнсә, XIX гасырда Казан университетында эшләгән галимнәрдән Христиан Френ, Карл Фукс, Александр Казимбәк, Илья Березин, Иосиф Готвальд кебекләр дә татар язма чыганакларын өйрәнүгә игътибар биргәннәр һәм бу эшкә үз өлешләрен керткәннәр. Болардан тыш, XIX гасырда халкыбызның тарихи һәм әдәби язмаларын тикшерүгә татар галимнәре Габдерәхим Утыз Имәни, Хөсәен Әмирханов, Шиһабетдин Мәрҗани, Хөсәен Фәезханов һәм Каюм Насыйри күп көч куйганнар. Аларның эшен мәшһүр шәхесләр Галимҗан Баруди, Ризаэддин Фәхреддин, Габдулла Апанаевлар дәвам иткән. Татар кулъязмаларын туплап өйрәнүгә Николай Катанов та шактый өлеш керткән.

Р.Фәхреддин XX гасырның башында һәм беренче чирегендә дә татар археографик истәлекләрен туплау һәм тикшерүне дәвам иткән. Бу өлкәдә шулай ук Сабир Алимов, Сәед Вахиди, Нәүширван Яушев, Фазыл Туйкин, Гали Рәхим, Вәли Зәбиров, Габделхәй Хәбибуллин, Әбүкәрам Шакиров тырышып хезмәт куйганнар. Татарстан Мәгариф халык комиссариаты карамагында 1921-1930 елларда

эшләгән Гыйльми үзәк (Академүзәк) тарафыннан кульязма истәлекләрне барлау, туплау һәм өйрәнүгә зур игътибар бирелгән. Әмма, XX гасырның дәһшәтле 30 нчы елларында татар кульязма ядкярләрен өйрәнүчеләрнең репрессияләнүләре сәбәпле, фәнни оешмаларда археографик эзләнүләр шактый кимегән. 1940 елларда мөгаллим һәм рәссам Сәлах Камал, танылган педагог Шәриф Сайкин, әдип, драматург һәм фольклорчы галим Нәкый Исәнбәт кебек аерым фидакяр затлар гына татар кульязма истәлекләрен чикләнгән күләмдә барлау һәм өйрәнү белән шөгыльләнгән.

1950 еллардан алып татар кульязма мирасын өйрәнгән галимнәрдән Гаяз Ишмөхәммәтов, Зәйнәп Максудова, Әмир Нәҗип, Габдрахман Таһирҗанов, Мостафа Ногман, Шакир Абилов, Җәвад Алмаз, Фазыл Фасиев исемнәрен атарга кирәк.

1959-1992 елларда Казан дәүләт университеты Фәнни китапханәсенең Шәрык кульязмалары секторы мөдире булып эшләгән галим Альберт Фәтхи – татар кульязма чыганакларын җыю һәм өйрәнү эшенә иң зур өлеш керткән белгечләрнең берсе.

1963 елда Казан дәүләт университетының фәнни-археографик экспедицияләрен оештырган һәм аларны 1987 елга хәтле җитәкләгән галим Миркасыйм Госманов татар археографиясендә тирән эз калдырды.

Филология фәннәре докторы Марсель Әхмәтҗанов 1972 елдан алып татар кульязма чыганакларын туплауда һәм өйрәнүдә армый-талмый хезмәт куя. Ул Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Мирасханә»сенең мөдире булып эшләде, меңләгән кульязма истәлекләрне өйрәнеп, матбугатта чыгарды.

Археографик мирасны өйрәнүгә һәм пропагандалауга әдәбиятчы-текстолог галимнәрдән Хәй Хисмәтуллин, Якуб Агишев, Хатыйп Госман, Нил Юзиев, Мәсгуть Гайнетдин, Марсель Бакиров, Хатыйп Миңнегулов, Камил Дәүләтшин, Рафис Әхмәтов, Әнвәр Шәрипов, Әнвәр Хәйри, Сәлим Гыйлаҗетдинов, Нәҗип Исмәгыйлев (Нәккаш) кебекләр үз өлешләрен керттеләр. Тарихчы һәм археограф Дамир Гарифуллин татар кульязмаларын туплаучы һәм пропагандалаучы буларак танылды. Өлкән буын галимнәргә алмашка 1980–1990 елларда Җәүдәт Миңнуллин, Фәрит Яхин, Раиф Мәрданов, Ильяс Мөстәкыймов, Айрат Заһидуллин килде.

XVIII гасырдан алып 21 нче йөз башына кадәр татар кульязма истәлекләрен өйрәнгән археограф галимнәр, әдәбиятчы-текстологлар тырышлыгы нәтиҗәсендә, дистә меңнәрчә тарихи ядкярләр сакланып калды, бик күп язма чыганаклар өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде. Гомумтөрки язма истәлекләр белән беррәттән, Идел буе татар әдәбияты һәм тарихы җәүһәрләреннән Өмми Камал, Мөхәммәтәмин, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Кадыйргали бәк, Мәүла Колый, Габди, Габдессәлам, Батырша, Габдерәхим Утыз Имәни, Колмөхәммәд Ушмави, Әбелмәних Каргалый, Габделҗәббар Кандалый, Акмулла һәм башка күп авторларның әсәрләре, «Түләк», «Чыңгызнамә», «Аксак Тимер», «Таһир белән Зөһрә» кебек мәшһүр дастаннар, «Кисекбаш», «Авык» һәм бүтән кыйссалар, тарихи елъязмалар, сәяхәтнамәләр, җыр һәм бәетләр кебек бай фольклор әсәрләре, шулай ук татар халкының иҗади-рухи хәзинәсенең башка мәрҗәннәре халыкка кайтарылды.

Хәзерге вакытта татар кульязма китапларының меңләгән күчермә нөсхәләре, нигездә, Казан, Петербург, Мәскәү һәм Уфа шәһәрләрендәге архивларда, фәнни китапханәләрдә һәм музейларда саклана. Шулай ук Әстерхан һәм Төмән калалары, Урта Азия, Европа һәм Шәрык-мөселман илләренең китапханә, музей һәм архивларында саклана торган татар кульязмалары да аз түгел. ■

Ядкярләрдән безгә тарих бага...

Альберт Борһанов

Мөслимлеләр булдыра!

Соңгы елларда Мөслим районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешен булдыру өчен зур эшләр башкарыла. Мөслимнең матур табигате, күркәм итеп төзекләндерелгән урам, парклары һәм социаль объектлары 2018 елда Укытучыларның август киңәшмәсенә килүчеләрне һәм 2019 елның мартында Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары форумы делегатларын таң калдырды. 2018 елда район үзәге булган Мөслимдә уникаль архитектура корылмасы – җәмигъ мәчете ачылды. Шунда ук мәдрәсә, китапханә һәм музей да бар. Музеенда исә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның үзе исән вакытта ук басылып чыккан китаплары саклана! Хәзерге вакытта Мөслимдә Бөтенроссия авыл Сабан туена, Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан һәм ТАССРның 100 еллыгын билгеләп үтү максаты белән, җитди әзерлек эшләре алып баралар.

Әмма безне, тарихчы-археологларны, иң сөендергәне Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Муллинның һәм мөслимлеләрнең мәдәни мираска уңай мөнәсәбәте булды. Ә бит Мөслим районы һәм Ык елгасы бассейнының аңа чиктәш булган биләмәләре – Идел-Урал төбәгендәге, гомумән, Евразиядәге борынгы һәм урта гасырлар цивилизацияләренең иң мөһим үзәге тарихи яктан бик аз өйрәнелгән иде. А.П.Шокуров, Е.П.Казаков, П.Н.Старостин һәм Р.С.Габәшевларның 1950-1970 елларда үткәргән тикшерү эшләреннән тыш, Ык буе төбәгендә зур күләмдәге комплекслы археологик казу эшләре үткәрелмәгән.

Тамьян авылы янында археологик казу эшләре

Катмыш авылы зиратын өйрәнү

2014 елдан башлап, безнең һәм туган якны өйрәнүчеләрнең тәкъдимен истә тотып, районда тарихи-археологик фондларны һәм коллекцияләрне өйрәнү һәм саклау, ә иң мөһиме – «Туган якны өйрәнү музее»н реконструкцияләү буенча зур эш башланып китте.

2015 елның җәендә А.Борһанов җитәкчелегендәге Алтын Урда тарих-археология экспедициясе тарафыннан Мөслим районында киң масштаблы, комплекслы тикшерү эшләре башкарылды. Элек билгеле булган тарихи объектларның урнашу урыннары һәм хәзерге торышы төгәлләштерелде, яңа археологик, эпиграфик, архитектура һәм сәнгать һәйкәлләре ачыкланды, борынгы торак пунктларның тарихы, мәдәнияте буенча яңа мәгълүматлар җыелды, авыл һәм мәктәп музейларының, туган якны өйрәнү почмакларының коллекцияләре өйрәнелде.

Нәтиҗәдә, элегрәк булган һәм яңа табылган материаллар нигезендә, ТР Милли музее (М.М.Хәйруллина һәм М.П.Новикова) ярдәмендә, тарихчы-археолог А.А.Борһанов, төбәкне өйрәнүче С.Я.Җаббарова һәм рәссам Р.И.Тимкин катнашында, фундаменталь реконструкциядән соң, 2015 елның августында заманча экспозицияләр һәм бай фонд белән Мөслим «Туган якны өйрәнү музее»ның яңа бинасы ачылды. Хәзерге вакытта музейга республикабызда уздырыла торган төрле халыкара һәм Бөтенроссия чараларында катнашучылар гына түгел, ә Көнчыгыш Татарстанның һәм Көнбатыш Башкортстанның башка төбәкләрендә яшәүчеләр дә актив йөри. Күптән түгел генә музей карамагында өр-яңа, заманча бина – «Батырлар йорты» да сафка басты.

Археологик ядкярләр ни сөйли?

«Татарстан АССРның археологик картасы» (1989 ел) һәм безнең яңа тикшеренү материаллары буенча, Мөслим районында таш, бронза һәм тимер дәверләреннән алып урта гасырларга кадәр булган вакытны эченә алган 60ка якын археологик объект бар дип әйтергә була. Аларның күбесе Ык елгасы бассейнында һәм аның кушылдыклары буенда урнашкан. Борынгы торак эзләр Рус Шуганы, Олы Чакмак, Мазин, Табын, Мәлләтамак, Тамьян, Керәш-Шуран һәм башка авылларда ачыкланды.

Әмма, Ык елгасы ярлары даими рәвештә үзгәреп тору сәбәпле, кеше яшәгән борынгы урыннар, каберлекләр һәм курганнар, шәһәрлекләр юыла, археологик ядкярләр җимерелә. Елга ярлары юылу нәтиҗәсендә һәм хуҗалык объектлары, йортлар төзү барышында биредә яшәүчеләр еш кына металл, керамика, сөяк һәм ташлардан ясалган уникаль әйберләр табалар. Бу предметларның күбесе сатыла, шәхси коллекционерлар кулына килеп эләгә, ә иң куркынычы – Татарстаннан читкә чыгарыла. Шунысы куанычлы: Мөслимдә җирле халык тарихи-археологик ядкярләргә битараф түгел: төрле елларда табылган әйберләрнең күпмедер өлеше «Туган якны өйрәнү музее» фондына тапшырыла килгән. Шундый энтузиастлардан Керәш-Шуран авылында яшәүче хезмәт ветераны Развит Әскәр улы Галиевне искә алыр идем. Ташлы Яр авылы янында табылган әйберләрне 2017 елда Әлфия Васил кызы Елистратова музейга бүләк итте.

> **Рамил Муллин,** Мөслим муниципаль районы башлыгы: **«Балаларның күңелендә: «Мөслим җирендә борынгы заманнан ук кешеләр яшәгән икән, нигә бүген монда калмаска, ә читкә китәргә кирәк», – дигән уй тусын иде. Тарих, тел, әдәбият, мәдәният, мәгариф, дин бергә кушылса гына көчле».**

Шулай итеп, үзем дә 2016-2017 елларда Табын, Ташлы Яр, Шуган, Керәш-Шуран, Салауз-Мухан, Тамьян, Иске Чакмак авылларында юлыккан 620дән артык экспонатны, тәфсилләп өйрәнгәннән соң, Мөслим «Туган якны өйрәнү музее»на тапшырдым. Табылдыклар арасында аю тешләреннән ясалган сөяк амулет, акула тешләре, күкәй сыман формадагы керамик ядрә аеруча зур кызыксыну уята. Соңгы предмет эче тиз янучан сыеклык белән тутырылып, дошман өстенә ыргытыла торган утлы корал буларак кулланылган. Ядкярләрнең төп өлешен төрле орнаментлар белән бизәлгән савыт фрагментлары тәшкил итә. Аларның шактые бронза һәм тимер дәверләренең башлангыч чорына карый.

2015 елда Тамьян авылы янында археологик казу эшләре оештырдык. Бу тикшеренүләр барышында биредә б.э.к. I меңьеллыкта ук кешеләр яшәгәнлеге ачыкланды. Әлеге борынгы җирлекнең хәзерге рельефы курганны хәтерләтә, мәдәни катламы 130 см тәшкил итә. Табышларның төп өлешен керамик савыт-саба, имезүче хайваннарның сөякләре, бронза очлык, сөяктән һәм таштан ясалган әйберләр тәшкил итә. Эш барышында бу объектның Ык елгасы бассейны төбәге тарихының башлангыч этапларын алга таба тикшерү өчен перспективалы урын булуы ачыкланды.

Музейга тапшырылган табылдыкларның бер өлеше урта гасырларның башлангыч чорларына, Идел Болгарстаны, Җучи Олысы (Алтын Урда), Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы дәүләтләре чорларына карый, шулай ук XVII-XIX гасырларга нисбәтле керамик савыт-саба фрагментлары да бар. Табылдыклар арасында кием-салымның металл элементлары, ат йөгәннәрен бизәү элементлары, төсле металл эшләнмәләр дә аз түгел.

Б.э.к. III - б.э.ның III гасырына караган, бронзадан ясалган бизәкле, эполетсыман берничә перәшкә кызыклы. Шулай ук күкрәкчәләр, кыңгырау формасындагы бизәнү әйберсе, алкалар һәм медальоннар да табылды. Кыйммәтле ташлардан, керамикадан, пыяладан, сөяктән, металлдан ясалган муенса рәвешендәге бизәнгечләр дә игътибарга лаек. Табылдыклар арасында бизәнү әйберләренең төсле металлдан вак элементларын ясау өчен таш калып та бар.

Шулай ук археологик экспонатлар арасында X-XIV гасырларга караган ук очлары, скиф төрендәге акинак (б.э.к. VI-IV гасырлар), тимер балталар, сөңге очлары, гарпуннар, кискечләр, кадаклар, йозаклар һәм ачкычлар барлыгын искәртәбез...

Гомумән, экспедиция эшендә җирле халык, аерым алганда, «Туган якны өйрәнү музее» рәссамы Р.И.Тимкин, Мөслим гимназиясенең тарих укытучысы И.Н.Юлдашев, гимназия укучылары Алмаз Шакиров, Раил Шәмсиев, Шамил Баев, Ленар Латыйпов һәм башкалар бик теләп катнашты.

Ташларга язылган тарих

Комплекслы экспедиция вакытында Мөслим һәм аңа чиктәш районнарның зиратларындагы эпиграфик һәйкәлләр дә читтә калмады. Аларны фотога төшердек, үлчәмнәрен алдык. Бу эштә безгә җирле халыкның ярдәме аеруча зур булды.

Кызганыч ки, табигать шартлары тәэсирендә, тамгалы һәм гарәби язулы күпсанлы кабер ташлары юкка чыккан яки авып, җиргә иңгән. Моннан тыш, патша һәм совет чорларында ташъязма ядкярләр кешеләр тарафыннан да җимерелгән, хуҗалык корылмаларының нигезләренә төзелеш материалы буларак файдаланылган. Мәсәлән, совет чорында Катмыш авылы янындагы терлекчелек комплексын төзегәндә шундый ташларны кулланудан тайчынмыйлар. Биредә без тугыз кабер ташының сакланып калганын ачыкладык. Алар барысы да янәшә ята иде.

Экспедиция вакытында

Уникаль кабер ташлары Тугаш авылының ике зиратында да саклана. Зиратның берсе шактый борынгы, биредә таш склеп һәм дүрт кабер ташы бар.

Тойгелде авылының борынгы зиратында безнең тарафтан 26 кабер ташы теркәлде. Болар буенча әлеге каберләргә җирләнгән мәрхүмнәрнең кем булуы, аларның шәҗәрәсе, нәсел дәвамчылары хакында бик күп мәгълүматлар белергә мөмкин.

Олы Чакмак зиратында – 17 , Тамьянда – 12, Митрәйдә – 10, Тугашта 18 кабер ташы сакланып калган.

Тугаш, Олы Чәкмәк, Чалпы (Азнакай районында) кебек авылларның зиратларында аерым нәсел каберлекләре бар. Гарәби язулы әлеге бай мирас киләчәктә җитди өйрәнүне таләп итә.

Үрнәк булырлык эш!

Татарстан Республикасының күп кенә районнарына хас, әмма Мөслим районында дөрес хәл ителгән бер проблемага тукталасым килә. Авылларда мәктәпләрнең, клубларның ябылуы яки аларның статуслары үзгәрү, җитәкчеләре алмашыну сәбәпле, анда урнашкан музейларның коллекцияләре юкка чыга. Мәсәлән, җирле халыкның әйтүенә караганда, Минзәлә районының Яңа Мазино авылы мәктәбе музеенда саклаучы археологик ядкярләрне мәктәп директоры лаеклы ялга киткәндә үзе белән алып киткән булып чыкты.

Әмма мөслимлеләр әлеге проблеманы башкача хәл итте. Аерым алганда, Салауз-Мухан мәктәбендәге безнең эраның III гасырына нисбәтле күп кенә археологик табылдыклар, шулай ук XVII-XIX гасырларга караган татар һәм рус мәдәнияте предметлары укытучылар коллективының һәм мәктәп директоры Д.Н.Магалимов тырышлыгы белән 2015 елга кадәр югалтуларсыз сакланды. Ә 2016 елда мәктәпнең статусы үзгәрде һәм, безнең тәкъдимебез буенча, барлык бу ядкярләр Мөслимнең «Туган якны өйрәнү музее»на даими саклауга тапшырылды.

Моның өстенә, Мөслим муниципаль районы башлыгы Рамил Муллин күрсәтмәсе буенча, авыл мәктәпләрендәге музейларның, музей-почмакларының барлык коллекцияләре исәпкә алынды һәм төрле урыннарда саклана торган экспонатларның бердәм исемлеге булдырылды. Шунысы әһәмиятле – иң кыйммәтле тарихи ядкярләр Мөслимнең «Туган якны өйрәнү музее»на саклауга һәм экспозицияләргә тапшырылды. Бу табылдыкларның күбесе хәзер җентекләп өйрәнелде һәм фәнни әйләнешкә кертелде. ■

Мөслимнең «Туган якны өйрәнү музее»

•1966 елда Мөслим урта мәктәбенең тарих укытучысы, РСФСРның һәм ТАССРның атказанган укытучысы Нурдидә Галиева тарафыннан мәктәп музее оештырыла.

•1989 ЕЛДА МӨСЛИМ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ РАЙОН ҮЗӘГЕНДӘ «ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ» АЧУ ТУРЫНДАГЫ КАРАР ЧЫГАРА. БУ ҖАВАПЛЫ ЭШКӘ ЯЗУЧЫ, ТӘНКЫЙТЬЧЕ, ЖУРНАЛИСТ НАИС ГАМБӘР, ШАГЫЙРЬ ҺӘМ ПЕДАГОГ МӨҖӘҺИТ ӘХМӘТҖАНОВ АЛЫНА. БИЗӘҮ ЭШЛӘРЕН ҮЗЕШЧӘН РӘССАМ РӘЙХАН ХАНТИМЕРОВКА ТАПШЫРАЛАР. МУЗЕЙ 1990 ЕЛДА АЧЫЛА. НАИС ГАМБӘР МУЗЕЙНЫҢ БЕРЕНЧЕ ДИРЕКТОРЫ БУЛА.

Археолог Альберт Борһанов җитәкчелегендәге төркем казу эшләре вакытында



• 1992 елда Мөслим урта мәктәбендә тупланган 3500 экспонат район музеена тапшырыла.

• 2014 елда музей өчен сәнгать мәктәбенең элеккеге бинасына реконструкция ясала.

«Бисмиллалы йорт» (Баланлы авылы)

• 2015 ЕЛДА, РЕСПУБЛИКА МИЛЛИ МУЗЕЕ ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕНЕҢ ЯРДӘМЕ БЕЛӘН, ЭЧКЕ ЭКСПОЗИЦИЯ ЗАЛЛАРЫ ЭШЛӘНӘ.

Баланлы авылы

Безнең мирас №7 июль 2020

Наис Гамбәр

КАЙТСАМ

Кайтамын да… китә алмый ятам,
Көннәр, төннәр ятам интегеп;
Бураннары чыкса – бишмәтем юк,
Яңгырлары яуса – итегем.

Мин гел шулай: кайтсам – китмәс өчен
Бер-бер хәйлә табам, алдашам;
(Йөрәгемдә – утлар, мин су эчәм
Атлар белән агач ялгаштан.)

«Акыллылар» әйтәдер дә (бәлкем?) –
Йөри шунда тик эт сугарып;
Этем түгел, атым сугарулы, –
Кайту белән ташлыйм тугарып.

Тугарылып ташлыйм кайту белән, –
Камыт суккан төшләр ял алсын!
Тик син генә, Ыгым, мәңге тынмас
Яраларны җөйли аласың.

Суың җылы синең, тының җылы –
Синдә генә басам сусынны.
Атлар ялгашыннан сулар эчәм –
Җирсү, сусау әллә шушымы?!

Җиккән атлар тора өй каршымда,
Син сорама: «Тагын кай таба?»
Кайтмам, диеп китәмен дә,
Мөслим, әфсеннәрең тартып кайтара.

Зифа Басыйровага багышланган күргәзмә

• МУЗЕЙДА «ТАБИГАТЬ ҺӘМ БОРЫНГЫ ТАРИХ», ИКЕ ӨЛЕШТӘН ТОРГАН «ЭТНОГРАФИЯ», «СОВЕТ ЧОРЫ», «ДАН» ЭКСПОЗИЦИЯЛӘРЕ ҺӘМ КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫ ЭШЛИ.

• 2017 елда район мәдәният йортында Мөслимнең «Әдәбият-сәнгать музее» ачылды. Биредә язучылар – Зариф Мөэминов, Флүс Латыйпов, Фоат Садриев һәм Факил Сафин, шагыйрьләр Зөлфәт, Мөҗәһит Әхмәтҗанов һәм Наис Гамбәр, җырчы Зифа Басыйрова һәм башкаларга багышланган стенд-күргәзмәләр бар.

• МӨСЛИМНЕҢ «ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ» ФОНДЫНДА 7 МЕҢГӘ ЯКЫН ЭКСПОНАТ САКЛАНА.

Митрәй авылының ындыр табагы. 1950 нче еллар

• 2020 елның 24 июнендә «Батырлар йорты» ачылды. Заманча итеп эшләнгән әлеге музейда Мөслимнән чыккан барлык каһарманнар, фронтовиклар турында да мәгълүмат алырга мөмкин. ■

Безнең мирас №7 июль 2020

Милли көрәш төрләре

Мәгаз Сәхәбетдинов

Грузин көрәше

Молдаван көрәше (трынтэ). Күлмәк-чалбардан көрәшәләр. Билгә йомшак билбау – шарф буыла. Көндәшләр бер-берсен билләреннән яисә билбаудан эләктерәләр. Аяк ярдәмендә, аяк аша егу, аякларга кул белән кагылу тыела. Максат – көндәшне берьюлы ике калак сөягенә ташлау. Дәвамлылыгы – 10 мин.

Үзбәк көрәше (кураш). Көрәш Бохара һәм Фирганә кагыйдәләре буенча алып барыла. Йомшак билбаулы милли халаттан көрәшәләр. Көндәшләр бер-берсенең билбавын уң кул белән аркадан урап тоталар. Билбауны ычкындырырга ярамый. Сул кул белән теләсә кайсы җирдән тотарга мөмкин. Көндәшен аркасына салганы җиңә. Тик аяк аша егу тыела. Дәвамлылыгы – 10 мин.

Казакъ көрәше (курес). Йомшак билбаулы милли халаттан көрәшәләр. Билне буып, халатсыз гына да көрәшергә мөмкин. Кулларын билбаудан ычкындырмыйча, көндәшен аркасына салган көрәшче җиңә. Аяк аша егу рөхсәт ителә. Дәвамлылыгы – 15 мин.

Кыргыз көрәше (курес). Йомшак билбаулы милли халаттан көрәшәләр. Билбаудан эләктереп тотарга да, билдән өскә таба башка урыннан тотарга да, аяк аша ыргытырга да рөхсәт ителә. Көндәшен аркасына салган көрәшче җиңгән исәпләнә. Дәвамлылыгы – 15 мин.

Таҗик көрәше (гушти). Йомшак билбаулы милли халаттан көрәшәләр. Билбаудан теләсә ничек эләктерергә дә, якадан, җиңнән тотарга да рөхсәт ителә. Билдән

түбән төшү тыела. Аяк аша ыргытырга мөмкин. Көндәшен аркасына салган (сыңар калак сөягенә дә ярый) көрәшче җиңә. Дәвамлылыгы — 10 мин.

Төрекмән көрәше (гөреш). Йомшак билбау белән буылган милли халаттан көрәшәләр. Билбаудан һәм халатның билдән югары теләсә кайсы урыныннан эләктереп тоталар. Көндәшенең гәүдәсен җиргә өч нокта белән кагылырлык итеп аркасына салган көрәшче җиңә. Аяк аша ыргыту рөхсәт ителә.

Грузин көрәше (чидаоба). Өс киеме – нык материалдан тегелгән кыска куртка, трусы һәм «чоха» дип аталган билбау. Кұртканың итәк өлешләре артка каерылып бәйләнгән була. Шуның өстеннән билбау буалар. Чоханың теләсә кайсы җиреннән эләктерергә рөхсәт ителә. Билдән түбән тоту тыела. Аяк аша да ыргытырга мөмкин. Җиңүче көндәшен аркасы белән келәмгә төшерергә тиеш. Тик ул аны келәмгә кысмый һәм куллары белән әйләндерми. Саф җиңүгә ирешмәгән көрәшчегә «ярты җиңү» бирелә. Көрәш милли музыка аһәңнәре астында бара. Дәвамлылыгы – 5 мин.

Әрмән көрәше (кох). Махсус әзерлекле көрәшчеләр, «чоха» дигән халат киеп, йомшак билбау бәйләп чыгалар. Көрәшкәндә билбаудан, «чоха»дан билдән югары тоталар. Аяк аша ыргыту тыелмый. Көрәшче көндәшен аркасына сала, келәмгә төшкәч, аны аркасына әйләндерү хаҗәт түгел. Дәвамлылыгы – 7 мин.

Якут көрәше (курдацан тустуу). Өс киеме – билбау һәм кыска трусы. Билбаудан гына эләктереп тотарга рөхсәт ителә. Аяк чалу тыелмый. Максат – көндәшне өч нокта белән җиргә кагылырлык итеп егылдыру. Дәвамлылыгы – 10 мин.

Тувалылар көрәше (хуреш). Өс киеме – арка һәм җиңнән генә торган махсус куртка – «содак» һәм калын материалдан тегелгән трусы. Куртка алгы яктан чи тиредән ясалган киң тасмалар белән беркетелгән. Көрәшче көндәшен куртка, трусыдан яисә тәненең теләсә кайсы җиреннән эләктерә. Аяк аша ыргытырга да рөхсәт ителә. Максат – көндәшне дүрт ноктасы белән келәмгә кагылырга мәҗбүр итү. Дәвамлылыгы – 6 мин.

Азәрбайҗан көрәше (гюлеш). Өс киеме – тездән түбәнрәк төшеп торган махсус чалбар, билдә – йомшак материалдан билбау. Көрәшче көндәшен гәүдәсеннән, аягыннан, билбавыннан, чалбардан эләктерә. Аяк чалырга да рөхсәт ителә. Партерда көрәшкәндә көндәшне аяклар белән аркасына әйләндерергә мөмкин. Максат – көндәшне аркасы белән келәмгә терәү. Дәвамлылыгы – 7 мин.

Төньяк Кавказ халыкларында киң таралган көрәш (тутуш). Өс киеме – куртка, йомшак билбау, йомшак аяк киеме. Көндәшләр, бер кул белән билбауның арка ягыннан эләктереп һәм икенче кул белән гәүдәнең билбаудан югары теләсә кайсы урыныннан тотып, аяк ярдәмендә бер-берсен тотрыклылыктан яздырырга омтылалар. Максат – үзе аяк өстендә калып, көндәшне аркасы белән келәмгә ташлау. Дәвамлылыгы – 7 мин.

Калмык көрәше. Өс киеме – кыска чалбар, билбау. Максат – көндәшне, келәмнән аерып алып, аркасына салу. Дәвамлылыгы – 8 мин. ■

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Токио. XX гасыр башы

Университет китапханәсе

Бераздан, саубуллашып, китәргә дип җыенгач, китапханә хезмәткәре, мөлаем елмаеп: «Бик озак аякта калдыгыз, рәхим итеп, бераз ял итеп алыгыз», – дип, үз бүлмәләренә чакырды. Бу бик җыйнак бүлмәдә утырып ял иттем. Чәйләр эчкәч, ишектә кулына төргәк тоткан бер кеше күренде. Китапханә хезмәткәре болай диде:

– Әгәр бик арымаган булсагыз, сезгә китапханәдә саклана торган кульязмаларны да күрсәтергә теләр идем.

– Әлбәттә, нинди борынгы язмалар бар, мөмкин булса, барысын да күрсәтүегезне үтенәм.

Китапханә хезмәткәре төргәктән саргайган кәгазьләр чыгарды. Алар шактый күп һәм борынгы булулары кәгазьләренең сыйфатыннан күренеп тора иде. Араларыннан бер кәгазь алып ачты һәм болай диде:

– Бу – моннан 618 ел элек язылган язу, җиргә хуҗа булу турындагы таныклык. Ул вакытларда мондый җир һәм милек таныклыклары, әгәр сатучы яза белмәсә, укый-яза белә торган башка берәү тарафыннан языла торган булган. Сатучы кеше исә, сул кулының имән бармагын кәгазьгә, имза куеласы урынга куеп, төбеннән очына кадәр бер сызык сыза, аннары буыннары урынында нокта төртә икән.

Бу кәгазьдән сызып алганча, сызык һәм нокталарны биредә хөрмәтле укучыларыма күрсәтеп үтәм.



Имза урынына куела торган сызык

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Сызык – бармакның озынлыгын, нокталар буыннарны күрсәтә. Моның артыннан тагын бер язу күрсәтте. Анысы моннан 744 ел элек язылган һәм ул вакытларда хөкемдар булган императрица тарафыннан расланган, ди. Китапханә хезмәткәре, шул рәвешле, боларга охшаш бик күп борынгы язмалар күрсәтте һәм шуларның күбесе турында сөйләп тә бирде. Иң соңыннан бер китап китерде һәм болай диде: *«Бу исә – безнең уку йортыбызның елъязмасы. Хәзерге вакытта уку йортында 6824 студент теркәлгән. Укытучыларыбыз барысы да япон милләтеннән. Моннан 20 ел элек 30га якын чит ил кешесе дә бар иде. Биш елдан соң Япониядә чит илдән килгән укытучылар бөтенләй дә калмаячак. Бүгенге көндә диңгез уку йортында килешү буенча эшләүче бер инглиз кешесе генә бар. 5 елдан соң аның килешүенең дә вакыты тәмамлана».*

Моннан соң тагын уку йорты бүлекләрен карап йөрдем. Бигрәк тә операцияләр бүлемендә берничә тапкыр булдым, авыруга ничек итеп операция ясауларын карап тордым.

Артыгы белән игътибарга лаек бер күренеш турында әйтеп үтим. Операция бүлегендә бер дәрес бүлмәсе бар, пыяла гөмбәз кебек. Студентларга утырыр өчен куелган урындыклар бронзадан ясалган иде. Шулкадәр сәнгати итеп ясалган ки, шаккатып каласың. Монда да, студентлар арасында утырып, анатомия дәресен карадым.

Шул рәвешле, университетның (японнар университетка, «дайгакко», диләр) бөтен җирен карап йөрдем. Аннары университет хастаханәсен дә барып карадым. Биредә биналар бик зур булмаса да, бар җир искиткеч тәртиптә иде. Монда килгәч, барыннан да элек, өс һәм аяк киемен салып, башка киемнәр киюемне үтенделәр. Аякка атлаганда тавыш чыгармый торган башмаклар бирделәр. Табибларның берсе минем белән бергә йөрде, бөтен бүлекләрне күрсәтте. Һәр бүлекнең ишек төбенә килгәнче, бу бүлектәге авырулар турында сөйләде, эченә кергәч, бары карап кына үттек, берни сөйләмәде. Нәкъ бер сәгать йөрдек. Шулай итеп, университет бүлекләрен карап йөрүемне тәмамладым.

«Хуш килдегез!» җәмгыяте

Шундый исем белән атала торган бу җәмгыять – Япониядәге җәмгыятьләрнең иң зурысы.

Әлеге оешманың максаты – Япониягә дөньяның төрле почмакларыннан агылган сәяхәтчеләрнең ялын оештыру.

Җәмгыять, нигездә, Япония баш вәкиллеге яклавы астында эшли икән, рәисе – маркиз Нашисоки җәнаплары, киңәшчесе – барон Шибусава, баш сәркатибе – адмирал Капураки җәнаплары.

Һәр сәяхәтче*, Япониягә килгәч, Токиода бу җәмгыятьнең идарә үзәгенә һәм башка шәһәрләрдә дә аның филиалларына мөрәҗәгать итеп, әгъза булып теркәлсә, җәмгыять идарәсе башта ул сәяхәтченең кулына, кырый-кырыйларына зур шәһәрләрнең планнары да сызылган, бик җентекле итеп төзелгән Япония картасын бирә. Моннан тыш, французча, инглизчә язылган ике китапчык та бүләк итә. Бу китапчыкларда бөтен Япониядә барып күрергә кирәк дип саналган мөһим урыннар турында мәгълүмат, аларның кайда урнашканлыклары, ул җиргә ничек барып җитәргә мөмкин икәнлеге, чыгымнарының күпме булачагы – һәммәсе турында да хәреф-иҗек тәртибе белән язылган. Әгәр кирәк дип табылса, җәмгыять

*Сәяхәтче сүзе кулланылса да, ул бүгенге көндә киң кулланыла торган *турист* сүзе мәгънәсендә (тәрҗ. иск.).

озатып йөрүче кеше дә бирә һәм бу кешеләр үз эшләрен бик яхшы башкаралар. Берничә тел беләләр. Күрешергә теләгән кешеләре булса, җәмгыять әлеге очракта да ярдәм итә. Болардан башка да, әгъза булып теркәлгән кешеләргә җәмгыять мөмкин булганча җиңеллекләр тудыра.

Җәмгыять инде 15 ел хезмәт күрсәтә икән. Әгәр Япониягә килгән сәяхәтче 3 йен биреп әгъза булып теркәлсә, шактый зур ярдәм күрә икән. Мин дә бу җәмгыятькә әгъза булып теркәлгән идем. Миңа бик ихтирам күрсәттеләр: бөтен Японияне гизә алыр өчен, бер рәсми кәгазь дә бирделәр, аңа үзенә күрә бер төр паспорт дип әйтеп булыр иде. Кайда гына булсам да, берәр шәһәргә, төбәк үзәгенә яки берәр авылга барсам, бу рәсми кәгазьне күрсәтәм: ни генә кирәк булса да, шунда ук ярдәм итәләр, бик ихтирам күрсәтәләр иде.

Бу кәгазьнең рәсемен биредә хөрмәтле укучыларымның игътибарына тәкъдим итәм.



Япониядә сәяхәт итү өчен Габдерәшит Ибраһимовка бирелгән рәсми рөхсәт язуы

Алда сүз алып барылган җәмгыять миңа моннан башка да аерым рәсми рөхсәтләр бирде. Шул рәвешле, мин япон милләтеннән бик зур ихтирам күрдем.

Бу җәмгыять кешеләренең кайберләре белән күрешкәндә, тупланган мәгълүматның әһәмиятле өлешен ара-тирә аларга күрсәтеп, берәр төрле өстәмә мәгълүмат алуны өмет итә идем. Мәсәлән, адмирал Капураки бер тапкыр, сөйләшеп утырганда, болай дигән иде: *«Соңгы елларда Япониягә елына ун меңнән артык сәяхәтче килә. Без җәмгыятебезне бөтен таләпләргә туры килерлек итеп юлга сала һәм сәяхәтчеләрнең ялын тиешенчә тәэмин итә алсак, ун елдан соң илле меңләп сәяхәтче киләчәгенә шигебез юк. Уртача хисап белән, һәр ел илебезгә юк кына җирдән 500000 лира тирәсе керем тәэмин иткән булып чыгачакбыз. Мин нык ышанам, җитәр бер көн: Япониягә елына илле мең түгел, биш йөз мең турист килеп китәчәк. Җәмгыятьнең төп максаты да шуны тәэмин итү»*.

Шул ук җәмгыятьнең әгъзасы булган Морита җәнаплары болай дип әйткән иде: *«Җәмгыятебез таләпләргә туры килерлек итеп тәртипкә салынса, без мәмләкәтебезгә күп санда турист җәлеп итә алачакбыз һәм мәмләкәтнең кереме бары тик туристлардан гына да тәэмин ителә алачак»*.

Сүз арасында

Минем уйлавымча, әгәр безнең Истанбулда да мондый җәмгыять төзелеп, Аурупадан агылган туристларны илчелек түрәләренең талауларыннан, комиссиончыларның алдауларыннан коткара алсак, начар булыр идеме?!

Моннан ун еллап элек Истанбулга Русиядән бер дустыбыз килгән иде, сарайларны һәм башка тарихи җирләрне карап йөрергә теләде. Илчелеккә мөрәҗәгать

иткәч, илчелектәге хезмәткәрләр: *«Бу шактый чыгымлы нәрсә, фәлән-төгән»*, – дигән булып, сигез-тугыз лира түләргә кирәк булачак, дип хәбәр бирделәр. Дустым, һичшиксез, барырга, күрергә тели иде, 10 лира булса да кабул итәсен әйтте. Моңа җавап итеп, илчелек хезмәткәре: *«Җомгага кадәр сабыр итегез, тагын киләсе туристлар бар. Чыгым, туристларның бөтенесенә бүленгәч, бер кешегә күпме төшәр, шул бәяне Сез дә бирерсез»*, – диде. Минем дус кеше җомга көнне башка туристлар белән бергә сарайларны карап йөргән, бер кешегә төшкән бәя госманлы акчасы белән сигез лира һәм берничә куруш (тиен) булып чыккан. Шунда ук гаепне тагын да шул ук безнең госманлылар өстенә ташлаганнар. Имеш, госманлыларның барысы да ришвәтче, туристларны озатып йөрүче хезмәткәр акчаны туристлардан ала, бөтен җирдә берничә лира ришвәт бирә, моңа әле тагын машина-фәлән акчаларын да кушканнан соң, бәя сигез лира була да куя, имеш.

Мондый бәя дә булырга мөмкин анысы. Шул ук вакытта инсаф дигән нәрсә дә булырга тиеш ләбаса, туристларга азрак бәягә күбрәк җир күрсәтергә дә мөмкин булыр иде.

Моннан тыш, әле тагын бичара хаҗ сәфәре кылучыларның ялын оештыручы берәр җәмгыять тә төзелсә, бик күп матди һәм рухи мәнфәгатьләрне кайгырту юлга салыныр иде. Ах, ул көннәрне күрү насыйп булырмы икән?!.

Милләт вәкилләре мәҗлесенең баш сәркатибе Хиашита

Әлеге мөхтәрәм шәхес – япон яшьләре арасында иң алдынгы кеше. Мин бу кеше белән берничә тапкыр күрештем, фикер алыштым.

Беркөнне мине дә кунакка чакырды. Шул көнне дус-ишләр белән Токио шәһәре читендәге җәйге бакчасы һәм шунда урнашкан вилласына кунакка барган идек. Хиашита җәнаплары безне олы хөрмәт белән трамвай тукталышына кадәр үк килеп каршы алды. Аннан, рикшага утырып, туры диңгез ярында урнашкан вилласына киттек. Биредә дә башка дус-иш көтеп тора икән.

Ишек төбенә килеп җиткәч, Хиашита җәнапларының ханымы, үз гадәтләре буенча, җиргә капланып, «хуш килдегез» сәҗдәсен кылып каршылады. Шуннан соң безнең белән андагы кунакларны, алар белән безне таныштырдылар. Шулай итеп, арабызда җылы мөнәсәбәт, якынлык урнашты. Минем исемемне японнар газеталардан һәркөн диярлек укып беләләр иде. Һәрвакыттагыча биредә дә татарлар һәм японнарның кардәшлеге турында сөйләштек.

Профессор Ошима ислам диненең киләчәге турында гаять файдалы чыгыш ясады. *«Исламият шундый югарылыкта торган дин: менә (мин фәкыйрегезгә ишарә итте), аның үрнәге булган тере кеше күз алдыбызда тора»*, – дигән сүзләр белән тәмамланган чыгышы алкышларга күмелде. Аннары болай дип тә өстәде: *«Япониядә Исламиятнең җәелүен чын йөрәктән өмет итәбез»*. Тагын алкышлар. Кунак мәҗлесе бик җылы, бик матур сөйләшүләр белән дәвам итте. Мин дә, ара-тирә сүзгә кушылып, татарларда японнарга карата аерым ярату һәм хөрмәт хисе барлыгын белдердем.

Бу мәҗлестә шактый кеше тарафыннан ясалган бөтен чыгышларның кыскача эчтәлеген теркәп барган идем, ләкин, ни кызганыч, кәгазьләрем арасында югалып киттеләр. Бигрәк тә Очита җәнаплары бик тирән эчтәлекле чыгыш ясаган иде.

Биредә бары тик өй хуҗасы Хиашита җәнапларының чыгышын кыскача гына китереп үтәм:

«Әфәнделәр! Безнең япон милләте, гомумән алганда, Шәрыкның үрнәге дип әйтерлек урын биләп тора. Япон халкына японнар үзләре генә түгел, киресенчә, бөтен Шәрык халыклары да аерым хөрмәт белән карыйлар һәм аның киләчәгенең якты һәм

бөек булачагын белдереп, чын күңелләреннән котлыйлар. Борынгыларыбызның бер сүзе бар: «Нигъмәт эчендә яшәгәндә, аның кыйммәте бик беленми», – диләр. Нәкъ менә шулай, бүген бездә дә шундый ук хәл. Без Шәрыктагы кардәшләребезнең безгә булган матур мөнәсәбәтенең кыйммәтен белеп бетерә алмыйбыз, Аурупаның ялтыравыклы мәдәниятенең җемелдәве күзләребезне камаштырды. Күршебездә яшәгән кардәшләребезне, Шәрык мәдәниятенә хезмәт итүче, Чыңгыз хан династиясеннән килгән татар кардәшләребезне оныттык. Менә безнең олы туганыбыз Габдерәшит Ибраһим бездән алгарак чыкты, Шәрык мәдәниятенә хезмәт итүчеләр безне тагын уздылар, безне эзләп килделәр, таптылар. Без, японнар, бертуктамый: «Аурупа, Аурупа!» – дип вөзгәләнгән булабыз, ә күршебездә гомер сөргән туганнарыбыз – татарлар турында бер хәбәребез дә юк. Аларны без эзләп табарга тиеш идек, булдыра алмадык. Бүген биредә Сезне олы туганым белән таныштыра алуыма бик горурланам, тыйнак йортыма килеп кунак булуы өчен аерым рәхмәтемне белдерәм.

Әфәнделәр! Мин Аурупаның бар җирен йөреп чыктым, күрдем, телләрен дә беләм: шунда укыдым. Гореф-гадәтләрен дә беләм. Хезмәт урыным белән бәйле рәвештә, бу соңгы сәяхәтем вакытында иң бөек кешеләре белән дә күрешеп сөйләштем. Безнең Шәрыкның яшәеше өчен Көнбатыштан берни өмет итә алмыйм. Без, Шәрык халыкларының, яшәве Шәрыкта һәм Шәрык белән бәйле. Безгә, Шәрык халыкларына, вакытны әрәм итмичә, үзебез кебекләрне күбрәк танып белергә кирәк.

Мин шуны өмет итәм: Габдерәшит Ибраһим әфәнденең мәмләкәтебезне килеп күрүе Шәрык яшәешенә аерым бер хезмәт күрсәтәчәк. Ибраһим әфәндене мондый уңышы белән тәбрик итәм. Яшәсен татар кардәшләребез!»

Мәҗлестәге барлык кешеләр дә: *«Яшәсен татарлар!»* – дип кычкырды.

Моннан соң мәҗлестә катнашучы тагын бер кеше – Ошита Сан да шундый ук чыгыш ясап, миңа карата бик җылы, бик нәзакәтле сүзләр әйтте. Мәҗлес сигез сәгатькә якын дәвам итте. Җавап сүзе белән чыгыш ясарга мине дә чакырдылар. Мин күпме генә үзем уйлап, үзем теләп кенә сәяхәткә чыккан кеше булсам да, японнар миңа шулкадәр зур илтифат күрсәттеләр ки, бу бары тик хөкүмәт тарафыннан җибәрелеп, рәсми күрешүгә килгән кешеләргә генә насыйп буладыр. Ул кичне Хиашита Санның өендә кунак булып калдым. Үзебез генә калгач, аннан Аурупага сәяхәтенең сәбәпләре турында сорадым.

«

Мин күпме генә үзем уйлап, үзем теләп кенә сәяхәткә чыккан кеше булсам да, японнар миңа шулкадәр зур илтифат күрсәттеләр ки, бу бары тик хөкүмәт тарафыннан җибәрелеп, рәсми күрешүгә килгән кешеләргә генә насыйп буладыр.

– Безнең Милләт вәкилләре мәҗлесе һәм Сенат урнашкан биналарыбыз вакытлыча дип агачтан салынган иде, әлеге көнгә кадәр, инде егерме ел бюджет та мөмкинлек бирмәде, арага сугышлар да килеп керде – һаман да шул хәлдә кала бирде. Ниһаять, быел бюджетта бераз мөмкинлек күренде, Милләт вәкилләре мәҗлесе бинасы өчен 5 миллион йен бүлеп бирелде һәм төзергә дигән карар да кабул ителде. Бу яңа төрдәге бина булачак һәм эшне оештыруны Мәҗлес миңа тапшырды. Мин исә: *«Булгач-булгач, мөкәммәл бер бина булсын!»* – дидем, үзем белән бер архитектор алып, Аурупа һәм Америка сәяхәтенә чыктык. Парламент биналарын бик җентекләп күздән кичереп, шулар нигезендә яңа бер бина барлыкка китерү



Токио. XX гасыр башы

фикере белән карап, өйрәнеп йөрдек. Сәяхәтебез өч айга сузылды. Насыйп булса, быел бина төзелешен башлыйбыз.

– Үзегезнең инженерларыгыз башкарып чыга алачакларммы, әллә Аурупа инженерларына да ихтыяҗ булачакмы?

– Юк, барысы да үзебезнекеләр. Чит илнеке булган беркемгә дә, бернәрсәгә дә ихтыяҗыбыз юк. Безнекеләр бик кыю, үзләре башкарып чыгарга ятаталар. Җитештерү өлкәсендә безнең бер генә җәһәттән дә Аурупага ихтыяҗыбыз юк, акча җәһәтеннән генә Аурупага ихтыяҗыбыз булуы мөмкин. Керемнәребезне яхшылап тәэмин итә алсак, калганы җиңел булачак. Бездә хәзер иң авыр мәсьәлә – финанс мәсьәләсе.

– Аурупада нинди кием киеп йөрдегез?

– Элегрәк, югары уку йортында укыган елларда, Аурупада үзебезнең милли киемнәребезне кими идек. Көләләр, артыбыздан көтү-көтү ияреп йөриләр иде. Без ояла идек, милли киемнәребезне бары тик кеше күрмәгәндә генә, өйдә, ике-өч якташ бергә җыелганда гына кия, идәнгә утырып чәй эчә торган идек. Шул рәвешле рәхәтлек тоя, үз милләтебезне сагынып искә төшерә идек. Ә бу юлы һич исем китмәде, гел милли киемнәремне киеп йөрдем, хәтта рәсми чакырылган җирләргә дә милли киемемне киеп бардым. Аурупа киемем дә бар иде, ләкин кимәдем, нигә әле милләтемнең данын, шәрәфен яшерим, дидем.

– Милли кием киеп йөргәндә, агрессивлык күрсәтүчеләр очрамадымы?

– Юк, бер дә андый нәрсәләр күрмәдем. Әлбәттә, бик игътибар белән карыйлар иде, ләкин мин күрмәмешкә салыштым, алар дип, милләтемнән йөз чөеримме?! Мин нык ышанам: Аурупа кешеләре безне һич яратмый, хәтта Аурупа киеме кисәм дә, япон икәнемне белгәч үк түбәнсетеп караячаклар. Дөресе генә, минем ниемә кирәк булсын, табигый дошманлыкларын билгеле итеп торсыннар. Милләтемне моннан ары яшерергә кирәк күрмим.

Икенче көнне мин Токиода идем инде. Кичкә таба почта китерделәр, бер хат бар иде. Бер дустым язган, болай дигән: *«Иртәгә фәлән җирдә, фәлән гыйбадәтханәдә конференция була. Килә алсагыз, бик сөенербез. Танылган профессор Таката чыгыш ясаячак. Япон хәрефләре турында».*

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Мөһаҗирлектәге татар китабы

«Татар моңнары һаваларга таралсын!»

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы



Әхмәд Гәрәй. «Ниләр, ниләр... тагы да ниләр». Нью-Йорк, 1963 ел



S O M E P O E M S
O f
E M I L Y D I C K I N S O N

Translated Into The Tatar Language
By
Ahmed Gerey
June,1963.

"My Faith is Larger than the Hills -
So when the Hills decay ...."

ЛИЧНАЯ БИБЛИОТЕКА ПРОФЕССОРА Х.МИННЕГУЛОВА

Sone poems of Emily Dickinson Translated Into The Tatar Languge By Ahmeb Gerey, June, 1963

Ата, дидем, ана, дидем дә, ни хөрмәт итә белдем?
Ватаным, милләтем, дидем дә, ни эш күрсәтә белдем?

* * *

...Тип, йөрәгем, әрнемә, сыгылма, талма,
Яшим, дип, тип йөрәгем, һич туктама.
Һәрбер татарның йөрәге әрни, сызыла,
Сызласа да, типсен мәңге туктамыйча...

Бу юлларның авторы 20 нче йөздәге татар мөһаҗирлек сүз сәнгатенең бер вәкиле Әхмәд Гәрәй (?—?). Аның исеме дә, әсәрләре дә хәзерге укучыларга гына түгел, әдәбият галимнәренә дә бөтенләй диярлек билгесез.

Бервакыт бер әдиптән (А.Блок булса кирәк) очрашу вакытында үзе турында сөйләвен үтенәләр. Мәшһүр шагыйрь: «Минем барысы да шигырьләремдә», – дип җавап бирә. Авторның тормыш юлын, шәхесен әсәрләре аркылы ачыклау аеруча элеккеге дәвер (бигрәк тә Борынгы һәм Урта гасыр) әдипләрен өйрәнгәндә киң таралган. Чөнки аларның, хәзерге кебек, анкета-автобиографияләре, «характеристика»лары да юк, булса да — сакланмаган. Әмма хәзер дә кадим заманнардагы кебек хәлләр очрап куя. Әхмәд Гәрәй дә — әнә шундый язмышка

тарыган зат. Кызганыч ки, аның шәхесе хакында без фәкыйрегезгә мәгълүматлар билгеле түгел диярлек. Интернет та, ничектер, бу затны читтәрәк калдырган бугай. (Бәлки, мин эзли белмәгәнмендер?) Инде хәзер бердәнбер чыганак булып авторның үз әсәрләре кала. Аларны тикшерү барышында без игътибарыбызны, әдәби-эстетик мәсьәләләр белән беррәттән, әдипнең тәрҗемәи хәлен, шәхесен ачыклауга да юнәлтербез.

1990 елда Финляндиягә өч айлык сәфәр вакытында андагы милләттәшләребез миңа, башка күп кенә язма истәлекләр белән бергә, Әхмәд Гәрәйнең дә 1963 елда Нью-Йоркта төзелгән ике китабын бүләк иткәннәр иде. Аларның берсе «Ниләр, ниләр... тагы да ниләр» дип атала. Икенчесе – Американың мәшһүр шагыйрәсе Эмилия Дикинсонның (1830-1886) татарчага тәрҗемә ителгән шигыре (янәшәдә текстлар инглизчә дә бирелә). [Sone poems of Emily Dickinson Translated Into The Tatar Languge By Ahmeb Gerey, June, 1963]. Мөһаҗирлек әдәбиятына багышланган кайбер язмаларыбызда инде без болар хакында аерым белешмә-мәгълүматлар биргән идек. 2019 елның ахырларында мин бу ике китапчыкны, чит илләрдә язылган, басылган башка бик күп (йөзгә якын) ядкярләр белән бергә, Татарстан Милли китапханәсенә бүләк иттем. Шуңа җавап йөзеннән булса кирәк, бу «Белем йорты» хезмәткәрләре (Ирек Һадиев, Айрат Заһидуллин) миңа Әхмәд Гәрәйнең Милли китапханәдә (Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә) сакланучы дүрт китапчыгын (копия-күчермәләрен) бүләк иттеләр. (Мең рәхмәт үзләренә!) Алар барысы да Нью-Йоркта төзелгән: «Чит илләрдә җырлаганым» (1964), «Юлым аерылды икегә» (1965), «Корбан бәйрәмегез котлы булсын» (1966), «Югалган яшьлегем» (1967). Китапчыкларның бөтенесе дә гарәп язуында. Арада инглизчә текстлар да бар.

Басма китапларга кадәр бездә язма истәлекләр кулъязма рәвешендә тарала. Аларны автор үзе дә, махсус хаттатлар да күчереп тарата. Әхмәд Гәрәй дә шул борынгы традициягә (бәлкем, махсус рәвештәдер?) тугры кала. Китаплардагы текстлар авторның үз кулы белән язылган, җыентыклар да аның үзе тарафыннан төзелгән. Алга таба бу тупланмалар махсус аппарат ярдәмендә күбәйтелеп таратылган булса кирәк.

Әхмәд Гәрәйнең җыентыклары зур форматлы, әмма бик юка. Бездә андыйларны дәфтәр калынлыгында дип йөртү бар. Мөһаҗир шагыйрьнең җыентыклары бу чагыштыруга тулысы белән туры килә диярлек. Аларның күләме уртача 5-10 биттән гыйбарәт. Барысын бергә тупласаң, мөгаен, 50 бит тирәсе булыр. Шуңа күрә әлеге җыентыкларны «китап» дип атау шактый шартлы. Чынлыкта алар «китапчык», «дәфтәр» исемнәренә күбрәк лаек.

Җыентыклар, нигездә, аларда урнаштырылган мөһимрәк аерым язмаларның исемнәре белән аталган. Күпчелеге – 50гә якыны – Әхмәд Гәрәйнең оригинал шигъри әсәрләре. Бер дистә тирәсе аерым чәчмә текстлар (нигездә, өзекләр) да күзгә ташлана. Оригинал язмалар белән бергә, тәрҗемәләр дә бар. Татар авторының берничә шигыре инглизчә дә бирелгән. Күпчелек әсәрләрнең язылу вакыты һәм иҗат ителү урыны да күрсәтелгән.

* * *

Әхмәд Гәрәй кайчан, кайда туган, вафат булган, кайларда укыган, эшләгән, төп шөгыле, туган-тумачалары, гаиләви ягы ничек?.. – бу төр сорауларны киләчәк тикшерүчеләр өчен ачык калдырабыз. Инде әсәрләре аркылы шагыйрьнең тормыш юлын бераз гына булса да күзалларга тырышыйк. (Ул фикер-фаразлар чынбарлыкка ни дәрәҗәдә туры килә – анысы икенче мәсьәлә.)

Әхмәд Гәрәй милләтенең татар булуына, Урал төбәгендә туып-үсүенә кат-кат басым ясый. Чит-ят кыйтгаларда каңгырып йөргән лирик герой үзенең «Югалган яшьлегем» шигырендә болай яза:

...Аһ, Африка, бигрәк эссе,
Янган йөрәгемне яндыра.
*Шул минутлар үлсәм (улсам? – **Х.М.**) иде*
Сакмар буенда, Урал тавында.

Бу һәм кайбер башка фактлар шагыйрьнең Көньяк Уралдан (хәзерге Оренбург яисә Көньяк Башкортстан) чыгуына ишарә ясый. Ул чын милли мохиттә, матур табигать кочагында, авылда туып үсә. Әсәрләрендә аның татар телен, җыр-моңнарын, гореф-гадәтләрен бөтен нечкәлекләре белән белүе, белүе генә түгел, аларны бөтен кан һәм җанына, күзәнәкләренә сеңдерүе ачык сизелә. Шагыйрьнең аерым парчалары халык җырларына ияреп, алардан файдаланып иҗат ителгән. «Кәккүк көе» (Каһирә, 1953), «Зәңгәр шәл», «Югалган яшьлегем» (II) – шуларның ачык мисалы. Икесенең соңгы строфасы болай яңгырый:

...Син кайда, былбылым, син кайда ялгызың?
Мин синнән озакта уйланам берүзем.
Кәккүк! Кәккүк!
Оч Уралга, чакыр анда – мин йөргән урманнарга,
Минем балалыгым үтте әнә шул урманнарда.

* * *

...Яшьлегем – яшен чакларым – калды сагынып сөйләргә,
Сак белән Соктай айрылдык, хуш, бәхил бул мәңгегә.

Әхмәд Гәрәйнең 1955 елда «Африкада» иҗат ителгән «Чүлдә төшемдә» дигән шигъри парчасы бар. Бу шигырь берничә яктан игътибарга лаек. Беренчедән, ул автор үз иткән, яратып кулланган төш алымына корылган. Икенчедән, анда шагыйрь «Рәбига» исемле яшьлек мәхәббәтен, аны өзелеп сагыну, юксыну хисләрен бәян итә. Өченчедән, бу әсәр корылышы ягыннан да үзгәрәк. Әүвәл – 11(12)–14 иҗекле ике юл. Алга таба аларга ялганып, нигездә, 6–6–5 иҗекле, үзара рифмаланучы өч юл килә.

Бер кичә сахраларда ялгыз берүзем,
Адашып юлдан, арып, төндә чүлдә утырдым.
Утырсам – уйландым,
Уйласам – җырладым,
Җырласам – җыладым.

Шушындый үзенчәлекле төзелеш шигырьнең биш строфасында да саклана.

«Әхмәд Гәрәйнең 1946 елда Италиянең Сицилия утравындагы Сиракуза шәһәрендә иҗат ителгән бик тә мәгънәле «Хәятем» шигыре бар. Җиде дүртьюллык строфадан торган бу әсәрне авторның шигъри-лирик автобиографиясе дип тә атарга мөмкин.

Әхмәд Гәрәйнең узган гасыр яшьтәше яисә 20 нче йөзнең башларында тууы, татар мәктәп-мәдрәсәсендә укуы, тәрбия алуы хак. Аның татар телен, сүз сәнгатен камил белүе, гарәп язуын куллануы да шуннан килә. Автор үз җыентыкларында яңалиф, урыс (кирилл) графикаларын бөтенләй кулланмый. Димәк, гарәп хәрефләре белән татарча язу аның

канына сеңгән, гадәтенә әйләнгән. Шагыйрьнең Сөембикә, Тукай исемнәрен еш искә алуы да Әхмәд Гәрәйнең милли мәгариф кысаларында белем-тәрбия алуына ишарә ясый. [Автор хәтта үзенең сөйгәнен дә Сөембикәгә охшата: «Сине күрсәм, Казан кызы, дип, син бер көлсәң – Сөембикәм, дип, Бер генә сүз әйтер идем, килче миңа җан күбәләгем, дип»].

Әхмәд Гәрәйнең 1946 елда Италиянең Сицилия утравындагы Сиракуза шәһәрендә иҗат ителгән бик тә мәгънәле «Хәятем» шигыре бар. Җиде дүртьюллык строфадан торган бу әсәрне авторның шигъри-лирик автобиографиясе дип тә атарга мөмкин. Анда ул «балачак»ларын, мәктәптә укып йөргәннәрен, «сабан сөрү»ләрен, «ат көтү»ләрен, урман кисүләрен, Сабан туйларын, «Карурман» дип җырлаган Урал көйләрен – күңелле, истәлекле чорларын искә ала да, аннан гомеренең ачы язмышлы өлешенә күчә:

...Ничә тапкыр, ничә җирдә төрмәләрдә,
Ничә еллар сөргеннәрдә изелгәнем.
Ничә тапкыр ачлыктан шешенгәннәрем,
Йә, бу көн, дип, йә, үләм, дип, качканнарым.
Бәхетсез икәнлегемне соңрак сиздем,
Милләтемнең изелгәнлеген аңладым.
Ләкин киләчәктән өметемне өзмичә,
Беркөн безгә дә азатлык булыр, димен.
Тормыш миңа никадәр авыр булса да,
Ватанымнан аерылсам, озаклашсам да,
Билем бөкрәп, күзем күрмәс картайсам да,
Мин җырлармын Урал көйләрен һаман да.

Күрәсез: тәүге строфадагы «ничә» сүзенең кабатланып килүе лирик каһарманның фаҗигаи гомер юлы сикәлтәләренең ниндилеген тагын да ныграк тоярга ярдәм итә. Андагы юлларда кулланылган антитеза, контраст алымнары да бу аянычлы язмыш хисен көчәйтүгә булыша. Әмма нинди генә киртәләр, кыенлыклар булмасын, шагыйрь киләчәккә өмет белән карарга, халкы өчен эш-гамәл кылырга чакыра. Бу мотив аның байтак кына башка шигырьләрендә дә күзәтелә.

«Хәятем» шигырендәге юллар авторның берничә мәртәбә төрмә-сөргеннәрдә булуы, ачлыктан интегүе, ватаныннан аерылуы хакында сөйли. Мәгълүм ки, 20-30 нчы елларда СССРның миллионлаган кешеләре зиндан-сөргеннәрнең газабын татый, шактые шуларда юкка да чыгарыла. «Ватаным Татарстан» гәҗите (10.05.2020) язуынча, 1941-1945 елларда илебезнең 26 млн кешесе һәлак була. Әсирлеккә эләгүчеләрнең 2 миллионы шунда үлә дә, 1 млн 836 меңе илгә кайта (шуларның 339 меңе Сталин лагерь-төрмәләренә озатыла). 160 мең әсир чит илләрдә торып кала. Әхмәд Гәрәй бу зиндан-сөргеннәрнең кайсыларында, кайчан булгандыр — хәзергә кистереп әйтә алмыйм. Авторның «ничә еллар...» дигәне тоткынлыкның озак вакытлы булуына да ишарә ясый. Мөгаен, ул Сталин төрмәләрендә дә газап чиккәндер. Әсирлеккә эләгеп, сугыш беткәч, чит илләрдә калуы да бик ихтимал. Ә инде шагыйрьнең 1946 елның май башларында Көньяк Италиядәге утрауда, атаклы Этна тирәләрендә яшәве хак. Алдарак әйтелгәнчә, Әхмәд Гәрәй күп кенә шигырьләренең ахырында язылу вакытын һәм урынын күрсәтеп бара. Италиядә күпме яшәгәндер — анысы төгәл билгеле түгел. 50 нче елларда ул «Африка» кыйтгасында гомер кичерә. Аның берничә шигыренең ахырында Каһирә, Искәндәрия (1951, 1955), Урта Африка (Хартум, 1953-1954) атамалары, еллар күрсәтелә. Бу Көньяк кыйтгада

шагыйрь шактый гына яшәгән булса кирәк. Африка, аның табигате Урал татарының берничә шигырендә телгә алына, ул бу кыйтга, андагы «Нил сулары», «пирамидалар» хакында махсус парчалар да иҗат итә. Шунысы мөһим: автор үзе булган, үзе яшәгән җирләрне, алардагы үзенчәлекләрне еш кына туган иле белән чагыштырма планда бирә. «Африка» шигыре дә моннан чыгарма түгел:

...Кай тарафын карасаң да, безнең илгә охшамый,–
Үзенә башка бөтенләй бер планетамы?

Әхмәд Гәрәй хәтта бу кыйтгага нисбәтле «Сагыну» шигырен дә яза:

Күрсәм иде янә Африканы, –
Кайда үтте яшьлек елларым.
Анда үткән күп авыр елларны
Хәзер янә сагына башладым.

Җыентыклардагы күпчелек әсәрләр 1963-1967 елларга, Нью-Йорк шәһәренә мөнәсәбәттә бирелә. Без Әхмәд Гәрәйнең алдарак телгә алынган илләрдә һәм калаларда гына түгел, кайбер башка илләрдә һәм шәһәрләрдә дә булуын, яшәп алу ихтималлыгын да кире какмыйбыз.

Авторның безгә билгеле китапларында аның мөһаҗирлектә, әдәби иҗаттан башка, нинди эшләр башкаруы хакында факт-мәгълүматлар күзгә ташланмый. Сугыштан соң чит мәмләкәтләрдә торып калган Шиһаб Нигъмәти, Исфәндияр Ишгай, Минһаҗ Исмәгыйлиләрнең җыентыкларында аларның алман лагерь-зинданнарында язылган шигырьләре дә теркәлгән. Әхмәд Гәрәйнең андый әсәрләре очрамады. [Әгәр дә андыйлар булса, бәлкем, алар авторның безгә билгесез җыентыгында теркәлгәндер?]

Төрле илләрдә, төбәкләрдә яшәү дәвамында Әхмәд Гәрәй шул мәмләкәтләрдә гомер итүче халыкларның да телләрен теге яки бу дәрәҗәдә үзләштергәндер. Ә инде инглиз телен камил белүе бәхәссез. Әйткәнебезчә, ул күренекле шагыйрә Эмилия Дикинсонның 10 шигырен оригиналдан татарчага тәрҗемә итә. Инглизчәдән күчерелгән парчалар [алар, нигездә, 3-4 (дүртьюллык) строфадан гыйбарәт] татарча болай исемләнгән: «Шәкел», «Мин һичвакыт баткаклыкны күл күрмәдем», «Үлемсезлек», «Мин үлдем матурлык өчен» һ.б. Бу тәрҗемә текстлардан бер-ике өзек китерәм: «Минем иманым таулардан да зуррак, Шулай кайчан таулар-таулар череп китәрләр»; «Рәхмәтем өметдән айрылды, Билгеле юлның аръягында. Мәңгелекнең ак байрагы алда һәм һәр капкада әллә?» Татар телендә язылган кереш сүздә инглиз шагыйре хакында белешмә дә бар.

Шунысы кызыклы: Әхмәд Гәрәйнең җыентыкларында аның аерым үз әсәрләре (нигездә, шигырьләре) инглизчә бирелә. Заманында мин шагыйрьнең тәрҗемә әсәрләрен инглиз һәм татар телләрен камил белүчеләргә күрсәтеп караган идем. Алар, текстларны үзара чагыштырып, татар әдибенең тәрҗемә өлкәсендәге эшчәнлегенә уңай бәя биргәннәр иде. Киләчәктә, инглиз һәм татар әдәби бәйләнешләре яссылыгында, Әхмәд Гәрәй иҗатын махсус өйрәнү дә зыян итмәс иде. (Хәзергә без шагыйрьнең инглизчә язмаларына тукталмыйбыз.)

Милләттәшебез язган әсәрләрнең безгә билгеле кадәресе дә аның эрудицияле, гыйлемле, дөнья һәм милли әдәбияттан шактый хәбәрдар икәнлеген күрсәтеп тора. Ул, нинди кыенлыклар булса да, үзеңне «һәр җирдә, һәр заманда» «мәгърур» тотарга чакыра.

Гаяз Исхакый, Сания Гыйффәт, Ләбиб Каран, Шиһаб Нигъмәти, Исфәндияр Ишгай һәм мөһаҗирлектәге кайбер бүтән каләм әһелләре кебек, Урал татары

да үзара берлек-бердәмлеккә өнди, үткәннәрдән гыйбрәт алырга куша. Әхмәд Гәрәй дә төп игътибарын татар тематикасына, аның тарихи язмышына, бүгенге хәленә юнәлтә. Еш кына Сөембикә образын, аның фаҗигале язмышын халкыбызның бер символы рәвешендә бирә. Бер шигырендә башкорт кавеменең легендар улы Салават Юлайның да батырлыгына соклануын белдерә. Аерым истәлек-хатирәдә бөек Тукайның инсаннарга көчле тәэсире сурәтләнә. Әхмәд Гәрәй әсәрләрендә Муса Ярулла Биги, Кәрим Тинчурин кебек халкыбызның билгеле шәхесләре хөрмәт-ихтирам белән телгә алына. Мәсәлән:

> «Хөрлек-азатлыкка, бәхет-сәгадәткә ирешүдә төп шарт – милли берлек, милли бердәмлек. Бу мотив Әхмәд Гәрәй шигырьләрендә еш очрый. Ул аеруча авторның Нил елгасы буенда узган гасыр урталарында язылган «Үрнәк» шигырендә калку гәүдәләнә.

...Фәкать һич гөнаһсыз Муса Ярулла
Җиде ел калды Һиндстанда зинданда.

Шагыйрь фикеренчә, татарлык, татар язмышы, татар тарихы «Ак Идел» кебек [Шунысы мөһим: ул бу төшенчәгә Агыйдел, Кама, Идел (Волга) елгаларын кертеп, аларны бер бөтен итеп карый]:

...Ак тасмадай сузылып аккан Иделкәй,
«Син» дип корбан булды Сөембикә нугай.
«Син» дип кан түкте, җан бирде Салават Юлай,
«Сиңа» багышлады рухын моңлы Тукай.

Син агасың, агасың мең-мең еллар,
Сөйләми тарихынданиләр булганын,
Сөембикәнең сиңа тамган яшьләрен,
*Агызып, илтеп Хазар (Каспий. – **Х.М.**) диңгезенә кушканын.*

Татар каны – димәк, Ак Иделнең суы,
Ак Иделнең суы, дисәң – татар каны...

Хөрлек-азатлыкка, бәхет-сәгадәткә ирешүдә төп шарт – милли берлек, милли бердәмлек. Бу мотив Әхмәд Гәрәй шигырьләрендә еш очрый. Ул аеруча авторның Нил елгасы буенда узган гасыр урталарында язылган «Үрнәк» шигырендә калку гәүдәләнә. Анда әүвәл Урал тарафларыннан җылы якларга очып килүче (һәм китүче) кыр казлары язмышы гәүдәләнә. Алар бергә, бердәм [Автор хәтта һавада очып баручы кошларның рәсем-схемаларын да ясап куйган.]. Шагыйрь милләттәшләрен дә шулардан үрнәк алырга чакыра.

Әдип татар дөньясы белән генә чикләнми, әсәрләрендә җиһанның Гомер, Данте, Гомәр Хәйям, Фирдәүси, Нәваи, Рабиндранат Тагор кебек мәшһүр затлары да гәүдәләнеш таба. Ләйлә-Мәҗнүн, Фәрһад-Шириннәре дә искә төшерелә. Антик дөньяның даһианә заты Гомерны ул: «Һәммәгә юл башлаган сукыр шагыйрь», – дип атый. Урал татарының кайбер башка шигырьләрендә дә борынгы дәвер, мифологик образлар, тарихи тематика эшкәртелә. Бу яктан аның «Фиргавеннәрнең

пирамидалары» парчасы кызыклы гына. Адәм балаларының кодрәти көче һәм тырышлыгы белән тудырылган бу гаҗәеп корылмаларга сокланып, автор үз шигырен мондый юллар белән төгәлли:

...Инде биш мең ел була – бу пирамидалар тора,
Янә ун мең ел үтәр – үзгәрмәс алар шунда да.

Мөһаҗирлектәге үзенә язмышташ шагыйрьләр кебек, Әхмәд Гәрәй әсәрләре дә туган җир, туган табигать, яшьлек, ата-ана, мәхәббәт кебек газиз уй-хисләр белән сугарылган. Урал шагыйре өчен дә җирсү, сызлау, сагыш кичерешләре хас. Ш.Нигъмәти, И.Ишгай әсәрләрендә СССРдагы сәясәтне, партия хакимиятен тәнкыйтьләү сизелерлек урын алып тора. Ә инде Әхмәд Гәрәйнең безгә билгеле җыентыкларында антисоветизм, антикоммунизм идеяләре күзгә ташланмады. Аның иҗатында урыс халкына тел-теш тидерү дә күренми.

Әдәби иҗатны, шигъри сүзне, «җыр»ны зурлау мотивы шәрык-татар сүз сәнгатендә күптәннән килә. Әхмәд Гәрәй дә бу традицияне уңышлы дәвам итте. Аның Котб, Дәрдемәнд парчаларын хәтерләткән, «каләмгә хитаб» рәвешендә язылган «Каләмем» дигән махсус робагые да бар:

Яз, каләмем, уңдан — сулга, сулдан — уңга,
Яз, каләмем, һәр тарафтан — һәр тарафка.
Яз, каләмем, акыл кайсы дөньяларда.
Яз, каләмем, бер көн-сәгать туктамыйча.
(1965)

Игътибар итегез: бу дүртьюллык фикъри яктан гына түгел, әдәби ноктадан да дикъкатькә лаек. Һәр юл башында бер үк сүзнең эндәш рәвешендә кабатланып килүе парчаның шигъри яңгырашын да тәэсирлерәк итә. Гомумән, автор бу төр кабатлау, эндәш, мөрәҗәгать кебек ысулларны яратып куллана. Аның халык авыз иҗатыннан файдаланып язылган «Тамчы-тамчы» робагые — сурәтләү ысулларын һәм чараларын куллануның матур бер үрнәге:

Тамчы-тамчы тамган тамчы сулар
Тамып, тамып, тамып тордылар.
Гасырларча тамган бу тамчылар
*Кая (кыя? — **Х.М.**) ташны җимереп аттылар.*

«Югалган яшьлегем» җыентыгында бу исемдәге ике шигырь бирелгән. Шуларның «авыл көйләре»нә ияреп язылган икенче парчасында кабатлау, тәҗнис (омонимия) күренешләре еш очрый. («...миңа, язмыш, язмыш, бер генә яз җырларга»; «Килер язлар, китәр язлар, килер, китәр янә дә, Миңа язылмыш яз үтте, килмәс инде янә дә...»).

Кыскасы, Әхмәд Гәрәй (гәрчә вәзен-кафиядә кайчак аерым төгәлсезлекләр җибәрсә дә) төрле поэтик ысуллар, детальләр, чаралар, формалар куллана. Аның иҗатында мәдхия, мәрсия, җыр, фәрд-икеюллык һәм кайбер башка жанрларның матур үрнәкләре бар. Лирик шигырьләр белән бергә, лиро-эпик әсәрләр дә очрый. Урал шагыйре аеруча робагый жанрына өстенлек бирә. Инде алдарак әйтелгәнчә, Әхмәд Гәрәй – гомумән, фәлсәфи рухлы шагыйрь. Кеше, милләт, ил, гавам, тарих, бүгенге заман, киләчәк турында уйлану аның бөтен иҗатын сугарып бара. Ул эзләнә, сораулар куя, аларга җаваплар эзли, борчыла, куана, сызлана. Бу төр сыйфатлар аеруча шагыйрь яратып кулланган робагый жанрындагы парчаларында ачык гәүдәләнә.


قوربان بەیرەمگز
قوتلی بولسن
1966
New York


-4-

A BROADWAY STAR

A girl of beauty and glee
In Broadway, like a queen in a honey-bee,
Passed by me talking "ye" and "ye",
Arousing my wishes to picture her and see.

She represented the nature's power,
In cosmetics, glorifying color and powder,
Like a bright star in the Milky Way
Shined along the Broadway.

A. Gerey.

On the eve of Christmas,

1965-66.

Әхмәд Гәрәй. «Корбан бәйрәмегез котлы булсын». Нью-Йорк, 1966 ел

Әхмәд Гәрәй чордашы һәм язмышташы И.Ишгай кебек өчьюллык строфалар белән дә яза («Иран шагыйрьләренә»). Аның җыентыкларында иҗтимагый, фәлсәфи, мәхәббәт, пейзаж лирикасы үрнәкләре, хәтта юмористик парчалар да бар. Авторның образлы фикерләве өчен, гомумән, урын-вакыт (ягъни хронотоп) киңлеге, масштаблылык хас. Ул милли һәм җиһани сүз сәнгатендәге хәзинәләр белән шактый иркен эш итә. Әсәрләренең үзәгендәге лирик герой һәм автор образы – тынгысыз, бай рухлы зат. Барыннан да элек ул – милләт улы, татар шәхесе. Шунысы гаҗәпләндерә: шагыйрь, туган җиреннән, милли мохиттән аерылып, читят тарафларда ярты гомерен уздыра. Әмма ул үзенең туган теленә, газиз халкына тугры кала. Урал татарлары телендә «ерак» урынына «озак» сүзен куллану киң таралган. Ә.Гәрәй дә бу кәлимәне бик еш һәм яратып куллана. Иленнән җисмани яктан ераклашса да, күңеле, рухы белән аннан «озаклашмый»:

...Никадәр илеңнән озаклашсаң да һаман –
Җырла Урал көйләрен, – дөнья ишетсен.

Автор, оригинал әсәрләрендә генә түгел, үзенең тәрҗемәләрендә дә татар укучыларының күңелен кузгатырлык гыйбрәтле әсәрләр сайлый. Мәсәлән, атаклы Робинзон Крузо (1632-1705) турындагы кыска гына өзек тә сине бик тиз тәэсирләндерә. Мәгълүм ки, чукракланган бөек композитор Бетховенны (1770-1827) үлемсез әсәрләр тудыруга хатын-кыз илһамландыра. Бу хакта татар әдибе үзенең «Югалган яшьлек» җыентыгында күңелләрне кузгатырлык махсус өзек тә урнаштырган.

Әхмәд Гәрәйнең мөһаҗәрәттә гомер кичерергә дучар ителгән чордашлары, каләмдәшләре, нигездә, үзара аралашып, хәбәрләшеп яшәгәннәр. Әмма Урал шагыйре кемнәр белән бәйләнештә торган – аларны шәхсән мин бик белеп бетермим. Бу зат хакында Минһаҗ ага Исмәгыйлинең дә сүз кузгатканы хәтердә калмаган. Эмилия Дикинсонның шигырьләрен тәрҗемә иткән китапта Әхмәд Гәрәй Төркиядә, өлешчә Финляндиядә гомер кичергән Сания Гыйффәтнең (1899-1957) дә өч шигырен («Тормыш көзгесе» драмасыннан, «Егерме ел элек», «Актык теләк»)

урнаштыра. Инглиз һәм татар шагыйрьләре арасында аерым охшашлыклар да күрә. Димәк, Әхмәд Гәрәй С.Гыйффәтнең шәхесе һәм иҗатыннан хәбәрдар була. Шагыйрь җыентыкларының берсендә Сөембикә хакында төрек илендә «тарихи роман» булуын да искәртә. Бу – Төркиядә яшәгән милләттәшебез Илгаз Ваһаб Нәүрузханның әсәре булса кирәк. [«Сөембикә» исемле бу тарихи роман 2018 елда Казанда татар телендә дә дөнья күрде].

Әхмәд Гәрәй Америкадагы милләттәшләребез белән аралашып торган. Җыентыкларын да, иң беренче чиратта, алар өчен төзегән. «Юлым аерылды икегә» китабында Америкага килгән Хәмид Рәшид исемле кеше белән танышуы хакында яза. «Бу зат, – ди ул, – Икенче дөнья сугышының беренче көненнән ахырына кадәр сугыша». Алга таба аңа читтә, чит илләрдә яшәргә туры килә. Ватанында ике баласы кала. Биредә дә янә ике баласы бар. Автор милләттәшенең, борчылып: «Илдәге балаларымны да үстерә алмадым, ичмасам, мондагыларын үстерергә язсын иде», – дип еш кына әйтүен искәртә. Әмма, ни үкенеч, әлеге зат 1964 елның 29 августында Вашингтон янындагы «автоказа»да һәлак була. Әхмәд Гәрәй бу уңай белән «Хәмид Рәшид мәрхүмгә» дигән мәрсиясен яза:

И газиз бәндә,ниләр күрмәдең бу дөньяда?
Зур теләкләр, зур өметләр калды инде аркада.
Без килмәгәнбез шул мәңгелеккә, хәят баглы билгесезлеккә,
Билгесезлекнең бер читендә яшеренгән үлем безне көтә.

Бу кара көндә дустларың-танышларың синә
Соңгы сәламнәрне биреп, тапшырабыз сине Аллага.

Автор илдәшенең, милләттәшенең фани дөньядан бакыйлыкка күчүен теркәп калдырган. Ә менә үзе бу юлга кайчан баса, кайда җирләнә, — кызганыч ки, хәзергә бу сорауга җавап бирә алмыйбыз. Аның безгә мәгълүм соңгы шигырьләренең берсе – «Югалган яшьлек» Нью-Йорк хастаханәләренең берсендә «1966 елның язында» иҗат ителгән .

Шунысы ачык: XX гасырда катлаулы язмышлы Әхмәд Гәрәй дигән милләттәшебез яшәгән, шигырьләр иҗат иткән, тәрҗемә белән дә шөгыльләнгән, Рәшит Ибраһимов, Гаяз Исхакый кебек «дөнья»ның (ул бу сүзне бик еш һәм яратып куллана) төрле төбәкләрендә яшәгән. Аның әсәрләре татар әдәбиятында билгеле бер урын алырга хаклы. Аларда мөһим генә уй-кичерешләр, татар сүз сәнгатен баеткан яңа образ-сурәтләр, географик-тарихи мәгълүматлар бар. Язмабызда бу мөһаҗир шагыйрь иҗатының кайбер яклары хакындагы фикер-күзәтүләребезне бәян иттек. Алла боерса, аның аерым шигырьләре дә укучыларга тәкъдим ителәчәк.

* * *

Әхмәд Гәрәй җыентыкларының тышлыгына, эпиграф рәвешендә, үзенең шигырьләрен дә урнаштыра. Менә аларның кайберләре:

Озакта калган илдәшләр, мине хәтергә алсагыз,
Хәятта милли берлекне иман шикелле саклагыз.

* * *

Доктор! Мине, авыру, диеп, бирмә дару,
Мин авырыйм, фәкать ул чарасыз авыру –
Һичбер табибта юк аңа дәва:
Минем авыруым – илне сагыну. ■

Әдипнең тәүге әсәре

Мәхәббәт чокыры

Камил Кәримов

1968 елда, бәхет эзләп, Оренбург өлкәсенә «Чирәм җир» игәргә киттем. Шунда бөтенләйгә калырга да исәп бар иде.

Ләкин...

Бер шигырем белән хикәямне «Яшь ленинчы» гәҗитенә җибәргән идем. Зөлфәт исемле шагыйрьдән хат алдым: шигырем басылып чыккан, ә хикәямдә Паустовский чалымнары бар, дигән... Миңа шул җитә калды, Чирәм җирнең сөрелеп бетмәгән далаларын калдырып, кайттым да киттем!

Су бораулаучы булып урнаштым. Актанышның Чынык авылындагы бер кызга сокланып, «Мәхәббәт чокыры» дигән хикәя яздым да «Яшь ленинчы»га килдем. «Балалар гәҗитенә бигүк ярамас бу, әйдә, Фаилгә керәбез», – ди Зөлфәт.

Фаил Шәфигуллин «Идел» альманахының баш мөхәррире иде. Күз алдымда укып чыкты да: «Шәп бу!» – диде. Хикәя «Идел»дә 1977 елны басылып чыкты.

Фаил «Идел»дән «Чаян»га күчте, Зөлфәт тә «Яшь ленинчы»дан «Чаян»га китте. Мин дә, еллар үткәч, шул редакцияләрдә эшләп өлгердем...

***

(Хикәя)

Миңа унҗиде яшь...

«Яшь әле син», – диләр, ләкин мин әнинең иң олы улы. Инде унынчының беренче чиреген тәмамладым. Укуымнан үзем канәгать, әни генә менә:

– Берәр кыз белән дуслашсаң, йөрәгең уяныр, көнчелек утың кабыныр, уку отличникларын куып җитәр идең, – ди.

Каныктылар бит шул кызлар да кызлар дип. Мәктәптә сабакташларым өчен мин кызлардан куркучылар исемлегендә. Ә өйгә кайтсам – әни, кыюлыгың юк, ди. Әти белән алар мәктәптә укыганда ук дус булганнар. Ә минем әле кызлар турында бер дә уйлаганым юк. Нигә ашыгырга? Дуслык мине генә әйләнеп үтмәстер, шәт...

Көзге салкыннар башлану белән, тоташ яңгырлардан лыҗырдаган юллар ныгый башлады. Кала белән безнең авыл арасында яңадан хәрәкәт көчәйде. Көннәрдән бер көнне клубыбызга артистлар килде. Концертларын атказанган бер тел бистәсе алып бара икән, бик күңелле булачак, ди.



«Мәхәббәт чокыры» хикәясе авторының үсмер чагы

Әни миңа бер билет бирде. Ул үзе дә бара баруын, тик аның гадәте шулай: билетны икебезгә ике җирдән ала. «Миңа ияреп йөрер чагың үткән, кешеләр белән аралаш», – ди.

Мин өйдән чыкканда, урамда, җилләргә ияреп, беренче кар бөртекләре оча башлаган иде. Әйтерсең, алар да минем белән концертка ашыгалар.

Башка көннәрдә клуб янына халык җыела, уйный белгәне дә, белмәгәне дә, дәррәү кубып, гармун кычкырта торганнар иде. Бүген, шәһәрдән чын осталар килгәч, берәүнең дә моңа кыюлыгы җитми, күрәсең. Хәтта, мин-мин, дип йөргән Әмин дә гармунын өендә калдырып килгән.

Урта рәттә бары минем урын гына буш калган. Сул ягымда – бүгенге көн яңалыкларын кем белән дә уртаклашырга белмичә тилмереп утыручы «радио» Мәликә апай, ә уң ягымда – сигезенче класска кадәр бергә укыган күрше Чынык авылы кызы Гөлнәфидә иде. Гөлнәфидә хәзер фермада сыер сава бугай, «...месез ...месез...», – дип, пышылдашып кына исәнләшеп алдык.

...Шушы көнгә кадәр кызлар йөзенә туры карый алганым юк иде. Бит урталарында «мәхәббәт чокыры» булган кызлар ярыйсы гына сөйкемле була икән. Гөлнәфидәнең ирен читләреннән ерак та түгел борчак сыярлык кына «мәхәббәт чокыры»н күреп алдым. Көлгән чакта аннан менә-менә гөлләр шытып чыгар сыман. Күз сирпеп алуымны Гөлнәфидә дә сизде, ахры – бит алмалары кызарды. Безне күзәтеп утыручы «радио» Мәликә апай, чыпчыклар көтүе очып киткән тавыш чыгарып, пырхылдап куйды. Концерт беткәнче аның көлүеннән алҗыячак сул колагым кызганыч. Мәликә апай ул кызык булса да, булмаса да көлә.

Без күңел ачкан арада урамга күктән кар болытлары ишелеп төшкән. Күз ачкысыз буран җир белән күкне тоташтырган иде.

Бүреклеләр бүрекләрен батырып киде, ялан башлылар пальто якаларын күтәрдек.

Гөлнәфидә, урамга чыккач, кинәт туктап калды. Никтер, эндәшмичә үтеп китә алмадым.

– Авылдашларыңны көтәсеңме?

– Алар кунарга кала, ә миңа иртәнге савымга өлгерәсе.

– Гөлнәфидә... бер ялгызың мондый буранда юлга чыгу ярамас... Әйдә, озатып куйыйм, – дидем.

Үз авызымнан шундый сүз чыкканга үзем шаккаттым. Юкка гына, кыюсыз, дип үрти мине әни. Тик менә Гөлнәфидә дә ризалашса иде... Ул елмайды... Елмаю караңгы төндә дә, буран эчендә дә күренә икән!

Буран эзләребезне күмеп бара, йөзләребезне кар белән сыламакчы була, яка эченә кереп тула. Гөлнәфидә минем беләгемә ябышты. Беләгемдә аның усак яфрагыдай нәни кулы орынган урын кайнарланып бара.

Чынык капкасына җитәрәк, килгән юлыбызга карап, буранга аркан атлап карадык. Җиңел булса, бөтен кеше артка таба гына атлап йөрер иде. Борылмакчы идек, кинәт икебез дә берьюлы бил тиңентен карга чумдык. Бу урыннан Чынык халкының гөл утыртырга туфрак ташыганын Гөлнәфидә дә, мин дә бик яхшы белә идек... Кара син аларны, нинди шәп «гөл савыты» казыганнар, икебезгә дә тап-таман гына, чыгасы да килми. Миңа әллә нәрсә булды, батыраеп, Гөлнәфидәнең «мәхәббәт чокыры»на иреннәремне тидерә яздым. Ул кинәт кенә йөзен читкә борды.

– Нишләвең бу?..

– Битеңнән кар бөртекләрен өреп төшермәкче идем.

– Ә-ә... котым очты, әллә мин әйтәм...

Һәм Гөлнәфидә, юка пыяла челтерәп ватылган тавышлар чыгарып, көлеп куйды. Шундый оялдым, шундый оялдым, бу «гөл савыты»ннан ничек чыкканымны да сизми калдым.

Кар сырышкан тәрәзәләр янына килеп җиткәч, Гөлнәфидә миңа үзләреннән әтисенең бүреген алып чыкмакчы иде дә, мин егетләргә хас горурлык белән кире кактым. Шуннан соң ул башындагы йон шарфын салды. Минем чәч араларымдагы кар тузанын сыпырып төшерде. Чәчләремдә сак кына кулын йөртүе бераз әниемчә дә, бераз башкачарак та иде... Аннары ул, уйлап-уйлап торды да, кулындагы шарфын минем муеныма урап, очларын куеныма яшерде. Кичә генә туган каз бәбкәсе кебек йомшак шарфтан бөтен тәнемә җылы йөгерде. Кире бирмәкче идем: «Башка бервакытта да авылыгызга килмәм», – дигәч, ризалаштым.

Кайтыр юлда мин әлеге «гөл савыты»на «Мәхәббәт чокыры» дип исем куштым. Бәлки, чыныклылар да әле аны шулай дип атарлар.

Җил уңаеннан атлагангамы, буран бераз сабырлангандай булды.

Яланбаш кайтып кергән Гөлнәфидәне күреп, әти-әнисе ни әйтер?.. Ә әни?.. Минем муенымда һәр җебе шомырт чәчәгеннән эрләнгән кызлар шарфы күргәч, ниләр уйлар икән?!.

1977 ел

Редакциядән: *Мөхтәрәм каләмдәшебез Камил Әдһәм улы Кәримовны юбилее белән ихластан котлап, сәламәтлек, иминлек һәм иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №7 июль 2020

Уймак-уймак уйлар

(Куен дәфтәреннән)

Сәяф Шәйхи

Минем авылым Түбән Кыерлы (Мамадыш) бормаланып-бормаланып агучы Бүрсет елгасы буенда урнашкан. Алтын көзләре, салкын кышлары, җылы язлары, назлы җәйләре белән табигатьнең бер кыйпылчыгы булып, җиһан түрендә урын алып яшәүче бер гади генә авыл ул. Кызлары сөйкемле, чишмә сулары саф, талларының күләгәләре дә җанга ямь, рәхәтлек бирә бит аның. Шаян җилләре, шушы талларның күләгәләренә чумып, әкрен генә йокы симертәләр. Мәңгелектән килеп, кире мәңгелеккә таба агучы нәни инешебездән дә сөйкемлерәк, тыйнаграк агышның булуы да мөмкин түгел. Барча гүзәллек, ямьлелек бары тик шушы төбәктә генә!

***

Урман эчендә – дымсу яшькелт күләгәләр. **ҖИЛСЕЗ ВАКЫТТА ДА ШЫБЫРДАШЫП, НИ ӘЙТЕРГӘ ТЕЛИЛӘР ИКӘН БУ ТЫНГЫСЫЗ УСАКЛАР?!.**

***

Кайбер кешеләр тормышыбызны, дөньябызны яманларга яраталар. Тормыш та, дөньяда яшәү дә бик кызыклы. Ләкин шул ук вакытта ясалма авырлыклар китерүче җитәкчеләребезнең булуы күңелләр күгенә авыр болытлар керүгә сәбәпчедер, мөгаен. Шулай да дөньяны, тормыш итүне мавыктыргыч итү үзеңнән тора. Инде олы яшькә җитеп килсәм дә, укыйм, өйрәнәм. Гомерем буе эшләдем, укыдым. Әле дә булса укыйм. Күңелемдәге хисләремне шигырь юлларына салам.

***

Торналар илле елга кадәр һәм хәтта артыграк та яшиләр. **ПАР ТОРНАЛАР ҮЗЛӘРЕНЕҢ ГОМЕР АГЫШЫНДА ҺӘРВАКЫТ БЕРГӘ БУЛАЛАР.** Парлы торналар башка бер торнаны да якын итмиләр: ул-бу була калса, гомер азагына кадәр, бер-берсенә тугрылык саклап, ялгыз яшиләр. Торналар тавышы, нинди генә каты күңелле, таш бәгырьле булсалар да, кешеләрне уйланырга, моңланырга, үткән мизгелләрне сагынырга мәҗбүр итә.

***

Тормышның һәр мизгеленнән ләззәт табып яшәргә кирәк. Бер мизгелдә барысы да – рәхәтлекләр дә, михнәтләр дә юкка чыгарга мөмкин.

***

ҺӘРКЕМ ҮЗЕНЧӘ БӘХЕТ ЭЗЛИ ҺӘМ ШУҢА ОМТЫЛА ДА. БӘХЕТ ЮК БИТ УЛ, БУЛСА ДА – БЕР МИЗГЕЛЛЕК КЕНӘ.

***

Яхшы булу гына җитеп бетми, башкалардан яхшырак булырга кирәк.

***

Мәхәббәт – Аллаһ биргән бөек кодрәт, ул кешегә бәхет китерә. Кадерен белмәсәң, үкенерлек тә итә.

***

Төннең иң караңгы мизгеле – таң алды.

***

Олыдан да олы ни олы? Җиргә тереклек биргән, безне яшәтүче икмәк олы. Күкрәгенә терәп кисәргә икмәге булган кеше дә олы һәм бәхетле.

***

АВЫРУ ҺӘМ ҮЛЕМ – ТОРМЫШЫБЫЗНЫҢ, ГОМЕРЕБЕЗНЕҢ БЕР ӨЛЕШЕ.

***

Акыллы сүз тиле кеше авызыннан чыга. Акыллы кеше һәрвакытта да сүзен әйтеп бетерми.

***

Иң акыллы, матур, ягымлы, җанга җылы бирүче сүзләр – әйтеп бетерелмәгән сүзләр. Ашык-пошык әйтелгән сүзләр – уйланып әйтелмәгән, уйлап бетерелмәгән сүзләр.

***

Сыйларга сыең булмаса, сыйларга телең булсын.

***

БЕЗНЕҢ ЧИШМӘБЕЗДӘ КИЧЕН ЙОЛДЫЗЛАР КОЕНА, ИРТӘН КОЯШ НУРЛАРЫ БИИ, КОШЛАР ЧУТ-ЧУТ КИЛӘ. ҺӘР ТЕРЕКЛЕК МӘХӘББӘТ ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛИ. МИНЕМ ТЕЛЕМ ДӘ МӘХӘББӘТ ТЕЛЕ БУЛСА КИРӘК.

***

Сылу кешегә солы капчыгы кидерсәң дә килешә. ■

АНА БАЛАНЫ ИКЕ КАТ ТУДЫРА: БАШТА – ТӘН БИРЕП, АННАРЫ – ТЕЛ БИРЕП.

Зөлфәт вафаты

Ләбиб Лерон

Көндәлектән:

«2006 ел, 25 ноябрь.

Көндезге сәгать 12ләрдә Зөлфәт абый шылтыратты (фатирларыбыздагы телефоннар аша сөйләшәбез. – Л.Л.):

– Әгъләм янында булдым. Комада ята. Мамыкны сыгып, авызына су тамызган идем, кое төбенә ике чиләк су салдылар, ди. Үзе әйтә: «Тугызынчы май... Урал тауларында... Икәү бергә...» – ди. Әллә мине теге дөньяга чакырды инде?!

Зөлфәт абыйны үземчә юатмакчы – кайчандыр аларның Мөдәррис Әгъләм белән икәүләп Уфага баруын кинәт кенә исемә төшереп, аңлатмакчы булам:

– Студент чакта сез бергәләп Уфада булгансыз. Майда баргансыздыр, мөгаен?! Мөдәррис абыйның шуны искә төшерүе инде, – дим.

Трубканы Зөлфәт абыйның хатыны Фирая апа ала (без сөйләшкәнне ишетеп торган икән):

– Ие, ие, май башларында барганнар, икесе дә пәлтәдән булганнар, – ди...

Мин шулчак әлеге сәфәргә бәйле бер мәзәкне Зөлфәт абыйның исенә төшерәм:

– Уфада студентлар белән очрашу бара икән. Зөлфәт залдагыларга Мөдәррис Әгъләмне тәкъдим итә: «Мин сезгә Казаннан Тукайны алып килдем!» – ди. Мөдәррис, юлдашы Зөлфәткә ишарәләп: «Такташ та минем белән!» – дип җиффәрә...

Трубкадан Зөлфәт абыйның да, Фирая апаның да рәхәтләнеп көлгәне ишетелә...»

Каләмдәш дустының аңсыз ятканда әйткән сүзләре Зөлфәт абыйның күңеленә тирән уелып калды шикелле. Өстәвенә, шул сүзләрен әйткәннең икенче көнендә Мөдәррис әкә үзелде – җаны фани дөньядан аерылды, бу да борчылучан шагыйрь йөрәгенә сизелерлек йогынты ясагандыр...

Шагыйрьнең кызы Кадриянең, 25 ноябрь көнен хәтерендә яңартып, болай дигәне истә:

– Әти бик дулкынланган иде, әрлебирле килде: «Ярты җанымны Әгъләм янында калдырып кайттым», – диде. Алай әйтергә ярамый бит, әти, – дидем.

> **«**
> **– Әти бик дулкынланган иде, әрле-бирле килде: «Ярты җанымны Әгъләм янында калдырып кайттым», – диде.**

Болай да вакыт-вакыт сырхаулап алган Зөлфәт абый көннәрдән беркөнне хастаханәгә кереп ятарга мәҗбүр булды.

2007 елның 4 гыйнварында (кичә шагыйрьнең туган көне иде) хатыным Фидания белән Чехов базары янындагы хастаханәгә *(заманында халык аны, гел түрәләр генә дәваланып ятканга күрә, «обком хастаханәсе» дип йөртә иде. – **Л.Л.**)* Зөлфәт абыйның хәл-әхвәлен белергә бардык. Ул 407 нче палатага урнашкан икән. Без күргәндә ашханәдән пеләш башлы бер карт белән чыгып килә иде. Палатага кердек. Кучтәнәч-мазар һәм башка газета-журналлар белән бергә, әле генә дөнья

Зөлфәт абыйның хастаханәдә яткан чагы. 2007 ел, 4 гыйнвар

күргән, тышлыгына мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакировның фоторәсеме төшерелгән «Сәхнә» журналын да алып килгән идек. Җырчы сурәтенә карап, ул: «Рәшит Ваһапов кебек бөек, Илһам шикелле җырчы татарда бүтән булмастыр инде, иртә үләлмәдем дип ул зерә борчыла», – диде.

Сизелерлек дәрәҗәдә ябыккан булуына карамастан, Зөлфәт абыйның хәле болай ару күренде. Безнең белән шаярып-көлеп сөйләште. Алмаш-тилмәш аның белән фотога төштек. Зөлфәт абый белән Фидания үзара гәпләшкән арада, Роберт абый Әхмәтҗановның да хастаханәдә ятуын белеп, берме-икеме кат өскә күтәрелеп, аңа да күчтәнәчләр кертеп, бер очтан палатадашы – Мөслим районының элекке башлыгы Рөстәм Шәрипов белән икесен фотосурәткә алып чыктым. Шулвакыт Зөлфәт абыйның якташы – Кырынтау егете Рөстәм Шәриповка кагылышлы «Мөмкин!» дигән шигыре искә төште:

Гаҗәеп бер хәбәр килде шулай
Туган төбәк – Мөслим ягыннан –
Күптән вафат булган авыл урынына
Яңа йортка нигез салынган!
Аңлап була Рөстәм Шәриповны! –
Хакиме ул шушы төбәкнең...

Рөстәм әфәнде, Роберт абыйга ишарәләп:

– Роберт абый әйтә: «Хәзер мин сине шагыйрь Зөлфәт белән таныштырам әле!» – ди...

Рәхәтләнеп көлештек.

Икесен дә сурәткә алып, кабат Зөлфәт абый палатасына төштем.

– Язып буламы монда, Зөлфәт абый? – дип сораган идем, көлә:

– Кая ул! Укол белән теткәләп бетерделәр! – ди.

Мөслим районының элекке хакимият башлыгы Рөстәм Шәрипов белән. 1997 ел

Зөлфəт абый хатыны Фирая апа һəм оныгы белəн. 2006 ел, 1 сентябрь

Зөлфəт абый балалары Азамат, Илһам, Фазыл, Кадрия белəн. 1980 нче еллар



Ике мəшһүр татар, ике бөек шагыйрь – Зөлфəт һəм Мөдəррис Əгъләм

Зөлфəт абый белəн кызыклы хəллəрне искə төшереп утырганда, нигəдер, келт итеп теге көн – 25 ноябрь искə төшеп алды. Җиңү көненə нибары дүрт ай калып бара иде...

2014 елның 16 апрелендə Г.Камал театрында, Зөлфəт абыйга алтмыш яшь тулу уңаеннан, тантаналы əдəби-музыкаль кичə (сценарий авторы Ркаил Зəйдулла дип истə калган) үтте. Шуның йомгаклау өлешендə Зөлфəт абый сүз алды. Ул, Тукай, Такташ, Пушкин кебек олуг шагыйрьлəрнең яшьли үлүлəренə ишарəлəп, үзенең алтмышка җитүенə кыенсынгандай, болайрак əйткəн иде:

– Чын шагыйрьлəр бу яшькəчə яшəми, хəерлегə булсын!

Əлеге истəлекле кичəдəн соң күп тə үтмəде, Зөлфəт абый бүлнискə (бу юлы 12 нче хастаханəгə) янə кереп ятты.

Без хəлен белешергə килгəн көнне, өч-дүрт яшьлəрдəге оныгы Нəфисə (Кадриянең олы кызы) белəн палата тəрəзəсе аша сөйлəшеп, аңа кул болгап торган чагы иде. Кабат аның хəлен белешү насыйп булмады инде безгə...

15 май көнне кичен Зөлфəт абыйның үлеме турында хəбəр алдык: «Инфаркт...» – дилəр...

Реанимациядə ятты. Аннан алдагы көннəрдə генə комага китеп алган булган. «Анда күргəннəрем ике китап язарга җитəрлек!» – дигəн ул кызы Кадриягə...

> **«**
> **9 май көнен узып киткəч, бик сөенгəн үзе. Исəн калдым бит тəки, дигəн.**

9 май көнен узып киткəч, бик сөенгəн үзе. Исəн калдым бит тəки, дигəн. Тик, ни хəл итəсең, кем əйтмешли – язмыштан узмыш юк...

Яңа бистə зиратында ике дусның – ике мəшһүр татарның, ике бөек шагыйрьнең – Зөлфəт һəм Мөдəррис Əгъләмнең каберлəре бер тирəдə генə. Алар тормышта да, иҗатта да гел бергə булды, каберлəре дə янəшə. ■

Истә, һаман да истә!

Җырчы
Зифа Басыйрованың
тууына 110 ел

Җырчы, ТАССРның атказанган артисткасы Зифа Җәмил кызы Басыйрова 1910 елның 4 июлендә Мөслим районының Мөслим авылында дөньяга килгән.

Ул, 1936 елда Казан театр училищесын тәмамлаганнан соң, 20 елга якын Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, 1956 елдан Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшли.

З.Басыйрова «Су буйлап», «Өй артында шомыртым», «Дөм-дөм», «Шөгер», «Таң атканда», «Фазыл чишмәсе» кебек бик күп җырларның беренче башкаручысы була.

З.Басыйрова 1979 елның 7 февралендә вафат булды.

Композитор
Әнвәр Бакировның
тууына 100 ел

Композитор, ТАССРның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1973) Әнвәр Закир улы Бакиров 1920 елның 7 июлендә Казанда туган. Булачак көйязарның балачагы Биектау районының Әлдермеш авылында уза. Казан музыка училищесын 1940 елда – скрипка классы буенча – И.Әүһадиевта, композиция классы буенча Ю.Виноградовта тәмамлый. 1951-1956 елларда шул ук училищеда укыта.

Ә.Бакировның төп әсәрләре: «Алтын тарак» (балет, 1957), «Тальян моңы» (музыкаль комедия, 1962), «КамАЗ» (увертюра, 1974), «Тукай» (опера, 1983).

Ә.Бакиров 2001 елда вафат булды.

Язучы
Җәвад Тәрҗемановның
тууына 100 ел



Язучы, галим, ТАССРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1981), 1947 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Җәвад Әфтах улы Тәрҗеманов 1920 елның 8 июлендә Казанда туган.

1938 елда, 10 сыйныфта укыганда, аның «Галстук» исемле беренче шигырьләр җыентыгы дөнья күрә. Киң танылу алган әсәрләре: «Ябалак һәм Тавык» (1940), «Шуктуган» (1962), «Шаян һәм Наян» (1965), «Көмешкойрык» (1967) әкиятләре һәм «Лобачевскийның яшьлеге», «Алтын дага» романнары (1965).

Җ.Тәрҗеманов 1995 елның 9 мартында Казанда вафат булды.

Безнен мирас №7 июль 2020

Драматург
Мөхәммәт Әблиевнең
тууына 120 ел

Драматург Мөхәммәт Шәриф улы Әблиев 1900 елның 15 июлендә Кама Тамагы районының Даныш авылында туган.

Язучы буларак ул узган гасырның егерменче елларында таныла башлый – хикәяләр (мәсәлән, «Минем дустым сугышта», 1922), повестьлар («Итекче кызы», 1928; «Ком улы», 1929) яза, үзен драматургия өлкәсендә дә сынап карый («Ике туй», 1925; «Лейтенант», 1940). М.Әблиев 1936 елда атаклы «Шәмскамәр» драмасын яза.

Әдип, сугышның тәүге көннәреннән үк укчы дивизиянең сәяси бүлеге комиссары сыйфатында, фронтның алгы сызыгында сугыша һәм күп тә үтми (1941 ел) һәлак була.

Галим
Хәмид Мөштәринең
тууына 120 ел

Күренекле галим, физика-математика фәннәре докторы (1937), профессор (1938), ТАССРның (1940) һәм РСФСРның атказанган фән һәм техника эшлеклесе (1965), сүрүләр теориясе буенча Казан фәнни мәктәбенә нигез салучы Хәмид Мозаффар улы Мөштәри 1900 елның 22 июлендә Оренбург шәһәрендә туган.

Х.Мөштәри 100дән артык гыйльми хезмәт яза.

Ул – мәктәпләр һәм югары уку йортлары өчен татар телендә физика һәм математика дәреслекләре, физика һәм метеорологиядән татарча терминнар җыентыгы авторы.

Казанның бер урамы галим исеме белән аталган.

Х.Мөштәри 1981 елның 23 гыйнварында вафат булды.

Язучы
Гали Рәфикыйның
тууына 130 ел

Язучы һәм тәрҗемәче, педагог-методист Гали Рәфикый (Гали Лотферахман улы Рәфиков) 1890 елның 29 июлендә Уфа губернасындагы Бәләбәй өязендә (Баязит авылында) туган. Башлангыч белемне ул Стәрлебаш мәдрәсәсендә ала, 1905 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Гали Рәфикыйның 1913-1915 елларда Казанда яңа гына чыга башлаган «Аң» һәм «Ак юл» журналларында бер-бер артлы егермедән артык әсәре дөнья күрә. 1924 елның язында ул Бәләбәй кантон халык мәгарифе инспекторы итеп билгеләнә, 1928 елда исә Бәләбәй татар-башкорт педагогия техникумына туган тел һәм әдәбият укытучысы булып килә. Гомеренең соңгы көненә кадәр шул эшендә кала.

Г.Рәфикый 1944 елның язында үпкә авыруыннан вафат була. ■

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

Безнең мирас №7 июль 2020

75 ел эзләдем

Альберт Гаделша

Мәкалә авторы Альберт Гаделшаның бабасы Сөнгатулла (аның алдында – улы Рәшит), әбисе Мәфрүзә (оныгы Альберт белән), әнисе Гөлҗәннәт һәм әтисе Сафиулла. Зәй. 1940 ел

Әтием Сафиулла Сөнгатулла улы Гаделшин гади крестьян гаиләсендә 1915 елның 12 февралендә, беренче бала булып, Зәй районының Югары Шепкә авылында дөньяга килә.

Бабам Сөнгатулла 1914 елда Беренче Бөтендөнья сугышыннан исән-сау кайткач (өч мәртәбә җиңел яраланган була), Зәй районының Пәнәче авылыннан, димләтеп, булачак әбием Мәфрүзәгә өйләнгән.

Әбием белән бабамның сигез баласы дөньяга килә. Әтием Сафиулла – беренче бала, калган җиде энесенә, бер сеңлесенә өлкән абыйлары булып, әти-әнисенең ярдәмчесенә әйләнә.

Әтием Югары Шепкә авылының җидееллык мәктәбенә беренче сыйныфка 1922 елда аяк басып, аны 1929 елны тәмамлый. Яшьтәше һәм сабакташы Зәкиулла белән, Алабуга педагогия техникумына имтихан тотып, укырга керү бәхетенә ирешәләр.

***

Инде бу чорда бабам Сөнгатулланы район җитәкчеләре авыл советы рәисе итеп билгелиләр. Сайламыйлар, ә билгелиләр. Чөнки беренче авыл советы рәисенең үле гәүдәсен кышын Зәйдән аты авыл советы идарәсе янына алып кайтып туктый. Идарәдә дежур торучы, телефон шалтыравына җавап бирүче апа, икенче катта урнашкан идарә тәрәзәсе аша рәиснең аты кайтып туктавын күреп, озак кына аның идарәгә кермәвенә аптырап, каршы алырга чыкса, аптырап кала. Рәис кошовкада хәрәкәтсез ята, өстенә туны капланган…

Район милиция бүлеге тикшерүчеләренең эзләве бернинди дә нәтиҗә бирми. Фаразлаулары буенча, рәис Зәйдән урман аша кайтканда, дошманнары, көтеп торып, аркасына ике җәпле сәнәк белән тирән чәнчү ясаганнар.

Мәрхүмнең гәүдәсе, бабам сөйләве буенча, бөкрәеп кошовкага авып, авызыннан кан агып җәелгән. Аркасында ике зур җәрәхәт, аннан да кан агып, бөтен киемнәрен чылатып, салкында укмашып каткан була.

***

Яшьләрнең техникумда укулары күңелле дә, зәвыклы да була. Монда инде аның өстендә энеләрен «тәртиптә тоту», мал-туар карау бурычы юк. Әйдә, рәхәтләнеп укы, белем ал!

Уналты-унҗиде яшьлек яшүсмер «егетләрнең» билгеле инде, күзләре кызларга төшә башлый. Техникумның югары курсларында «шәһәр» кызлары укый. Кызларга хас горурлык белән, алар авылдан килгән «малайларга» өстән генә карап узалар, теләр-теләмәс кенә аралашалар. Шулай да әтиемнең игътибары тулай торакта торучы «шәһәр» кызы Җәннәткә төшә.

Альберт Гаделшаның әнисе Гөлҗәннәт

Җәннәт дүртенче курста укый. Тыныч холыклы, төскә-биткә күзгә ташланырлык. «Шәһәр» кызы булса да, үзен бик тыйнак тота. Кием-салымы да «казенный» кебек күренә, шулай да күзне камаштыра.

Җәннәт илә Гөлҗәннәт булып, әтием курсташ кызлары аша исемен, каян килүен белешә, шулай итеп, акрынлап танышалар.

Булачак әнием Гөлҗәннәт детдомда тәрбияләнеп үскән, ятим кыз бала булган. Әти белән яшьтәшләр, аралары бары ике ай гына. Ул Минзәлә приют-детдомында биш яшеннән тәрбияләнгән. Әти-әнисе, абыйсы, игезәк энеләре фаҗигале 1921 елда ачлыктан үләләр. Гөлҗәннәт Актаныш районының Иске Богады авылында күршеләрнең түбәсез мунчасында берүзе утырып кала. Ул елны көчле янгын чыгып, шундый зур авылның яртысы көлгә әйләнә.

Әниемнең әтисе Лотферахман бабай һәм әбием Гөлҗамал уттан, ачлыктан котыла алмыйлар, ярты авыл халкы гүр иясе була. Күршеләре – мунча хуҗалары Лотферахман бабайның туганы Сабит абыйга хәбәр итәләр.

Үзенең дә ачлы-туклы яшәгән зур гаиләсе булу сәбәпле, укытучы, Кадермәт авылында яшәүче Сабит абый әниемне Минзәлә «приют»ына урнаштыра. Шулай итеп, әнием Минзәлә шәһәре кызына әйләнә.

> **Әнием үзен гомер буена бәхетсез сизде. Татар халык җыры «Саубуллашу»ны акрын гына җырлап, кинәт сүзсез калып, елап, ишек алдына чыгып китә иде ул.**

Яхшы укыган өч кыз баланы, дүртенче сыйныфны тәмамлагач, Алабуга педагогия техникумына укырга җибәрәләр, шул исәптән әниемне дә. Аларны инде бернинди дә имтиханнарсыз кабул итеп, дәүләт хисабына укытып, киендереп, тукландырып торалар. Белем һәм һөнәр бирәләр.

Техникумны тәмамлагач, әниемне Актаныш районындагы Яңа Әлем авылына укытучы итеп җибәрәләр. Егет белән кыз арасында хатлар йөри башлый. Менә, ниһаять, әтиемнең дә техникумда соңгы чыгарылыш имтиханнары якынлаша. Әниемне дә яңадан техникумга квалификацияне күтәрү курсларына чакыртып, югары сыйныф балаларын укытырга әзерлиләр. Ул курсташлары белән җәйге таңнар атканчы Кама елгасы яры буйларында бергә йөрүләрен сагынып искә ала иде.

Техникумны тәмамлауга, әтинең армиягә алыну вакыты җитә. Сөйгән ярым читләргә калмасын, дип, өйләнешәләр. Аларга карап дигәндәй, тагын өч курсташы да, туй ясап, гаилә кора.

Әтине, сәламәтлеге яхшы булуын искә алып, Сталинград шәһәрендә урнашкан хәрби очучылар мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ул чорда әле ул «хәрби училище» дип аталмыйча, «мәктәп-школа» дип йөртелә.

Хәрби очучылар мәктәбендә очучы хәрби лейтенант дәрәҗәсе алып, хезмәт итү вакытын тутыргач, әтием, армиядә калмыйча, туган ягына – Зәй районына кайта. Зәй РОНОсы аны Бигеш авылы җидееллык мәктәбенә завуч итеп эшкә җибәрә. Шунда ул әниемне дә Актаныштан барып ала.

Шулай итеп, әтием-әниемне сагынып шушы юлларны сырлаучы мин фәкыйрегез Бигеш авылында дөньяга аваз салганмын.

Әниемнең сөйләвенчә, укытучылар коллективы бик тату эшләгән, яшәгән. Кода-кодагый булыйк, дип, әтием миннән коллегасы кызының хәтта колагын да тешләткән. 1939-1940 нчы елларда тормыш җайлана төшә, туйганчы ипи ашарга мөмкинлек туа. Өс-баш киемнәренең дә иркен сатуда булуы яшьләргә яшәү дәрте бирә.

1941 елның апрель азакларында Пәнәче дигән авылга әтине – мәктәп директоры, ә әнине завуч итеп күчерәләр. Әнием искә алганча, әтием Пәнәче мәктәбен төзекләндереп, парта, кара такталарын буятып, кышка ягарга урманнан утын китертеп, аны кисеп-ярып өйдертеп куя. Тору урыннары, билгеле инде, ялгыз авыл апасының фатирында була.

Көтмәгәндә, 1941 елның 22 июнендә Икенче Бөтендөнья сугышы башлана. Әтине һәм тагын яшь укытучыларны, авыл яшьләрен 5 нче июнь көнне, район хәрби комиссариатына чакыртып, фронтка озаталар.

Әниемнең сөйләвенчә, фронтка китүчеләрне бөтен авыл халкы Бөгелмә-Зәй-Чаллы олы таш юлына кадәр озата бара.

– Әтиең үзеңне кулыннан төшермәде, олы юлда аларны көтеп торучы җигүле атлар янына кадәр барып җиткәч, мескенем Сафиулла, кешеләрдән оялыбрак, синең белән икебезне кочып үпте, – дип, тетрәнеп искә ала иде әнием ул көнне. – Күздән

яшьләр чәчрәп чыгып, кояшлы көн томанга күмелгәндәй булды. Шушы мизгелләр әтиеңне соңгы мәртәбә күрү булган икән...

Әтиеңнәрне алып китүче атлар калкулыктан төшеп күздән югалганчы барыбыз да елап озатып калдык. Күңелләрне сөйләп тә, язып та аңлата алмаслык сагыш басты... Чит кешеләрдә фатирда торып, кулымда өч яшьлек бала – син, көзен дөньяга киләсе энең Илшат белән гомергә ятим каласыбызны күңел сизгән, күрәсең...

Үзем сабый чактан ятим калып, приют-детдомда үсеп, әтиең белән бәхетле генә тормыш корган идек, аяусыз сугыш бөтенесен җимерде...

Әнием үзен гомер буена бәхетсез сизде. Татар халык җыры «Саубуллашу»ны акрын гына җырлап, кинәт сүзсез калып, елап, ишек алдына чыгып китә иде ул. Энем Илшат белән безгә күз яшьләрен күрсәтәсе килмәгәндер, күрәсең.

Сугышка алынганнарны Зәйдән машиналарга утыртып Бөгелмәгә, аннан товар поезды «теплушкаларына» төяп, Ульяновск өлкәсендәге «Сугышка әзерләү пунктына» алып баралар. Кыска вакытлы курслар узгач, аларны фронтка җибәрәләр...

Әтине, хәрби очучы булуын искә алып, авиачастька юллыйлар. Анда күпмедер хезмәт иткәч, ни сәбәптәндер, 1942 елның 17 февраленнән аны Карелия фронтына – 21 нче укчы дивизиянең 326 нчы укчы полкына миномет взводы командиры итеп җибәрәләр. Бу вакытта ул өлкән лейтенант дәрәҗәсендә була.

Карелия фронты, немец гаскәрләрен тоткарлап торып, Ленинград шәһәрен саклауда күпмедер дәрәҗәдә йозак була. Соңрак, 1944 елның сентябрендә, Карелия һәм хәзерге Балтыйк буе илләрен фашист-илбасарлардан азат итү өчен киеренке сугышлар башлана...

***

Әтинең энесе Раббани абыйның сөйләвенчә, 1945 елда Венгриядә сугышканда алар әти белән хат язышып табышалар. Әти ул вакытта майор дәрәҗәсендә штабта хезмәт иткән була. Ул хәрби штаб телефоны аша энесе Раббани абыйны эзләп таба.

Сафиулланың энесе Раббани

Раббани абый – сержант, полк командирының адъютанты булып хезмәт итә, сугышларда катнаша. Аралары илле чакрым гына булып, әти аңа, яныңа үзем килеп чыгармын, дип вәгъдә бирә. Телефоннан сөйләшүдән соң, икенче көнне Раббани абыйларның полкы, көчле сугышларда катнашып, Германиягә кереп китә һәм әти белән элемтәләре югала. Ул вакытта әтиләрнең хәрби частьлары Венгриянең Кевел пунктында көчле каршылык күрсәткән венгр гаскәрләре белән аяусыз сугышлар алып бара. Шунда әтиләр штаблары белән хәбәрсез югалалар. Дәүләтнең Үзәк оборона архивының «Информация из донесения о безвозвратных потерях» белешмәсендә әтинең 1945 елның 20 гыйнварында Венгриянең Кевел җирлегендә хәбәрсез югалуы теркәлгән.

Мин армиядә 1958-1961 елларда Минск, Калининград шәһәрләрендә хезмәт иткәндә хәбәрсез югалган сугышчыларны барлау башланган иде. Ике мәртәбә язган мөрәҗәгатемә «Данных сведений не имеется» дип, коры, салкын хәбәр генә килде.

2019 елны компьютер аша Дәүләт архивының мәгълүматларыннан әтием турында бераз белешмә таптык. Энеләрем Илшат белән Рәйхәткә шатлыклы да, кайгылы да хәбәрне ишеттердем. Күпмедер вакыт узгач, энем Рәйхәт тә шатлыклы хәбәр җиткерде. Киленебез Розаның сеңлесенең Мәскәүдә яшәүче кызы Динә Дәүләт архивында эшли икән. Шул бала әти турында күп кенә яңа хәбәрләрне компьютер аша безгә җибәрде.

Наградной листка әтинең хәрби хезмәтенә, күрсәткән батырлыгына карап бүләкләнүе турында кыскача белешмә язылган:

«В бою 11 сентября 1944 года в районе выс. Питкявара, тов. Гадльшин командуя стрелковым взводом, лично сам поднял свой взвод в атаку на врага, сам шел все время впереди, увлекая, подчиненных на разгром противника, несмотря на сильный огонь врага, тов. Гадльшин первым ворвался в траншею, уничтожив при этом из своего автомата двух немцев. Продвигаясь со взводом по траншеям, был задержан сильным огнем пр-ка справа. Тов. Гадльшин, лично с двумя бойцами подорвал ДЗОТ пр-ка гранатами, мешавший продвигаться его взводу, тем самым дал успешно продвинуться взводу и неотступно проследовать врага.

В бою 13 сентября 1944 года перед ст. Алакуртти тов. Гадльшин со своим взводом, действуя в разведке, уточнил слабые места в обороне противника, после чего провел весь батальон незамеченным для врага.

За отличное выполнение ряд заданий командования и проявленную при этом доблесть и мужество, достоин награждения орденом Красной Звезды.

Командир 326 СП
Подполковник /Бастрыгин/
30 сентября 1944 года».

Сафиулла Гаделшин

Архивная справка

Сообщаем, что старший лейтенант Гадльшин Сафий Сунгатович, 1915 года рождения, место рождения не указано, домашний адрес на момент награждения: Татарстан АССР, Заинский район, д.Верхни-Шипки, командир минометного взвода 326 стрелкового полка 21 стрелковой дивизии (домашний адрес, должность так в моменте) награжден:

– орденом Красной Звезды №803118 приказом 21 стрелковой дивизии №071/п от 10.10.1944 года, награда вручена, временное удостоверение В №498639.

Других сведений о награждении не имеется.

Основание: ЦА МО РФ, картотека награжденных. Выписка дана соблюдением текста документа.

Заведующий архив хранилищем Т.Киселева.
8 августа 2019 года №11/236190
На №4722 от 11.06.2019».

Әти 1945 елның гыйнварында Венгриядә энесе белән телефон аша сөйләшкәндә штабта хезмәт итүен, өлкән офицер – майор дәрәҗәсе бирелүен, орден белән бүләкләнүен дә әйтә. Оборона министрлыгының Үзәк архивы нишләп шушы көнгә кадәр Зәй районы хәрби комиссариатына хәбәр итмәгән?!

Бик аяныч, без ул хәбәрне 75 ел көтеп, ниһаять, үзебез эзләп таптык.

Мәрхүмнәр – әбием, бабам, әнием һәм әтиемнең энеләре аның турында ачык хәбәр белмичә гүр иясе булдылар.

Әтинең икенче энесе Нурулла абый 1917 елда туган. 1945 елда японнар белән сугышта катнашып, каты яраланып, исән кайта. Ул, пенсиягә чыкканчы, яраткан һөнәре буенча – киномеханик булып эшләде. Яр Чаллы шәһәренең үзәк зиратында җирләнде.

Өченче энесе Габдулла абый 1919 елда туган. Алабуга педагогия техникумын тәмамлый. 1942 елдан фронтта була, өч мәртәбә каты яралана. 1945 елда Япония белән дә сугышта катнашып, тездән түбән сул аяксыз калып кайтты. Икенче группа инвалид, капитан дәрәҗәсендә иде.

Үзбәкстанда Навои шәһәрендә укытучы булып эшләп, ялга чыгып, туган җире Зәйгә кайтып торды. Шагыйрь, драматург, прозаик иде.

Туган-үскән авылы Югары Шепкәдә, бабамнар-әбиемнәр җирләнгән зиратта мәңгелек йортына 85 яшендә китте.

Мәфрүзә әби уллары Сафиулла (уңда) һәм Габдулла белән

Дүртенче энесе Лотфулла абый 1921 елда туган. Казанда елга техникумын тәмамлагач, армиягә Кара диңгез флотына хезмәткә чакырыла һәм сугыш башланганда хәрби корабльдә хезмәттә була.

1943 елның азакларында хәрби корабльләре дошманның көчле уты астына эләгә. Шул вакытта аягын снаряд кыйпылчыгы яралый. Исән калып, госпитальдә тездән югары уң аягын кисәләр. Икенче группа инвалид булып кайтты.

Ул, Казан дәүләт университетын тәмамлап, аспирантурада укып, филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә лаек булды. Төмән, Казан һәм Алабуга педагогия институтларында укытты.

Мәрхүмнең үлеме бик фаҗигале булды. Көзге караңгы кичтә Казанда Даурская урамында, җиңел машинага тапталып, 1995 елда 74 яшендә җан тәслим кылды. Самосырово зиратында җирләнде. Ел саен үзем дә, балалары һәм оныклары да каберенә чәчәк салып искә алабыз.

Бишенче энесе Раббани абый 1924 елда туган. Аны, 18 яше тулгач, 1942 елда сугышка алалар. Казанда өч айлык сержантлар курсын бетергәч, фронтка озаталар.

Ул, полк командирының адъютанты булып, дошман белән каты бәрелешләрдә катнаша. Алдарак язуымча, Венгриядә сугыш вакытында хат аша абыйсын – минем әтине эзләп таба. Телефон аша элемтәгә кереп, очрашырга сөйләшсәләр дә, очрашу насыйп булмый.

Безнең мирас №7 июль 2020

Раббани абый ике мәртәбә җиңелчә яралана. 1947 елда, җиде ел хезмәтен тутырып, армиядән кайта. 1960 нчы елларда, гаиләсе белән Чиләбе шәһәрендә яшәп, җиңгәчәбез – табиб Гөлсем апа белән тату гомер кичереп, шунда җир куенына керделәр.

Әтинең сеңлесе Маһифәрвәз апа 1928 елда бердәнбер кыз бала булып дөньяга килгән. Ул, Югары Шепкә җидееллык мәктәбен тәмамлагач, Үзбәкстанга абыйсы Габдулла янына Навои шәһәренә бара. Озын гомерен Таҗикстанның Дүшәмбе шәһәрендә яшәп, 85 яшендә чит җирдә, чит илдә дигәндәй, вафат булды.

Әтинең кече энесе Рәшит абый 1934 елда дөньяга аваз салып, төпчек бала булып иркәләнеп үссә дә, тормышның әчесен-төчесен татыды. Ул Яр Чаллы төзелешләрендә прораб булып эшләде.

Рәшит абый гомеренең икенче яртысында Актаныш районы үзәгендәге төзелешләрне җитәкләде. 2015 елны сиксән яшен тутырырга ике ай калганда, төнге сәгать бердә йөрәге тибүдән туктады.

Җәсәде Актанышның яңа зиратында җир куенына керде.

«Әтиебез Сафиулланың һәм бабабыз Сөнгатулланың Югары Шепкә зиратындагы каберләренә 2013 елда мәрмәр таш һәм яңа чардуган куйдык. Ел саен кайтып, каберләрен карап, дога кылабыз. Баш иеп, безне табып-үстерүләренә, тормыш бирүләренә рәхмәт әйтәбез.

***

Ел саен әби-бабамнарны искә алырга Зәй районының Югары Шепкә белән Суык Чишмә авылларына, Чаллыга, Актанышка кайтып, каберләрен барлап, чәчәкләр салып, аларга багышлап дога кылабыз.

Әниебез Гөлҗәннәтне, 1952 елны Югары Шепкә авылында укытуыннан алып, Суык Чишмә авылы башлангыч мәктәбенә мөдир итеп җибәрделәр. Мин ул вакытта бишенче сыйныфта, энем Илшат исә икенче сыйныфта укый иде.

Әниебез әтине ун елдан артык күз яшен түгеп көтте. Тормышның авырлыгы тагы да тол хатын җилкәсендә булу, йортсыз-җирсез кеше өстендә фатирда яшәү…

Укытучы Маһинур апа һәм аның сеңлесе Гыйльмебаян апа, Суык Чишмәдә әни белән якыннан танышып, абыйлары Сәхиуллага кияүгә чыгарга димлиләр.

Сәхиулла абый да фронтовик. Сугышта яраланса да, үзләренең хәрби частьларенда, хоз.взводта калып, Германиягә кадәр барып җитә. Ул бик эшчән, заманча әйтсәк, коммуникабельный кеше иде. Районның заготконторасында агент булып эшләде. Суык Чишмә авылы очына чорына карап бер дигән йорт салды, каралтыкура корды. Авылда безнең йортның гына түбәсе рубероид белән ябылган иде.

Өченче энебез Рәйхәт Суык Чишмә авылында 1954 елның 1 декабрендә дөньяга килде, әнисе һәм абыйларының йөзенә кызыллык китермәде. Елга техникумын тәмамлап, Төньяк флотта Североморскида су асты атом көймәсендә хезмәт итте. Университетны тәмамлап, ВЛКСМ өлкә комитетында инструктор булып эшләде. Утыз елга якын яшьләр лагеры «Волга»ның директоры булып хезмәт куеп, лаеклы ялга чыкты.

Энем Илшат, Казан медицина институтын тәмамлап, Коми Республикасына юллама алып, шунда стоматология дәваханәсендә баш табибның урынбасары булып

Сөнгатулла бабай кабере янәшәсендә Сафиулла Гаделшинга куелган истәлек ташы. Югары Шепкә. 2013 ел

эшләп ялга чыкса да, бүгенге көндә дә дәвалау бүлегендә хезмәт куя. Киленебез Гөлчәчәк белән өч кыз һәм бер ул тәрбияләп үстерделәр. Хәзер алар алты оныкның әби-бабайлары.

Әниебезнең җәсәден Суык Чишмә авылына алып кайтып, Сәхиулла абый янына җирләдек. Чуеннан чардуган койдырып, икесенә дә мәрмәр истәлек ташы куйдык.

Әтиебез Сафиулланың һәм бабабыз Сөнгатулланың Югары Шепкә зиратындагы каберләренә 2013 елда мәрмәр таш куеп, чардуганын алыштырдык. Ел саен кайтып, каберләрен карап, дога кылабыз. Баш иеп, безне табып-үстерүләренә, тормыш бирүләренә рәхмәт әйтәбез.

Үзем дә инде өлкән яшьтә булгангадыр, туганнарымны бик еш искә алам. Аларны күңелдән барлап, сүзсез генә сөйләшәм...

Утыз яшендәге әтием һәм аның дүрт энесе дә, Ватан сугышында катнашып, фашист илбасарларын тар-мар итүгә зур өлеш керттеләр.

Менә быел Җиңүгә 75 ел тулды. Әти-әниемә, исән булсалар, 105 яшь булыр иде. Барлык сугыш корбаннарының истәлеге алдында баш иеп, рәхмәт әйтәбез. Безне, киләчәк буынны, немец фашистлары коллыгыннан коткарып, тормышларын аямыйча, сугыш кырында ятып калды алар.

Җиңү безгә җиңел бирелмәде. Бу олы бәйрәм әле озак еллар буе хәтерләрне яңартып, тынычлыкка өндәп торса иде. ■

Безнең мирас №7 июль 2020

Гомерем мизгелләре

Әхтәм Зарипов



Язмышыма рәхмәт – үз гомеремдә артист та, режиссер да, язучы да булырга туры килде

***

«Америка язучысы Джон Стейнбек Россиягә килә. Илья Эренбург аны Загорскига экскурсиягә алып бара. Юл уңаеннан һөнәрче алачыгына алып керә. Нәрсә генә юк монда, әмма кунак эшләнеп бетмәгән аю сынын алырга тели. Оста аптырый, бүләкне әзерләре арасыннан сайлагыз, ди. Кунак исә меңләгән сын арасыннан бары тик монысында гына сәнгать таба. Аю бер күзен кыскан икән. Сәнгать әсәренә, төгәллектән бигрәк, серлелек кирәк шул. Әйбәт дигән киноларыбызга әнә шундый күз кысу җитми».

***

«1956 елның сентябрендә Мәскәү театр студиясендә укуларыбыз башлангач, артистлык һөнәренә өйрәтәчәк остазыбыз Лидия Ивановна Дейкунны 23 татар баласы көтеп утырабыз. Әлегә аны беребезнең дә күргәне юк. Яшьлегендә Станиславскийда укыган, МХАТ артисты булган, диләр. Көтеп утырабыз утыруын, әмма ул һаман юк та юк. Нишләргә?.. 10-15 минут вакыт узуга, ап-ак чәчле юан әби ишекне ачып карый да: «Простите, пожалуйста», – дип, тагын юкка чыга. Без һаман көтәбез. Инде таралышу турында сүзләр чыга башлагач, ишек ачыла да, теге юан әбинең башы пәйда булып: «Простите, где же татары?» – ди. Без хор белән: «Здесь», – дибез. Лидия Ивановна: «Как?! Вы же совершенно нормальные ребята», – ди һәм соңлап булса да дәрес башлана».

Әтием Исмеәгъзам Зарифулла улы белән әнием Гыйльмеҗиһан Хәсән кызы. Әткәйгә – 59, әнкәйгә 57 яшь. 1950 нче еллар ахыры

Әнием Гыйльмеҗиһанның май язып утырган чагы. Без хатыным Җәмилә белән өйләнешкән ел – 1958 елның көзе

Балачак дустым Ривнер Ганиев (сулда) сеңлесе Венера белән. Ривнер соңыннан академик, машина төзелеше институты ректоры булды. Венера (инде мәрхүмә) экономист булып эшләде. 1945 елның җәе

АВТОР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ

Әхтәм Исмеәгъзам улы Зарипов 1935 елның 15 июлендә Башкортстанның Илеш районындагы Тәҗәй авылында туган.

1956-1961 елларда Мәскәүдә Щепкин исемендәге театр училищесында укый.

1961-1972 елларда – Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты.

1972-1987 һәм 1987-1992 елларда – Казан телевидениесе студиясе режиссеры һәм баш режиссеры.

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Илеш районының Тәҗәй авылында (Башкортстан) мин үскән йорт. 1946 ел



Мәскәүдә укыганда каникулга туган авылга кайткач. Кадрга әти дә эләккән. 1958 ел

Авылда кунакта: әтием Исмеәгъзам, әнием Гыйльмеҗиһан, бертуган сеңлем (минем артымда), мин, хатыным Җәмилә, аның янында – бертуган апамның кызы Мурания. 1958 елның августы

***

«Балалар бакчасында сабыйларны тезеп утырталар да баллы ботка каптыралар икән. Ике-өч балага тозлыны. Шуннан балаларның барысы да: «Баллы», – ди. Тозлыны капкан бала да: «Баллы», – ди. Иң ахырдан берсе: «Тозлы», – ди. Ничек инде барысыныкы да баллы, аныкы гына тозлы?!. Тозлы кабып, баллы дигән баланы да күзәтәләр, ул боргалана. Ләкин, баллы, ди. Гомер буена тозлыны – тозлы, баллыны – баллы, дип яшәдем. Алай яшәү – рәхәт һәм бәхет. Нәтиҗәсе күз алдында: яшәү шартлары, тегесе, монысы, андыйларны яратмыйлар».

Хатыным Җәмилә (25 яшь), улларым Айдар (3 яшь) һәм Вилдар (3 ай) белән. 1963 ел, 12 май

Минем гаиләм: алда – хатыным Җәмилә, мин; икенче рәттә сулдан – кызым Зөлфия, улларым Вилдар (инде мәрхүм) һәм Айдар, аның хатыны. 1983 ел

«Башмагым» спектакленнән соң. Кәрим бай ролендә – мин – Ә.Зарипов. Уң ягымда утырганнар: профессор Смирнов В.К., Малый театр режиссеры, профессор Гладков М.Н., Камал театрыннан килгән режиссер Йосыпов Габдулла абый. (Фотода бөтен курс студентлары юк.) Алда утырганнар: Рәшит Галиәкбәров, Ринат Таҗетдинов, Николай Дунаев. 1958 ел, июнь

Минзәлә театрында эшләгән чак. 1955 ел

Минзәлә театрында «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин) спектаклендә уйнаган чак. Уртада – Әхтәм Зарипов, ягъни мин булам инде. 1956 елның язы

Мәшһүрләребез Галимә апа Ибраһимова һәм Габдулла абый Шамуков белән бергә «Әни килде» спектаклендә (Ш.Хөсәенов әсәре буенча) уйнаган чак. 1969 ел

***

«Шагыйрь Илдус Гыйләҗевнең «Мәхәббәттә өченче кеше артык» дигән шигыре бар. Диндә дә шулай бит. Мин һәм минем ышануым бар, башкасы артык. Өченчесе килеп кушылса, агрессия туды-ра. Аннары без бик кечкенә генә отышны да җиңү дип шапырынырга өйрәндек».

«Кырлай егете» спектакленең премьерасыннан соң. Г.Камал театры артистлары Нәкый Исәнбәт (рәсемдә – уртада) фатирында. Мин әлеге рәсемдә иң алгы рәттә уртада уң кулымның баш бармагын иягемә куеп төшкәнмен. 1970 нче еллар

Авылдашлар алдында чыгыш ясаган мәл. 2015 ел

РЕДАКЦИЯДӘН: ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ДАИМИ АВТОРЫ, ТАНЫЛГАН ЯЗУЧЫ, АКТЕР ҺӘМ РЕЖИССЕР ӘХТӘМ АГА ЗАРИПОВНЫҢ 15 ИЮЛЬДӘ ГОМЕР БӘЙРӘМЕ – 85 ЯШЬ ТУЛА. АНЫ ЮБИЛЕЕ БЕЛӘН ИХЛАСТАН КОТЛАП, СӘЛАМӘТЛЕК, ИМИНЛЕК ҺӘМ ИҖАТ УҢЫШЛАРЫ ТЕЛӘП КАЛАБЫЗ!

Авылдашлар арасында – сиксән яшьлегемне бәйрәм итәргә кайткач. Илеш районының Тәҗәй авылы. 2015 ел

***

«Җәмгыять кайсы чорда да авырый ул. Хәзер дә төрле-төрле чирләрдән интегә. Бигрәк тә билгесезлек чиреннән. Без барабыз, кая барганны белмибез. Көрәшәбез – ни белән – белмибез. Уңышсызлыкларыбызда хакимиятне гаепләп, үзебезне аклыйбыз. Шулай булдыксызлыгыбызны яклыйбыз, җан саклыйбыз. Мәсләксезлегебездә үз мескенлегебезне күрмибез».

*Сәхифәне, журналистлар Ф.Хуҗахмәтова һәм Г.Гыймадова язмаларыннан файдаланып, **Л.Лерон** әзерләде.* ■

«Безнең мирас» журналы редакциясе хезмәткәрләре белән: уңда – журналның баш мөхәррире Ләбиб Лерон, Ленар Гобәйдуллин, мин бахырыгыз (Әхтәм Зарипов), Марат Закир, Данил Салих. 2014 ел

Безнең мирас №7 июль 2020

Борынгы татар милли музыка уен кораллары

Ринат Гыйләҗев, «Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе

Барабан

Барабан ул – әзер кысага эшкәртелгән тире тарттырылган һәм аңа бәреп көчле тавыш чыгара торган корал. Аның турындагы беренче истәлекләр борынгы Шумер тарихына, безнең эрага кадәр өч мең еллар элеккеге һәм аннан да алдарак чорларга карый. Ул халык тормышында күптөрле максатларда кулланылган. Мәсәлән, ерак араларга төрле хәбәр бирү, хәбәр алмашу, төрле йолалар, ритуал биюләр башкарганда, хәрби өлкәдә гаскәрне дәртләндерү, тәртиптә тоту өчен кирәк булган. Шуңа да барабан дөньядагы барлык халыклар өчен дә искиткеч зур әһәмияткә ия булган корал. Шулай ук ул татар тормышында да шундый вазыйфаларны үтәгән. Аның уен коралы буларак кайчан кулланыла башлаганы билгеле түгел.

Барабан *(бәрүбан)* – гомум төрки сүз. Тарихи һәм әдәби чыганакларда аның дистәләгән төрләре, исемнәре искә алына. Кубрат хан гаскәрендә «давылбаз» – хәзерге литавраларга охшаган зур барабан, «нәгарә» (нәкарә) – уртача зурлыктагы барабан, «давыл», «табыл» кебек күптөрле сугыш барабаннарының булуы билгеле. Шундый ук исемдәге барабаннарның соңрак хәрби максатларда Идел Болгарстанында да кулланылуы турында бөек Болгар шагыйре һәм галиме Кол Гали үзенең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында яза.

Үлемсез «Идегәй» дастанында шундый юллар бар:

«Күн давылбаз бар икән – Төяренә аны алды...»

Сугыш барабаны

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Явыз Иван Казан ханлыгын буйсындырганнан соң, татарларда шәһәр мәдәнияте, югары сәнгать тулысынча юкка чыга. Хан сарайларында, хәрби оркестрларда куллануда булган музыка кораллары акрынлап онытыла. Бу хакта галим М.Нигъмәтҗанов та ассызыклап үтә. Ә инде шәһәр культурасы булмагач, сыйфатлы уен кораллары да, оста башкаручылар да була алмый.

Барабан бүгенге көндә татар музыкасында, ни сәбәпледер, бик аз кулланыла. Югыйсә, ритм саклау, музыкаль тизлекне тәэмин итү, музыканы тагын да баету, тулыландыру өчен, аннан да кирәгрәк уен коралы юктыр, мөгаен. Минемчә, монда берничә җитди сәбәп бар. 16-19 нчы йөзләрдә татар музыкантлары арасында төрле уен коралларында ансамбльләргә оешып уйнау культурасы юкка чыга. Берләшеп, өч-дүрт төрле уен коралында гына уйнасалар да, аның берсе дөңгер (кабала) яисә барабан булган булыр иде. Ләкин кем алдында нинди шатлыктан уйнарга? Шулай да XIX гасыр азакларында берән-сәрән генә булса да ансамбльләр күренә башлый. Ул хакта К.Фукс, С.Габәши, Ф.Туишев, В.Бәхтияров истәлекләрендә дә телгә алына. Чөнки бу вакытта инде татарлар шәһәрләрдә дә яши башлый, музыка уйнап акча эшләү мөмкинлеге туа.

Хәзерге көндә сатуда барабанның бик күп төрләре бар. Миңа калса, нинди максатка нинди зурлыктагы барабан кирәк булса да, сатудагы барабаннарны кулланырга кирәктер. Ә инде фольклор музыкасында тышкы кыяфәтен мех белән төрергә яисә чиккән кулъяулык бәйләп куярга мөмкин. Шул ук вакытта аерым осталар ясаган барабаннар да очрый. Бу уен коралы татар фольклор музыкасында киләчәктә үз урынын табар дип ышаныйк.

Дөңгер

Дөңгер – барабанның бер төре. Халыкта аның «шаман бубены» дигән исеме дә бар. Ул шулай ук музыкага тормыш-көнкүрештән килеп кергән.

Бүгенге көндә «татарларда шаманнар булмаган» дигән сүзне еш ишетергә туры килә. Алай була алмый ул. Чөнки барлык халыклар да меңнәрчә еллар тәңре, шаман дине белән яшәгәннәр, моннан бер татар гына читтә кала алмый. Аның файдасы булмаса, ул алай озак яши алмас иде. Шаман бездә бары тик имче, багучы, күрәзәче кебек башка исемнәр белән генә аталган.

> **«Соңгы елларда татар тормышында ислам дине белән кызыксыну тагын да артты. Зурдан кубып дини бәйрәмнәр, кичәләр, никах туйлары үткәрелә, яңа мәчетләр ачыла. Дини әсәрләр башкарган җырчыларга һәм шулай ук фольклор ансамбльләренә дә ихтыяҗ артты. Монда инде мөнәҗәтләр әйткәндә, дини инструменталь әсәрләр башкарганда уен кораллары бик үтемле.**

Тәңречелеккә турыдан-туры бәйле музыка коралы бер дөңгер генә түгел. Төрки халыкларда, шулай ук татар халкында да алар байтак. Әйтик, кубыз, кыл-кубыз, думбыра, ятаган, таш сыбызгы һәм башкалар. Шуңа да олы тарихлы бу уен коралларына аеруча хөрмәт белән карарга кирәктер.

Дөңгернең кысасын ясау өчен билгеле бер урында үскән агач кына яраган. Аңа тарттырылган тире дә махсус адарынып үстерелгән бәрән яки кәҗә тиресеннән эшләнелгән. Тарттырылган тирегә ясалган рәсемнәр галәмнең символын чагылдырган. Иң беренче камлау дөңгерне утта кыздырып көйләүдән башланган. Ул терелү, чистарыну йоласы дип аталган. Имче терелү йоласы барышында ияләргә уен коралының нинди агачтан ясалуы, тиресе кайсы хайванныкы икәнлеге һәм уен коралына төшерелгән рәсемнәрнең нәрсә аңлатуы турында сөйләгән. Ул бары тик шуннан соң гына тәңредән камлау өчен рөхсәт сораган.

Бөек Аттиланың да, Кубрат ханның да янында күпсанлы шаманнары, имчеләре булуы билгеле. Сүз дә юк, татар тормышына ислам дине килеп кергәч, әлеге уен кораллары кулланудан беренче чиратта төшеп кала башлый. «Без инде мөселман», – дип, аңа кадәр булган бабаларыбызның меңнәрчә еллык тарихын өйрәнмәскә хакыбыз юк. Тарихны ихтирам итәргә кирәктер. Ул безгә мөселман булып калырга комачауламый. Юкка гына: «Үткәнгә мылтыктан атсаң, ул сиңа пушкадан җавап кайтарыр», – димиләр.

2010 елда Алтайдан, Казанда яшәргә дип, тәңречелек үзенчәлекләрен яхшы гына белгән Фарат кайтты. Ул югары сыйфатлы шаман дөңгерләрен ясау эшен торгызып җибәрде. Аның ясаган уен кораллары күп кенә фольклор ансамбльләрендә кулланыла.

2018 елда Венгриянең Бугас шәһәрендә үткән Төрки халыклар корылтаенда дөньядагы иң зур дөңгердә уйнадылар. Әлеге дөңгер тоташ үгез тиресеннән ясалган һәм аның диаметры – 188 см. Әлеге фестивальдә «Сорнай» ансамбле дә катнашты.

Кешеләр соңга табарак, бигрәк тә шәрык илләрендә, әлеге уен коралларының тәрбияви роле зур булуын тоеп-аңлап, аларны башка төрле чараларда да куллана башлаганнар. Шулай итеп, дөңгернең бүтән төрләре дә барлыкка килгән һәм алар, акрынлап, күңел ачу коралына әйләнгән.

Соңгы елларда татар тормышында ислам дине белән кызыксыну тагын да артты. Зурдан кубып дини бәйрәмнәр, кичәләр, никах туйлары үткәрелә, яңа мәчетләр ачыла. Дини әсәрләр башкарган җырчыларга һәм шулай ук фольклор ансамбльләренә дә ихтыяҗ артты. Монда инде мөнәҗәтләр әйткәндә, дини инструменталь әсәрләр башкарганда, дәф, танбур, саз, гыҗык кебек уен кораллары бик үтемле.

Хәзерге татар инструменталь ансамбльләрендә тәңкәле бубен, шөлдер кебек уен кораллары күп кулланыла. Сатуда аларның барлык төрләре дә бар.

Бәрмә уен кораллары

Көнкүреш әсбапларын фольклор ансамбльләрендә уен коралы буларак куллану бик отышлы. Элек-электән оста куллы, шаян егетләр, бер-берсенә бәргәч тавыш чыга торган һәр нәрсәдә музыкаль тавыш, төрле ритмнар уйнап, бигрәк тә кызлары, дуслары алдында үзләренең осталыкларын күрсәтергә омтылганнар. Әйтик, агач кашыкның берсен авызга куеп, икенчесе белән бәреп көй уйнау, пыяла кәсә яисә төрле зурлыктагы чүлмәкләрнең авызларына сугып, музыкаль аваз чыгару, үсеп утырган үләннең яки каенның ярысын кубарып алып сандугач булып сайрау, тал агачыннан ясап, кәк-күк булып кычкырту, салам яисә каз каурыен кисеп алып, аның бер башын телеп, бала булып елау, көлү, сөйләшү, элек авыл каравылчылары кулланган чыгыр әйләндерү, кырлы бәләк, тарак кубыз, пычкыда уйнау һәм тагын бик күп осталыкларны күрсәтергә була.

Әле хәтерлим, 1975 нче елны Арчада торганда безгә татарның танылган композиторы Заһид абый Хәбибуллин кунакка кергән иде. Ул мич алдында эленеп торган күмер кыскычын күреп алды да, аны авызына якын китереп, бал кашыгы белән җиңелчә генә сугып, көй уйнап күрсәтте. Заһид ага скрипкада да бал корты очканын, күбәләк биюен, җил искән тавышларны искиткеч кызыклы, сокланырлык итеп уйный, тасвирлый белә иде.

Хәзерге көндә дә мондый шаяруларны бигрәк тә балалар бакчаларындагы һәм мәктәпләрдәге музыка дәресләрендә, балалар алдында чыгышлар ясаганда күбрәк кулланырга кирәктер. Чөнки нинди дә булса чын уен коралында уйнарга өйрәнү өчен күпмедер вакыт кирәк. Ә бу төр уен коралларында, күрсәтеп биргәч, һәр бала уйный ала, беренче тапкыр музыка дөньясына аяк атлый.

Фольклор ансамбле җитәкчеләренә дә санап киткән әлеге уен коралларына игътибарлырак булырга, аларны күбрәк кулланырга кирәктер. Чөнки дөрес файдалана белгәндә мондый коралларның тавышлары халыкка шулкадәр үтемле, кайчакта аларны бернинди профессиональ уен коралы да алыштыра алмый. ■

Татар дәүләт филармониясе 100 еллык ТАССР тарихында

«Таныш моңнар, таныш исемнәр» циклында узган Илдар Юзеев сүзләренә язылган җырлардан төзелгән әдәби-музыкаль кичәдән соң. Сулдан уңга: Мәсгут Имашев, Фәрит Хатипов, Флера Сөләйманова, Фердинанд Фәтхи, Илдар Юзеев, Нәҗип Бәдретдинов, Фәрдия Сәфәргалиева. 17 октябрь, 2002 ел

1997-2007 еллар

■ 1998 елда Татарстан Республикасы халык уен кораллары оркестры Германиядә гастрольдә була.

■ 1999 елда филармония базасында Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле оеша.

■ 2000 елның 18 ноябрендә Павлюхин урамында урнашкан Киров исемендәге мәдәният сараенда Татар дәүләт филармониясенең Концерт залы ачылуга багышланган «Таныш моңнар» дип аталган тантаналы концерт була.

■ 2001 елда Киров исемендәге мәдәният сарае бинасы тулаем филармония балансына тапшырыла.

■ 2002 елда Фольклор музыкасы дәүләт ансамбле җитәкчесе итеп Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахманов билгеләнә.

■ Татар дәүләт филармониясе һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы гамәлгә куйган Халыкара «Татар җыры» конкурсы 2003 елдан «Татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге халыкара конкурсы» исеме белән дәвам итте. 2005 елда

әлеге җыр бәйгесе Казанның 1000 еллыгына һәм Илһам Шакировның 70 яшьлек юбилеена багышлана.

■ 2003 елның декабрендә филармония директоры итеп Кадим Назыйр улы Нуруллин билгеләнә.

■ 2005 елда филармония Казанның 1000 еллыгына багышланган «Җанлы татар музыкасы» музыкаль проектын гамәлгә ашыра. Казанда узган концертта Әнвәр Измайлов (Кырым), Зөлфия Камалова (Австралия), «Казан төркеме Бәдретдин» (Финляндия), ТР фольклор музыкасы дәүләт ансамбле һ.б. чыгыш ясый.

■ Казан шәһәренең 1000 еллыгы уңаеннан, филармония бинасы фасады ремонтлана. 2007 елда бина эчендә капиталь төзекләндерү эшләре тәмамлана һәм филармония 70 еллык юбилеен 605 тамашачы сыйдырышлы залы булган затлы бинада каршылый.

■ 2006 елда атаклы дирижер Натан Рахлинның тууына 100 ел тулу уңаеннан, Татар дәүләт филармониясе, Татарстан Мәдәният министрлыгы белән берлектә, Натан Рахлин исемендәге музыка фестивален гамәлгә куя. 2007 елда фестиваль Татарстан Республикасы дәүләт симфоник оркестрының оешуына 40 ел тулуга багышлап уздырыла.

*Журналга **Зимфира Гыйльметдинова** әзерләде.* ■

Г.Тукайның тууына 118 ел тулуга багышланган концерттан соң. Сулдан уңга: Нәҗип Бәдретдинов, Гөлчирә Бәдретдинова, Зилә Сөнгатуллина, ..., Равил Шәрәфи, Зөһрә Сәхәбиева, Рөстәм Вәлиев, Илһам Шакиров, Кирам Сатиев, Лена Шагыйрьҗан, Фердинанд Фәтхи, Резеда Галимова. 2004 ел

Тел диган дәрья бар...

Тел дигән дәрья бар...

Татар халкының сөйләмендә мәкальләр һәм әйтемнәр, кыска тәгъбирләр зур урын алып тора. Алар безгә гомер-гомергә аерылгысыз юлдаш, киңәшче, үгет-нәсыйхәтче булган. Гыйбрәтле сүз әйләнмәләрен, сүз тезмәләрен халкыбыз яшәгән һәр җирдә очратырга мөмкин. Аларның кайберләре бөтен татар дөньясына таралган, икенчеләре (аеруча җирле үзенчәлекләргә бәйлеләре) аерым төбәк, хәтта аерым авыл чикләрендә генә кулланышта йөргән. Мамадыш районындагы Бүрсет ягы авылларының да үзләренә генә хас шундый әйтемнәре бар. Үсәли авылыннан ***Мансур Фазылов,*** *заманында, аларның килеп чыгу тарихын ачыклап, берничәсен Татарстан радиосының «Тел күрке – сүз» тапшыруына да язып җибәргән булган.*

Акай явы

Безнең якта юктан гына шау-шу күтәрүче кешегә: «Ник кычкырасың, Акай явы чыкканмы әллә?» – дип әйтү гадәте яшәп килә. Гыйбарәнең барлыкка килү тарихы болай. Явыз Иван тарафыннан басып алынган борынгы бабаларыбыз яшәгән җирләрдә азатлык өчен көрәш ялкыны бер дә тынып тормый. Казан ханлыгының төрле җирләрендә колониаль изүгә каршы берсеннән-берсе көчлерәк баш күтәрүләр булып ала. Шундый баш күтәрүләрнең берсе 18 йөзнең беренче яртысында Татарстан һәм Башкортстан җирләрендә морза Акай Кучемов җитәкчелегендә кабынып китә. Чулман арьягында купкан дәһшәтле фетнә хәбәре Бүрсет буе авылларына да килеп җитә. Изүчеләргә каршы юнәлгән бу баш күтәрүне халык «Акай явы» дип атаган, аңа теләктәшлек белдергән, кулга корал алып, изге яуга китәргә әзер торган. Ләкин тигезсез бер бәрелештә Акай батыр җәлладлар кулына әсир төшә. Ул, ачлыкка һәм газапларга түзә алмыйча, патша зинданында җан бирә. Акай үзе һәлак булса да, аның ядкяре һәм даны халык күңелендә онытылмый. Шушы рәвештә булса да аның исеме безнең телебездә, сөйләмебездә бүген дә сакланып килә.

Безнең якта юктан гына шау-шу күтәрүче кешегә: «Ник кычкырасың, Акай явы чыкканмы әллә?» – дип әйтү гадәте яшәп килә.

Әрнәш җиле

Бүрсет суының югары агымында Әрнәш (Зур Арташ), Түбән Әрнәш, Урта Әрнәш (Албай), Югары Әрнәш (Казаклар) исемле керәшен авыллары сибелеп утырган. Әүвәл заманнарда бу төбәкне «Әрнәш ягы» исеме белән атап йөрткәннәр. Бу яктан – Бүрсет суы үзәнлегеннән Чулман елгасына таба кыш айларында еш кына үзәккә үтәрлек төньяк җиле исә. Элек мескен бүрек, чабата, суккан ыштан киеп йөргән заманнарда салкын төньяк җиле түбәнрәк урнашкан Ташлык, Югары Бүрсет, Үсәли, Бүрсет-Сөкәсе, Баскан, Катмыш, Еникей-Чишмә авылы кешеләренең, теңкәләренә тигән. Үзәнлектән килүче менә шул салкын җилне халык «Әрнәш җиле» дип атаган да инде.

Шулай бервакыт Югары Бүрсеттән Хөснулла исемле кеше Казанга барып чыккан. Көн бик салкын, җилле икән. «Үзәккә үтә шушы Әрнәш җиле, инде Казанга килгәч тә тынгылык бирми каһәр!» – дип, Хөснулла абзый Казан урамыннан исүче салкын җилдән зарланып алган.

Харрас Әюп

Милләтен алмаштырган замандашка

Атаң-анаң татар иде юкса,
Бүтән икән синең милләтең.
Тумыштан бит гарип түгел идең –
Кем ташлады болай имгәтеп?

Нишләттеләр әле, кемнәр тиде,
Яздырдылар нигә телеңнән?
Хәлләреңне беләсеңме үзең,
Канәгатьме шушы көнеңнән?

Ил алдында нинди гаебең бар?
Иркен сулап йөрер кешене
Халкыннан һәм нәсел-нәсәбеннән
Баш тартырлык көнгә төшерде…

Дөнья белә,
Белә татарларны
Башкисәрләр итеп булса да…
Кемдер саткан яманатка карап,
Тик синдәйләр үзенә кул сала.

Кем син хәзер, кайсы милләтнеке? –
Әмма татар түгел инде син!
Үзенә бер яңа яман кавем…
Берүк үрчи генә күрмәсен!

Атаң-анаң каргадымы әллә –
Алмашынган нигә милләтең?
…Тумыштан бит гарип түгел идең –
Кем ташлады болай имгәтеп?!.



Яткан килеш утырам

Туфан Миңнуллин

Наис Гамбәрнең «Әткәй белән сөйләшү»ен укып ятам. Бер җөмләне укыгач, туктап калдым. «Кече якта сәкегә яткан килеш дәрес әзерләп утырам». Көлеп куйдым. Ничек инде ул яткан килеш утырып була икән? Ләкин мин Наисның «наданлыгыннан», редакторның шул мәгънәсезлекне күрми калуыннан көлмим. Татар теленең сыгылма булуыннан, соклануымнан тәмләп көләм. Мантыйкка туры килеп үк бетмәгән халәтне матур итеп әйтеп була икән ул телдә. Искиткеч бит! Яткан килеш утырам. Йоклаган килеш уяу ятам, яраткан килеш сөймим һ.б. Татар телен җаны белән тойган кеше бу алогизмнан хата эзләмәс, билгеле.

2003 ел

Текстларны журналга, «Тел күрке – сүз» тапшыруында яңгыраган язмаларга нигезләнеп, ***Рөстәм Акъегет*** *әзерләде.* ■

Көлке куа килә...

Ягсуп Мортазин

Язучы, мөгаллим һәм актив хәбәрче Я.Мортазин Мөслим районының Яңа Сәфәр авылында туган. Шул ук районның Октябрь (Теләнче), Баек мәктәпләрендә укыта. Бүгенге көндә Бөгелмә шәһәрендә яши.

Гаилә хәле

Партиягә әгъза булып керергә гариза биргән яшь кенә бер ирдән сорыйлар бюрода:

– Өйләндеңме, гаилә хәлең ничек?

– Бер балалы хатын алган булган идем. Шуның белән чиләнеп ятам әле, – дип җаваплый теге.

Саран «теща»

Хатынның анасын урысчалатып теща дип йөрттеләр безнең якларда. Бер танышым сөйләде. Шулай бервакыт күрше авылга тещаларына кунакка баралар болар хәләл җефете белән.

Авырып урында ятса да, кызы белән киявенең парлап чәй эчкәннәрен чаршау ярыгыннан гына күзәтә карчык. Кызын үз янына чакырып ала да:

– Кияү чәенә өч шакмак шикәр салды. Эрегәнче берсен ал әле тизрәк, – дип пышылдый икән тегеңә.

Моны ишетеп алган кияү дә аптырап калмаган, әлбәттә:

– Әбекәем, бер дә борчылма, хәзерге шикәрләр элекке сыман бик баллы түгел алар, – дип куйган, кайнар чәен калак белән болгата-болгата.

Ата «Т»

Әлифба дәресендә «т» хәрефен өйрәнделәр. Баш хәреф һәм юл хәрефе турында да төшендерде укытучы, үрнәкләрен тактага язып куйды. Аннары: «Бу нинди «Т» була инде?» – дигән сорау куйды класска, баш хәрефне күрсәтеп.

Җәһәт кенә кул күтәрде дә Гөлнур, җавап бирде:

– Бу ата «Т» була, – диде.

Гаиләдә баш кешенең ата булуы күңеленә сеңгәндер сабыйның, күрәсең.

Артык бәбкә

Кече улы Наил Вазифа апаның уң кулы иде. Үзе көне-төне колхоз эшендә. Йорт эшләрен карау да, кош-кортны ашату-тәрбияләү дә малай өстендә.

Беркөнне кичкә каршы каз бәбкәләрен су буеннан алып кайтып килә Наил. Елый-елый ярсып беткән балакай.

– Нәрсә булды, ник елыйсың? – дип кызыксына күршеләре.

– Безнең бәбкәләр бишәү генә иде, монда алтау булганнар, – дип, тагы да ныграк үксергә тотына сабый.

Ленин кайда туган?

Партиянең Мөслим райкомында укытучыларның политик белемнәрен тикшерү гадәте бар иде. Шундый максат белән безнең Октябрь сигезьеллык мәктәбенә пропагандист Шәехвәли Миргаязов килде бервакыт. Педагогларны берәм-берәм чакырып сөйләшә бу. Чират шактый өлкән яшьтәге, инде пенсиягә чыгар вакыты якынлашкан апага җитә. Гади генә сорауларга да җавап бирә алмагач, кызык өчендер инде:

– Ленин кайда туган әле? – дип сорап куя пропагандист.

– Сез бигрәк инде, иптәш Миргаязов, Владимир Ильичның Ленинградта туганлыгын беренче класс укучысы да белә ич аны, – ди мөгаллимә апабыз, ниһаять, бер сорауга дөрес җавап биргәндәй.

Чагыштыру

Мари Бүләре – безнең Мөслим районындагы зурлыгы, матурлыгы белән урта кул авылларның берсе. Ә менә халкының уңган-булганлыгына тел-теш тидерерлек түгел мәгәр. Әле республикабыз башлыгы Фикрәт Табеев чагында ук аларның хезмәт алдынгылары турында укып та, ишетеп тә белә идек. Шулай бер елны Мәскәүдә буласы алдынгылар җыелышына делегат итеп терлек караучы Миңлегәрәйне дә сайлаганнар шушы авылдан.

Кызыл Мәйданда Ленин мавзолеена керергә чиратта торалар икән. Тирә-юньгә карап-карап торган да:

– Безнең Мари Бүләре чаклы өч бардыр бу Мәскәү, әйеме, Фикрәт Әхмәтҗанович? – дип куйган Миңлегәрәй.

– Да, шул чама булыр, – дип җаваплаган Татарстан делегациясе җитәкчесе тыныч кына, ягымлы елмаеп. ■

*Сахифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.*

ИЮНЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Казанда табиб һәм шагыйрь Ринат Мәннанның «Сүз» нәшриятында «Ринат Мәннан: иҗатына штрихлар» китабы басылып чыкты.



● Мамадыш үзәгендә сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен Мамадыш мәктәп-интернатының (директоры – М.Вәлиев) уку корпусы төзелә. Анда зур спорт залы, гимнастика һәм тренажер заллары булачак. Алдагы уку елында мәктәп-интернатта 146 бала укыячак, шуларның утызы өйдә белем алачак.

● 3 июньдә Татарстанның атказанган артисты, Актаныш районының Кормаш авылы тумасы, байтак еллар Минзәлә театрында эшләгән Гөлшаһидә Сәлахова вафат булды.

● 6 июньдә күренекле эзтабар-язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россия Федерациясенең М.Ломоносов исемендәге премиясе, шулай ук Ш.Маннур һәм Х.Ямашев исемендәге премияләр (әдәбият, журналистика һәм хәрби-тарихи публицистика өлкәсендәге эшчәнлеге өчен) лауреаты, прозаик, публицист, шагыйрь, «Безнең мирас» журналының тугрылыклы дусты һәм актив авторы Шаһинур Әхмәтсафа улы Мостафинның йөрәге тибүдән туктады. Аның җәсәде туган авылы Арташ (Мамадыш районы) зиратында җирләнде.

● Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты «Тәсбих: фарыз яки сөннәт намаздан соңмы?» буклетын бастырып чыгарды.

● Уфада, Шәехзадә Бабичның (1895-1919) 125 еллыгы уңаеннан, шагыйрьнең «Ал да чәч нур халкыңа» дигән шигырьләр китабы басылып чыкты.

● 14 июньдә Ульяновск шәһәрендә шагыйрә Иделбикә (Лена Садыйкова-Сабитова, 2001 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы) вафат булды.

● Омски шәһәрендәге җәмигъ мәчете манарасына яңа ярымай куелды.

● 15 июньдә Казандагы Яңа Татар бистәсе зиратында мәшһүр җырчыбыз Әлфия Авзалованы искә алу чарасы узды.

● Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның (1938-2011) туган төбәгендә – Баулы районының Кызылъяр авылында узган ел парк төзелә башлаган иде. Күркәм эшне җәй ахырына тәгалләргә ниятлиләр.

● 16 июньдә язучы һәм шагыйрь Әхмәт Дусайлы (Хәмәдишин) вафат булды. Мәрхүмнең җәсәде Мөслим районындагы Баек авылы зиратында җирләнде.

● 18 июньдә Мәскәүдәге Троекуров зиратында Россиянең халык артисты Фуат Мансуровны искә алу чарасы узды: бөек музыкант һәм дирижер каберенә Татарстан Республикасы Премьер-министрының урынбасары, Татарстан Республикасының Россия Федерациясендәге Тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, Мәскәү татар автономиясе җитәкчесе Фәрит Фарисов һәм Татарстанның Тулы вәкаләтле вәкиле урынбасары Эмиль Фәйзуллин чәчәкләр салды.

Ф.Мансуров 2010 елның 11 июнендә Мәскәүдә вафат булган иде.

● 20 июньдә Ростов шәһәренең Иске Татар зиратында беренче тапкыр өмә оештырылды. ■

МИРАСВОРД

Мамадыш районында Питрау бәйрәме уза торган авыл

Кар эчендә ясалган куян өне (диал.)

«... килде» (Шәриф Хөсәенов)

Камыр ачыту өчен савыт

Шәрык поэзиясендә ике юллык шигырь

«Килә ..., килә ...» (Зөлфәт Хәким)

... Шәйхи (Мамадыш районы Урта Сон авылында туган шагыйрь)

... Гарипов (башкорт шагыйре)

Ел (иск.)

Умберто ... (итальян язучысы)

Юныс ... (төрек шагыйре)

Ваһапов, Шамкай, Бәшәр

... Маннанов (Мөслимнең Бүләк авылында туган Советлар Союзы Герое)

Сатурн иярчене

Мәдинә Маликова романы

Берәр өлкәдә билгеле бер югарылыкка, дәрәҗәгә күтәрелү

Борынгы Спарта патшасы

Кәҗә мамыгын чистарта торган тарак

Әгерҗе районындагы авыл

... Карнай (башкорт әдибе)

Б.э.к. Кара диңгез буенда яшәгән күчмә кабиләләр

Кавказда яшәүче, тел ягыннан иран төркеменә караган халык

Левон ...-Петросян.

Европадагы елга

Ханның уң кулы

Сальвадор ... (испан рәссамы)

Испан биюе

... Тойгын (башкорт шагыйре)

Диалект (иск.)

Каеш прәшкәсе

Иптәш, дус, агай-эне

Җәяр өчен әзерләп куелган түгәрәк камыр

Кәрим Тинчурин драмасы

... Латыйфи (Мөслим районы Уязгендә туган язучы)

Мөҗәһит ... (Мөслим районының Түреш авылында туган шагыйрь)

«Ла ...» (Милан опера театры)

Ягулык та, ашлама да

Тотка

Сабантуй батырына бирәләр

Мамадыш район газетасы

... мылтыгы

Җәлалетдин ... (урта гасыр фарсы шагыйре)

Сабантуйда аны күзне бәйләп ваталар

Бензин маркасы

6 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: омега, Сәлим, иләт, Рәхимкулов, мән, Лист, фәс, Вакыйф, Илида, ия, тиф, Рубенс, Имәни, арка, Реймс, ихата, ядрә, нүкәр, уд, сәкен, Каюм, По.
Өстән аска: Финикия, әмәл, «Дуга», хәситә, ир, ясмин, дин, Хәким, Афина, Маликов, Илу, «Аврора», гамәл, Толымбай, улән, «Вий», Ермак, сфинкс, әдеп, яса, Бруно.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / июль

Мөхәммәт Мәһдиевнең музей-йорты. Арча районының Гөберчәк авылы

625 ел элек (1395)

Аксак Тимер гаскәре Идел буена килеп җитә. Күпчелек тарихчылар фикеренчә, Үкәк, Болгар, Җүкәтау вә Кирмәнчек кебек болгар калалары шушы вакыттагы коточкыч дәһшәтле яу көннәрендә җимерелә.

120 ел элек (1900)

22 июльдә мәшһүр галим Хәмит Мозаффар улы Мөштәри (1900-1981) дөньяга килә.

90 ел элек (1930)

29 июльдә Мәскәүдә Кызыл Армия һәм Кызыл Флот язучылары берләшмәсе – ЛОКАФ оештырыла. Аның Үзәк идарәсенә Татарстаннан Кави Нәҗми белән Мирсәй Әмир сайлана.

85 ел элек (1935)

«Совет әдәбияты» журналында Галишер Нәваиның «Фәрһад вә Ширин» поэмасы (үзбәкчәдән Әхмәт Исхак тәрҗемәсе) басыла.

25 ел элек (1995)

«Мәдәни җомга» газетасының беренче саны дөнья күрә.

20 ел элек (2000)

6 июльдә Арча районының Гөберчәк авылында Мөхәммәт Мәһдиевнең музей-йорты ачыла.

25 июльдә татар җәмәгатьчелеге язучы Хәйдәр Гайнетдиновны (1952-2000) соңгы юлга озата. Аны туган ягы – Зәй районының Дүрт Мунча авылы зиратында җирлиләр.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.*■

Содержание. Июль 2020

И останется в мире слово мое...: Шайхи Маннур.

Татарский мир: «Рамиль Муллин: «Самое главное – духовный мир человека».

Историческое наследие: «Этруски – наставники римлян». С.Шамси; «Мамадыш». Ф.Мингалиева; «Бунт мамадышских крестьян». Ю.Карпов; «Фольклор Мамадышского региона на страже нации». Л.Мухаметзянова, Г.Дувалова; «Краеведческий музей Муслюмово»; «Виды национальной борьбы». М.Сахабутдинов.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

Литературное наследие: «Ямочки любви». К.Каримов.

В глубинах памяти: «В памяти, до сих пор в памяти!»; «75 лет искал». А.Гадельша.

Художественное наследие: «Древние национальные музыкальные инструменты». Р.Гилязев; «Татарская государственная филармония в столетней истории ТАССР». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Әхмәтҗан хәлфә Мостафин (утырганнар арасында уңнан беренче) гаиләсе һәм туганнары белән

- **Миссионер Малов Исхакыйның «Зөләйха»сы белән кызыксынган.** **Лена Гайнанова**
- **Әхмәтҗан хәлфә.** **Тәэминә Биктимирова**
- **Шагыйрь Сириннең «Ана» поэмасы.** **Әнвәр Шәрипов**
- **Казанда Гали Акышны хөрмәтләү.** **Фоат Галимуллин**
- **Иҗат мөһере.** **Рәдиф Сәгъди**
- **Үлемсез батальон солдаты.** **Ирек Нигъмәти**

Әдип авылы — фотоларда

Ш.Маннур (уңнан икенче) авылдашлары белән Сабан туенда

Мамадыш районының Тулбай авылына (язучы Шәйхи Маннурның туган авылы) кагылышлы әлеге фотолар «Шәйхи Маннур мемориаль музей-китапханәсе»ннән (җитәкчесе – Римма Сөләйманова) алынды.

Тулбай авылының өлкәннәре. Ш.Маннурның чордашлары, әсәрләренең прототиплары. 1965 ел

Әдипнең авылдашлары

Язучының якташлары печән өстендә

МӨСЛИМ МӘДРӘСӘСЕ

Мөслим мулласы Миргалəү Максутов аны 1901 елда таныш байлар – Гликəевлəр ярдəмендə салдыра

2016 елның җəендə ремонтлана

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА - П2343
РОССИЯДӘ - П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»* *журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдəмендə
- редакциядə
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдəмендə

электрон версия

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннəн (Бауман ур., 19 һəм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннəн (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.